Безнен МИРАС
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
02
февраль 2022
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИН

## Кондырча сугышы яки Аксак Тимер һәйкәлгә лаекмы?

*10 бит*

## «Ул Бибигайшәгә өйләнергә тиеш иде...»

*29 бит*

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең Мирас 12 +
02
(338)
февраль 2022

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

15

*Баш мөхәррир*
**Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)**
(843) 222-09-83 (17-92)

*Баш мөхәррир урынбасары*
**Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)**
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

**Ирада Әюпова**
*(ТРның мәдәният министры)*
**Айрат Зарипов**
*(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)*
**Айдар Сәлимгәрәев**
*(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)*
**Васил Шәйхразиев**
*(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)*

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

*Җаваплы мөхәррир*
**Ленар Гобәйдуллин**
89196911406

*Дизайнер һәм биткә салучы*
**Алмаз Фәйзуллин**
(843) 222-09-83 (17-92)

*Мөхәррир*
**Ләйсән Данилова**
(843) 222-09-83 (17-91)

*Сайт мөхәррире һәм корректор*
**Энҗе Хөсәенова**
(843) 222-09-83 (17-93)

*SMM-белгеч*
**Ләйләгөл Сафина**
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

**«Безнең мирас» (Наше наследие)**
**Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)**

# Эчтәлек

**ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...**

3 Кадыйр Сибгатуллин

**ТАРИХИ МИРАС**

4 Татар – дәүләти халык. *И.Таһиров*
10 Кондырча сугышы яки Аксак Тимер һәйкәлгә лаекмы? *И.Миргалиев*
15 Казан татарлары. *А.Сперанский*
24 Истанбул мәктүбләре. *Ф.Кәрими*
29 «Ул Бибигайшәгә өйләнергә тиеш иде...» *Ә.Камал*
34 Фин иленә сатылган татар мирасы. *Н.Гариф*
37 Коточкыч ачлык. *Ш.Юзеева*
40 Атлы кешеләр заманы кайтырмы? *З.Хәбипова*
46 «Ирләрне каракүл бүрекләре таныта». *М.Фәйзи*
52 Татарның таланган алтыны. *Л.Габдрафикова*

**Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.**
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

**«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.**

## ТАТАР ГАМЕ


56 Сиринә Сәлимшина: «Җиңүгә иманлы кешеләрнең кылган догалары китерде!»
62 Без – Чыңгыз хан варислары! *Ф.Нәфиев*
66 «Безнең мирас» котлый!


## ДИНИ МИРАС


67 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
73 Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. *Ә.Рәхими*
74 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*
76 Сәрвәретдин хәзрәт мирасын барлыйк!
78 Ислам, тәрәкъкый, ислах. *С.Мифтахетдин*


## ӘДӘБИ МИРАС


87 Гариза. *Р.Батулла*
93 Нурихан Фәттах көндәлекләре
98 Әхмәт Гадел шигырьләре


## ХӘТЕР САНДЫГЫ


100 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
102 «Болай ук булыр дип уйламаган идем...» *Ф.Сәфәргалиева*
108 Истә, һаман да истә!





## СӘНГАТИ МИРАС


110 «Вәгъдә» җыры


## ШАЯН МИРАС


112 Көлке куа килә...


## БАЛАЧАК МИРАСЫ


114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Февраль*

Заказ №О-0295. Тираж – 2850 данә. Формат 70х100 $^1/_{16}$
Басарга кул куелды: 27.01.2022. Чыгу көне: 02.02.2022.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Кадыйр Сибгатуллин

*Үз бабасын җуйса әгәр халык,*
*Ят бабалар ала урынын...*

*Кадыйр Сибгатуллин*



**Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин үзе яшәгән йорт ишегалдында. 1991 ел**

# КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИН
(15.02.1942-4.06.1994)

Һәр милләтнең була көчлеләре,
Һәр халыкның була батырлары.
Көрәшләрнең башы гел бертөсле,
Төрле-төрле була ахырлары.

***

Дөнья матур, матур итеп гомер итсәң.

***

Һәйкәлләрнең төрле гомерләре,
Һәйкәлләрнең төрле язмышы.
Берәвендә – илнең мәхәббәте,
Берәвендә – илнең каргышы.

***

Аналардан малайлар туа, ир тумый.

***

Милләт бөек, халык бөек,
Бары тик сансыз гына.

***

Син – халкымның сагыш-газаплары,
Син – халкымның тирән моңгай сыры.
Кайгыларга баш имәгән өчен
Рәхмәт сиңа, рәхмәт, татар җыры!

***

Мәңгелек түгел, гомерлек,
Барыбыз да – күбәләк.
Булмый гомерләр туп-тулы,
Булмый гомер түгәрәк.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

# Татар – дәүләти халык

**Индус Таһиров,** академик

**Татарстан суверенитеты көнендә язучы Рабит Батулла улы Нурбәк белән чыгыш ясый**

Яңа Союз шартнамәсенә карата Татарстан үз позициясен анык белдерде: ул, кабул ителгән Декларациягә нигезләнеп, әлеге шартнамәгә РСФСР составында түгел, ә мөстәкыйль рәвештә генә кул куярга риза иде.

Бу хәл Россия җитәкчелеген бик нык борчуга салды. Россия белән Татарстан арасында диалог кору ихтыяҗы барлыкка килде. Сөйләшүләрнең беренче өлеше 1991 елның 12 августы көнне Россиянең Ак йортында башланды һәм 15 август көнне уртак беркетмә имзалау белән тәмамланды. Әлеге документның шул ягы әһәмиятле: анда безнең Декларациягә ихтирам белдерү һәм алга таба да килешеп эшләү зарурлыгы язылган иде.

Мәгълүм ки, шул елның 19-21 августында булып үткән ГКЧП фетнәсе ике арадагы мөнәсәбәтләрне катлауландырды. Россия җитәкчелеге, шуннан файдаланып, Татарстанны «үз урынына утыртырга» тырышты. Минтимер Шәймиевкә, партия рескомының беренче секретаре Рево Идиатуллинга карата җинаять эшләре кузгатылды. Республикабызның кайбер гражданнары, шул исәптән прокуратура хезмәткәрләре, Югары Совет, Шәһәр Советы депутатлары бу яңалыкны алкышлап каршылады. Алар Шәймиевнең эш урыныннан алынуын таләп итте.

---

Ахыры. Башы журналның 1 нче (2022) санында.

Ләкин шушы авыр шартларда да халык үз Президентына кул тидертмәде, аның иминлегенә гарант булды. Нәтиҗәдә, Татарстан үзе сайлаган юлдан тайпылмады, җитәкчелек тә артка чигенмәде. Моңа иң зур дәлил – республикабызның дәүләт статусы турында үткәрелгән референдум. Шунысын әйтергә кирәк: баштарак Россия җитәкчелеге бу чараны уздыру ягында иде. Әйтик, алдарак телгә алынган сөйләшүләр вакытында Россия делегациясенең җитәкчесе Геннадий Бурбулис: «Декларациягез яхшы һәм дөрес төзелгән. Ләкин сез бу хакта референдум үткәреп, аның нәтиҗәләре белән килсәгез, аерата яхшы булыр иде», – диде. Бу – Татарстанда бары тик 48 процент татар яшәп (ул вакытта), аларның да бер өлеше суверен статуска каршы булу ихтималын исәпкә алып, ягъни референдумның тәгаен тискәре нәтиҗә бирәчәгенә ышанып әйтелгән сүзләр иде.

Инде дә килеп, Татарстан җитәкчелеге әлеге эшкә җиң сызганып тотынгач, мәскәүлеләрне шом басты. Алар ничек тә референдумны үткәрмәү чараларын күрә башлады. Аеруча РСФСР Югары Советы рәисе Руслан Хасбулатов чыгырыннан чыкты. Гомумән, бу кеше һәрвакыт Татарстанга басым ясап торды. Радио-телевидениедән, газета-журналлардан дисеңме – гел-гел суверенитетыбызга каршы чыгыш ясады. Референдум алдыннан Россия Югары Советы машиналары Татарстан районнарына чыгып, референдумга каршы өндәмәләр, коткы-куркыту хәбәрләре таратып йөрде.

Мәскәүнең Ак йорты һәм Кремле тарафыннан Татарстандагы суверенлыкка каршы көчләргә ярдәм күрсәтелде. Республика прокурорларына барлык сайлау участокларын ябарга дигән әмер бирелде. Кайбер район прокурорлары бу әмерне кирәгеннән артык тырышып үтәргә кереште. Мәсәлән, Лениногорскида хәтта Татарстан Президенты яки Югары Советы исеменә юлланган хатларны да тоткарларга боерылган. Россия демократик партиясенең (ДПР) җирле оешмасын җитәкләгән прокурор Петр Гринь шул хатларның авторларын чакыртып, аңлатмалар яздырган. Ләкин, дөресен әйтергә кирәк, мондый кешеләр аз иде. Татарстанда бер генә сайлау участогы да ябылмады.

Референдумга каршы эшкә Россия Президенты Б.Н.Ельцин үзе дә турыдан-туры катнашты. Ул телевидение аша Татарстандагы рус халкына сүз катты: референдум соравына «әйе» дип җавап биргән көннең иртәгесен үк икенче сортлы гражданнар булып уяначаксыз, диде.

Б.Н.Ельциннан соң Татарстан халкына М.Ш.Шәймиев мөрәҗәгать итте. Ул телевизор караучыларга Татарстан позициясенең асылын, референдумның максатын аңлатты. Аларны актив катнашырга һәм куелган сорауга уңай җавап бирергә чакырды. Бу, һичшиксез, батыр адым иде. Чөнки, соңрак ачыклангач, шул көннәрдә Мари-Эл Республикасының Волжск шәһәренә Руслан Хасбулатов килгән; референдум тискәре нәтиҗә бирсә, ул Минтимер Шәриповичны, «тимер читлеккә утыртып», Мәскәүгә илтеп тапшырырга тиеш булган.

Мондый батырлык тавыш бирүчеләр тарафыннан югары бәяләнде. Ф.Х.Мөхәммәтшин, М.Г.Сабиров һәм М.Ш.Шәймиев исеменә юллаган хатта Н.И.Степанов (Казаннан): «Безнең гаилә референдум соравына «әйе» дип җавап бирде, – дип яза. Үзенең 21 март көнне бары тик җиңү турында гына уйлавын белдерә һәм Шәймиевкә: – Сайлаучыларга Сезнең мөрәҗәгатегез бик нык ярдәм итте», – ди.

Татарлар курыкмады. Алар Татарстан җитәкчеләренә көч-куәт, дәрт-дәрман биреп торды: «Минтимер! Булма камыр, бул тимер!» – дип, мәйданнарга чыкты.



БЮЛЛЕТЕНЬ

для голосования на референдуме
Республики Татарстан

21 марта 1992 года

Согласны ли Вы, что Республика Татарстан — суверенное государство, субъект международного права, строящее свои отношения с Российской Федерацией и другими республиками, государствами на основе равноправных договоров?

Оставьте один из указанных ответов, другой вычеркните

ДА НЕТ

Бюллетень, в котором при голосовании вычеркнуты слова ДА и НЕТ или не вычеркнуты оба слова, признается недействительным.

Референдум көннәрендә республиканың Югары Советы исеменә бик күп хатлар, телеграммалар яуды. Аларның күбесендә референдумны яклау, халкыбызга теләктәшлек белдерү ярылып ята иде. Шуларның тагын берничәсе белән танышып китик.

Бер хатта: «Без Президент М.Ш.Шәймиевкә, ныклыгы һәм суверенлыкны тормышка ашырудагы тәвәкәллеге өчен, рәхмәт белдерәбез», – диелә. Сайлаучы К.Нуретдинов Ф.Х.Мөхәммәтшин исеменә язган хатында: «Әгәр дә Татарстан җитәкчеләре, Мәскәүдән куркып, федератив договорга кул куйса, халык аларны беркайчан да гафу итмәс, беренче номерлы мөртәт итеп санар», – ди. Хатның ахыры да гаярь: «Әгәр дә сез бер җебек яки империячел рухтагы кеше икәнсез, отставкага китегез, татар халкын хурлыкка төшермәгез!»

Әгерҗедән килгән хатта мондый җөмләләр бар: «Артка таба юл юк. Безне хәзер бөтен дөнья белә. Шуңа күрә дә референдум бик уңышлы үтәргә тиеш… Артка юл юк, бары тик алга, бары тик алга!»

БДБ илләрендә һәм Россиядә яшәгән татарлар да ул көннәрдә Татарстанга теләктәшлек күрсәтте. Безнең кулда – Үзбәкстан, Таҗикстан, Мәскәү, Әстерхан, Екатеринбург, Чиләбе, Красноярск тарафларыннан яуган хатлар… Аларның авторлары үзләрен Татарстанның суверенлыгын яклаучылар исемлегенә кертүне сорый.

Чиләбедән төзүче-инженер В.В.Вәлиев: «Мин үземне һәрвакыт тарихи Ватанымның гражданы итеп санадым, саныйм һәм референдумда куелган сорауга «әйе» дип җавап бирәм», – дип яза. Екатеринбургтан килгән бер хатта: «Суверенлык өчен көрәшне бер генә минутка да туктатмаска, халыкны көнетөне азатлыкка чакырырга кирәк», – диелгән. Н.М.Мәгъдәнуров (Мәскәү) Татарстан Югары Советы исеменә җибәргән открыткасында болай ди: «Референдум үткәрүдәге тәвәкәллегегез белән тулысынча килешәм. Дөрес һәм ачык куелган соравыгыз өчен бигрәк тә рәхмәтлемен. Әгәр дә мин Татарстан гражданы булсам, республикамның мөстәкыйльлегенә, аның бәйсезлегенә «әйе» дип җавап бирер идем». Мәскәү татарларының Татарстан статусына карата мөнәсәбәте Рифкать Галимов һәм Нур Гарипов җитәкләгән «Туган тел» җәмгыятенең хатында тулысынча чагыла: «Татарстан суверен дәүләт булсын!»

Референдумда татардан гайре милләт вәкилләре суверенлыкка каршы тавыш бирер дигән шөбһәләр дә акланмады. 14 март көнне М.Ш.Шәймиев исеменә юллаган хатында А.П.Степанов болай дип яза: «Шушы авыр көннәрдә Татарстанның суверенлык программасын тулысы белән яклыйм, чуаш булсам да, Татарстанда туып-үстем һәм аның өчен көрәшкә әзермен».

12 март көнне имзаланып, М.Ш.Шәймиевкә, Ф.Х.Мөхәммәтшинга һәм М.Г.Сабировка юллаган хатында ике солдат анасы Т.Володина референдумны тулысынча яклавын әйтә: «Алла хакына, моннан ары Грозныйлар да, Годуновлар да,

Берия дә, Сталин да, Жириновскийлар да булмасын. Радио-телевидение, матбугат чаралары аркылы Хасбулатов, Травкин, Грачев, Хафизов һ.б. безгә янамасыннар. Күпмилләтле Татарстан халкы үз юлын билгеләде… Безнең җитәкчеләргә тимәгез, аларны пычратмагыз».

Бик күп хатларда Россиядә яшәүче руслар һәм башка милләт вәкилләре Татарстанга карата кылынган басымга ризасызлык белдерә. Оренбургта яшәүче бер хатынның язганнарын тәрҗемәсез, оригиналдагыча бирәм*:

*«Здравствуйте, милые татары!*

*Слушаю каждый день гавканье ТВ и радио России по поводу референдума в Татарстане. Да плюньте вы на них и на их продажные суды и обязательно отделитесь от России.*

*Правительство России ведет политику геноцида против народа. Если Вы отделитесь от России, может быть, и выживете. А нам, русским, не привыкать подыхать под игом наших царьков.*

*Я считаю, что всем нужно отделиться от России: и мордве, и чувашам, и всем народам; а нам так и надо, чтобы впредь немного думали, кого в цари выбирали.*

*Мне даже смешно, как депутаты России пыжатся, осуждая Вас. Да какое им дело до Татарстана, если все они колышутся под одной дирижерской палочкой, как болванчики.*

*Только одно надо помнить. Если для Татарстана все народы, живущие на этой территории, будут родными детьми, Вы достигнете огромных высот, если же нет, то Вы будете не лучше русских царьков.*

*С уважением, Дубровская Ольга Андреевна».*

Пятигорск шәһәреннән В.Н.Щелоков РСФСРның вице-президенты А.В.Руцкойга, генераль прокурор В.Г.Степанковка һәм Татарстан Югары Советына җибәргән хатында мондый сорау куя: «Генераль прокурорның, Югары Советның, Ельцинның Татарстанның Россиядән аерылып чыгу ниятенә карышырга ни хакы бар?.. Татарлар, ничек теләсәгез, шулай хәл итегез, тик русларны гына рәнҗетмәгез, аларны инде Ельцин да җитәрлек рәнҗетте».

Самарада яшәүче В.Е.Фирсов Татарстан Президенты һәм Югары Советы Рәисе исеменә мондый сүзләр юллаган: «Самара өлкәсе халкы сезнең горур республикагыз белән бергә дип санагыз. Шушы елның 21 мартында сезнең халкыгыз Мәскәү экспансиясеннән азат яшәргә теләвен ачык белдерәчәк. Без, Идел буенда яшәүче татарлар, чуашлар, руслар һәм башка халыклар, үзебезгә ничек яшәргә кирәклеген кемнән дә булса яхшырак беләбез. Миңа, рус кешесенә, татар халкының кайгылары, иртәгесе көн турында уйланулары яхшы аңлашыла…»

1992 елның 18 мартында Татарстан Югары Советына Украинадагы «За вільну Україну» оешмасыннан килеп төшкән, Татарстанның бәйсезлеген тулысы белән яклаган бер хатта: «Бүген Россия элеккеге СССР халыкларына карата империалистик политика алып бара, ләкин ул, ахыр чиктә, үзе шушы политиканың корбаны булачак», – диелә. Шул ук Украинадан Татарстандагы хәлләрне игътибар белән күзәтеп баручы коммунист В.Захарченко Ельцинны һәм аның тирәсендә буталучы С.М.Шахрай ишеләрне «СССРны җимерүчеләр» дип атый, аларның татар депутат-

* Хатның орфографиясе һәм пунктуациясе чыганактагыча сакланды. – *Редакция.*

ларын «боргычларга» тырышуларын «административ-тоталитар ысул демонстрациясе» дип бәяли. Аның хаты болай тәмамлана: «Татарстан – Кырым, Украина һәм башкалар кебек үк – үз суверенлыгы өчен үзе тавыш бирергә хокуклы. Беркемнең дә моңа комачау итәргә хакы юк».

«Без, Балтыйк култыгында яшәүчеләр, – диелә Я.Я.Колниншның Ригадан язылган хатында, – сезнең дәүләт бәйсезлеге, Татарстанның яңа күтәрелеше өчен алып барган авыр көрәшегезне игътибар белән күзәтәбез. ...Мәскәү Кремле сезгә үзенең империалистик позициясен такмакчы була. Без исә, әгәр дә сез үз акылыгыз белән яшәмәсәгез, Татарстан юкка чыгачак дип уйлыйбыз». Хатның ахырында: «Балтыйк култыгында яшәүче халыкларның намуслы күпчелеге Татарстан халыкларына бәхет, азатлык һәм дәүләт бәйсезлеге тели», – диелгән.

Псков өлкәсендә гомер кичерүче Л.Ф.Баженовның хаты да үзенчәлекле. Анда мондый юллар бар: «Мине, 1928 елда туган вотяк (удмурт) Баженов Леонид Федоровичны, бәйсез Татарстан дәүләте хакындагы референдумда катнашучы итеп санагыз... Татарстан дәүләте рус булмаган халыкларның сәяси нигезе булачак. Татарстанга Әстерхан, Оренбург, Урал, Новосибирск һәм монгол чикләренә кадәр җирләр кушылачак. Бу җирлеккә Чечня, Кабарда, Дагъстан, Осетия белән союздаш рәвештә вотяклар, коми, мордва, мари, чуашлар һ.б. керәчәк».

Мин шушы хатларга нинди дә булса аңлатма бирергә дә, андагы кайбер фантастик фикерләрне тәнкыйтьләргә дә җыенмыйм. Максатым – читтә гомер сөргән милләттәшләребезнең, башка милләт вәкилләренең Татарстандагы референдумга карата мөнәсәбәтен күрсәтү. Әйе, алар нигезендә шик-шөбһәсез нәтиҗә ясарга мөмкин: референдум көннәрендә Татарстан берьялгызы булмый.

Әлбәттә, референдумга, Татарстанның суверен статусына карата тискәре фикер белдергән хатларның да булуын искә алмасам, хакыйкатькә хилафлык килер. Самара өлкәсеннән Юдин дигән берәү хәтта «доброволецлар» җыеп, Татарстанга хәрби һөҗүм ясарга чакырган иде!.. Дөрес, аны Абдулов, Галимов, Надиров шикелле татар активистлары бик тиз авызлыклады.

Референдум нәтиҗәләре һәркемгә мәгълүм: тавыш бирүчеләрнең 61,4 проценты Татарстанның суверенлыгын яклап чыкты. Бу тарихи җиңү иде. Чөнки Россия Конституция суды рәисе В.Д.Зорькин аңарчы РСФСР Югары Советы утырышында: «Әгәр дә референдум соравына «әйе» дигән җавап алынса, бу бәйсезлек игълан итү өчен юридик нигез булачак. Моны һәрбер юрист хаклы рәвештә шулай дип санаячак», – дип чыгыш ясаган иде. Бәлки, соңрак ул әлеге гамәленә үкенгәндер дә. Әмма, халык әйтмешли, әйткән сүз – аткан ук. Аны кире алып булмый.

Референдум татарның дәүләти халык икәнлеген тагын бер кат раслады.

Озакламый Россия җитәкчелеге Федератив шартнамә әзерләп, аны тантаналы рәвештә имзалау көнен билгеләде. Әлбәттә, Татарстан аңа кул куюдан баш тартты. Чөнки ул вакытка безнең өчен Россия белән ике яклы, тигез хокуклы килешү төзеп, махсус статуска ия булу мөмкинлеге ачылган иде.

Татарстан яңадан үзенә көрәштәшләр эзләде. Һәм тапкан да сыман иде: Башкортстан белән Саха да әлеге шартнамәгә тискәре мөнәсәбәтен белдерде. Әмма бу юлы да эш без дигәнчә булмады. Мин, Россия һәм Татарстан арасындагы сөйләшүләрдә Татарстан делегациясе җитәкчесенең урынбасары буларак, күз алдымда үткән берничә вакыйгага тукталырга телим.

Федератив шартнамәне имзалау көне итеп 1992 елның 31 марты билгеләнде. Ике яклы сөйләшүләребезнең чираттагы утырышы да нәкъ шушы датага туры килерелде. Ул иртәнге сәгать унда Россия Хөкүмәте бинасында башланырга тиеш

**Ирек мәйданында халык Югары Совет депутатларыннан Татарстанның бәйсез Конституциясен кабул итүне таләп итә. Ул таләпләр кулларындагы плакатларга язылган. Казан, 1992 елның 15 октябре**

иде. Без, җыелышып, Россия делегациясе җитәкчесе, РСФСР Дәүләт Секретаре Г.Э.Бурбулисны көттек… Ун минут үтте – ә ул һаман юк. Аптырагач, делегация җитәкчесе, Татарстанның вице-президенты В.Н.Лихачев белән икәү коридорга узып, Бурбулис кабинетына юнәлдек. Аның ишек төбендә бер төркем түрә-кара утыра иде. Лихачев танып алды: Башкортстан җитәкчеләре булып чыктылар. Баксаң, Бурбулис аларны Федератив шартнамәгә кул куярга күндерү өчен чакырган икән. Максатына ирешкән дә. Кичен безгә документның Башкортстан өчен генә эшләнгән кушымтасы килеп иреште. Аның нигезендә җир асты байлыклары, хокук саклау органнары – Башкортстанныкы дип танылган иде. Күрше республиканың шушы ташламалар бәрабәренә Федератив шартнамәне имзалавы беленде.

Сөйләшүләр вакытында Бурбулисның урынбасары, Милләтләр эше буенча Дәүләт комитеты рәисе В.А.Тишков безгә: «Сез дә имзалагыз Федератив договорны! Сезгә дә шундый ук ташламалар бирербез», – дип, кылыбызны тартып карады. (Җөмләдән, Саханы да Мәскәү шул ук шартларда үз тарафына аударган иде.) Ләкин Татарстан үз позициясендә нык торды. Соңрак Тишков безнең ныклыкны чакма ташы белән чагыштырды.

Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар, ди халык әйтеме… Әйе, Россия җитәкчелеге борынгы Римның «бүлгәлә һәм хакимлек ит!» традициясен бу юлы да уңышлы файдаланды, Башкортстан белән Саханы Татарстаннан читләштерә алды. Вакыты җиткәч, бу республикалар өчен ясалган ташлама-вәгъдәләр юкка чыгарылды. Аларның берсенә дә үзләрендәге җир асты байлыклары тәтемәде…

Татарстан исә, Бурбулис әйтмешли, башкалар өчен әхлакый үрнәк булды. Ул 1994 елның 15 февралендә ике яклы шартнамәләр төзүгә ирешеп, Россияне федератив рельсларга бастыра алды. Татарстан тәҗрибәсе дөнья тарафыннан да танылды. Ул үзәк һәм төбәкләр арасындагы конфликтны «йодрыксыз» хәл итү юлын ачты. Әйтик, Рамбуйе шәһәрендә Косово проблемасы тикшерелгән вакытта уртак өстәлгә Татарстан белән Россия арасында төзелгән шартнамә салынган иде.

…Чигенүләр тукталыр. Татарстан тәкъдим иткән демократик федерация кору юлыннан бармаса, Россиянең бербөтен дәүләт сыйфатында сакланып калуы икеле.

Аллага шөкер, сөтебез куе. Без – дәүләти халык. Вакыты җиткәч, Ватаныбыз кайтыр. Бу турыда бернинди шик булырга мөмкин түгел. ■

Безнең мирас №2 февраль 2022

# Кондырча сугышы яки Аксак Тимер һәйкәлгә лаекмы?

**Илнур Миргалиев**

**Борынгы Болгар. Реконструкция.** ***Чыганак: livelib.ru***

2021 елның азагында татар дөньясын дулкынландырган хәбәр таралды. Ул да булса – Үзбәкстан хөкүмәтенең Алтын Урда һәм башка төрки-мөселман илдәүләтләрен җимергән, Урта Азиядәге Чагатай иленең әмире Аксак Тимергә, аның гаскәр башлыкларына Самара өлкәсендә һәйкәл куярга дигән карары.

Соңгы елларда Самара өлкәсендәге Иске Буян авылы янында, Кондырча сугышына багышлап, «Русь: берләшү чоры» дип исемләнгән фестиваль үткәрелә. Ике гаскәрнең бәрелеше булган урынны якынча гына фараз кылып, биек хач та куела. Бер урыс язучысының Туктамыш ханны төрлечә сүккән романын да тараталар. Шуның өстенә, Үзбәкстаннан бию ансамбльләре килеп, «бәйрәм»гә «ямь» өстәп китә, кунакларны пылау пешереп тә сыйлыйлар. Татар дәшми торгач, инде менә һәйкәл дә куярга булганнар…

Дөрес, соң булса да, татар җәмәгатьчелеге әлеге эшкә каршы фикерен күпсанлы хатлар, мөрәҗәгатьләр аша белдерде. Үзбәкләрнең һәйкәл кую теләге гамәлгә ашмас дип уйлыйк.

# Аксак Тимер Туктамышны алдый

Алтын Урда XIV гасырда дөньяның иң көчле, алга киткән, бай дәүләтеннән санала. Төрле афәт-казалар чорнап алган XIV гасырның икенче яртысында татарның бөек заты Туктамыш хан пәйда була. Ул 1380 елда тәхеткә утыра һәм Татар иле яңадан көч-куәт җыя башлый.

Нәкъ шушы елларда Урта Азиядәге Чагатай дәүләтенең әмире Тимер, көчле дәүләт корып, күрше илләрне талау һәм үзенә буйсындыру сәясәтен киң җәелдереп җибәрә. Шуны да искәртү урынлы булыр: Алтын Урда тәхете өчен көрәшеп йөргән вакытта Туктамышны Ырыс хан юк итәргә тели. Каты яраланган Туктамышны 1378 елның кышында әле яңа гына күтәрелеп килгән Тимер иленә алып киләләр. Шуны истә тотып, Туктамыш башта әмиргә каршы чыгарга теләми, сак эш итә. Әмма ул алып барган сәясәт Алтын Урда мәнфәгатьләренә тискәре йогынты ясый башлагач, ике ил арасында киеренкелек арта, 1385 елда сугыш башлана. 1390 елда, сугыш туктатылып, ике ил арасында солых төзелергә тиеш була. Туктамыш хан Тимергә үз илчеләрен җибәрә. Әмма Чагатай әмире ханны алдый, аның илчеләрен әсир итеп, Алтын Урдага зур гаскәр белән бәреп керә.

**Туктамыш хан.** ***Р.Шәмсетдинов рәсеме***

Туктамыш, илен саклау өчен, аяусыз көрәш башлый. Ике дәүләт арасында яңадан сугыш башланып китә. Татар ханы гаскәрен тиз генә даланың төньяк чигендә җыярга карар бирә һәм яңа стратегик план кабул итә. Бер төркем татар гаскәре дошманның алдында күренеп бара, аларны уяу торырга мәҗбүр итә. Шулай итеп, ул каршы тарафны көчсезләндерергә тырыша. Нәтиҗәдә, урта азиялеләр гаскәре даланы тулысынча кичеп, Идел ярына ук килеп җитә. Шуны да әйтергә кирәк: Туктамыш хан күпкырлы сәясәт алып бара, сугыш кырында дипломатияне дә кулланa, Тимергә каршы бөек дәүләтләрнең берлеген төзергә омтыла.

1391 елның җәендә булган бу хәрби конфликт тарихта Кондырча сугышы буларак билгеле. Биредә татар гаскәре, тар-мар ителмәсә дә, чигенергә мәҗбүр була.

# Татар халкы Аксак Тимер һәйкәленә каршы!

Нык нигезле фаразларга таянып, шуны да өстисе килә: бүгенге Самара өлкәсенең Камышлы җирлегендә туган урта гасыр татар шагыйре Сәйф Сараи Туктамышның якыннарыннан, тугры тарафдарларыннан була. Хан аны Мисыр дәүләтенә үз илчесе итеп тә җибәрә.

Сәйф Сараи – танылган дәүләт эшлеклесе. Ул урта гасырның иң зур коалициясен корырга ирешә, туган иленә зур хезмәтләр куя. Аның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» исемле әсәре нәкъ менә шушы вакыйгаларга багышланган да инде.

Ул вакытта Тимергә каршы тора алырлык өч зур илне санап китәргә мөмкин: Алтын Урда, Мәмлүкләр Мисыры һәм Госманлы дәүләте. Соңгы икесенең Аурупаның «тәре йөртүчеләр»е белән сугышлар алып баруы сәбәпле, Тимер фетнәсе белән көрәштә төп авырлык Алтын Урда өстенә төшә. 1391 елда Аксак Тимер, бу форсаттан файдаланып, татар дәүләтен юк итәргә була да инде.

Ул вакытта Туктамыш бөтен төрки-мөселман дөньясының лидерына әйләнә. Татарларны өметсезлеккә төшмәскә, куркып калмаска өндәп, Сивас әмире, шагыйрь һәм галим Әхмәд Борһанетдин шундый шигырь яза:

*«Әҗәлдә Хак нә язмыш исә булыр,*
*Күз нәйи ки күрәчәк исә күрер.*
*Ики галәмдә Хакка сыгынмышыз,*
*Туктамыш нә ула, йә аксак Тимер».*

Көньяк Иран халкы белән төрекмәннәр дә Тимергә каршы баш күтәрә. Алар Туктамыш хан исеменә хөтбә укый һәм акчаларын да татар ханы исеме белән суга башлыйлар.

Ә менә танылган сукыр шагыйрь Әхмәд Үргәнчи Тимергә ләгънәтләр яудыра, мәшһүр фикһ галиме Хафизетдин әл-Бәззази үзенең «Әл-Фәтава әл-Бәззазиййа» исемле әсәрендә Тимерне кяфер дип атый. Белүебезчә, татар фольклорының кадерле ядкяре булган «Дәфтәре Чыңгызнамә» дастанында да Тимер тискәре яктан гына тасвирлана. Аңа үзе яшәгән вакытында ук Аксак Тимер дип дәшәләр. Ул, хакимияткә килгәнче юлбасарлар башлыгы булып, талау-үтерү белән шөгыльләнә һәм үзен эзәрлекләүчеләр тарафыннан җәрәхәтләнеп, аягы имгәнеп кала. Хәтта урыс елъязмаларында да «Повесть о Темир-Аксаке» дигән аерым бер әсәр бар. Урта Азиядән тимериләрне куып чыгарган шәйбанилар белән тыгыз һәм дустанә элемтәдә торган Казан ханы Мөхәммәтәмин үзенең «Гыйкаб» («Үч») исемле шигырендә Тимергә ахирәттә каты җәза булачагын искәртә:

*«Чыкты һиҗри белән җиде йөз илледәд –*
*Төште галәмгә җир тетрәү кебек хараблык.*
*Үзе аксак, гакылы – ахмак, фетнә иясе*
*Золымын таратты һәр җиргә.*
*Күп галимнәр һәм шәйхләр шәһид*
*Булдылар ислам дине юлында.*
*(Аның) фетнәсеннән ислам йорты, ачык бел,*
*Туздырылды, хәвефтән күз яшьләре акты.*

*Ни җавап бирер ул Хода каршында, –*
*(Әгәр дә) Алла каты җәзага тартса.*
*Йа Илаһым, ул бәндәңне син теге дөньяда*
*Ит залимнәр һәм җаһилләр рәтендә».*

Татар үзаңында бу вакыйгалар тирән эз калдырган. Туктамыш Литва кенәзе Ягайлыга язган хатында 1391 елгы сугыш турында тәфсилләп аңлаткан. Бәрелеш Тимер илбасарларының өстен чыгуы белән тәмамлана. Туктамыш чигенергә мәҗбүр була һәм, Идел елгасын кичеп, төньяккарак, урманлы җирләргә килеп төпләнә. Безнең уебызча, ул хәзерге Казан шәһәре тирәләренә сыенган булырга тиеш. Татар шәҗәрәләре белгече Марсель Әхмәтҗанов Туктамыш хан, Болгар олысын урыс ушкуйникларыннан саклар өчен, күп кенә Алтын Урда татарларын бирегә күчергән, ди. Галим Казан арты районнарында һәм Киров өлкәсендә яшәгән татарларның тарихында Туктамыш гаскәрләре мөһим роль уйнаганын әйтә.

Туктамыш хан Ягайлыга язган хатында чигенү сәбәбен кайбер гаскәр башлыкларының Тимергә сатылуы белән бәйләп аңлата, алар арасында Идегәйне дә искә ала. Белүебезчә, үз илен саткан Идегәй һәм аңа бәйле вакыйгаларның фаҗигасе дастан аша хәзерге көнгә кадәр килеп җиткән. Бу дастанда Туктамыш-Тимер мөнәсәбәтләре, Идегәйнең фетнәсе, илгә килгән бәла-казалар турында бик тәфсилле бәян ителә.

## Таңнан төнгә чаклы сугыш

Киң даланы кичкән Тимер тиз арада Туктамыш белән сугышырга кирәк икәнен яхшы аңлый, чөнки Идел елгасын йөзеп чыгарга ул җөрьәт итмәс иде. Хәтта татарларны чигенергә мәҗбүр иткәч тә, ул Иделне кичәргә базмый, кире китүне хуп күрә. Шуңа күрә Тимер авангардын алга җибәрә һәм, Туктамыш гаскәренә һөҗүм итеп, аны туктарга мәҗбүр итә. Туктамыш, әле гаскәрләрен җыеп өлгермәгән булганлыктан, Тимергә Җаек елгасын кичкәндә һөҗүм итәргә план корган була. Әмма сугышырга мәҗбүр ителгәч, гаскәрен Кондырча һәм Сок елгалары буена урнаштыра. Тимер гаскәре исә Кондырчаның Сок белән кушылган җирендә була. Ул татарларны Иделдән аерып алырга тели, әйткәнемчә, олы елганың аръягына чыгарга курка, көч-куәтенә ышанмый. Тимер, Иделне кичә калса, икенче татар гаскәре белән дә сугышырга туры киләчәген бик яхшы аңлый. Ә Туктамыш янында сул кул гаскәрләре генә була. Аксак Тимер, Туктамышның уң кул гаскәрләре читтә булудан файдаланып, тиз арада сугышка омтыла.

1391 елның 18 июнендә Кондырча елгасы буенда каты бәрелеш була. Таңнан төнгә чаклы сугыш... Нәтиҗәдә, татар гаскәре төрле якларга чигенә. Туктамыш хан Иделне кичеп чыгарга омтыла. Бу бик авыр була, чөнки дошман гаскәре нәкъ менә татарларны Идел аша үткәрмәскә тырыша. Әмма Туктамыш, берничә гаскәр башлыгы хыянәт иткәнен белгәч, тиз арада Иделнең уң ягына чыгарга карар кыла, андагы уң кул гаскәрен алып, дошман белән яңадан сугышырга уйлый.

Әйтергә кирәк, Кондырча бәрелеше урта гасырның иң зур һәм хәлиткеч сугышларыннан санала. Чыганаклар гаскәрләрнең берничә йөз мең кешедән торганлыгын язсалар да, безнең уебызча, һәр яктан илле меңгә якын хәрби катнашкан булырга тиеш. Югалтулар ике яктан да бик күп санда. Нәтиҗәдә, Аксак Тимернең татар гаскәрен куып барырга көче калмый, ул кире үз юлы белән Сәмәркандка кайтып китә.

# Явызлык моның белән генә бетми...

Дошманнар икенче бәрелешкә чаклы аерылыша. Тимернең яңадан яу белән киләчәген һәм Алтын Урданың тиз арада зур сугышка яхшы әзерләнә алмаячагын аңлаган Туктамыш хан аңа каршы көчле дәүләтләрнең гаскәри берлеген төзергә керешә.

Кондырча бәрелеше Туктамышка шундый дәрес бирә: моннан соң Чагатай әмиренә ышанмаска һәм аның белән җиңгәнче көрәшергә. Солых төзибез дип җибәргән илчеңне әсир итеп алган һәм яу белән килгән кешегә тагын нинди ышаныч булырга мөмкин?! Моннан тыш, Аксак Тимер Алтын Урдадагы Үргәнеч шәһәрен җимерә, мәдәният үзәге булган урында ялан кыр гына кала. Башкисәр әмир Туктамышның әнисе ягыннан туганнарын үтертә, мәмләкәт аша үткән мәшһүр «Ефәк юлы»н талап, сәүдә кәрваннарын тар-мар итә, Алтын Урда тарафдарларын юкка чыгара, аңа чиктәш илләрне бер-бер артлы басып ала.

«Идегәй» дастанында Туктамыш, мин хәзер үзем дә Чыңгыз булдым, ди, чөнки ул, чыңгызи буларак, җимерелеп баручы чыңгызи илләренең лидерына әйләнә. Элеккеге татар ханнары кебек үк, Туктамыш та Хулагулар иле Иранны үз йогынтысына алу максатына керешә, әмма Тимер аның каршысына чыга.

Аксак Тимернең вәхшилекләре турында күп чыганаклар хәбәр итә. Һиндстанда 100 мең әсирнең башын чаптырганлыгы, әсир хатын-кызлар һәм балаларны атлы гаскәрләре белән таптатып үтергәне, Сивас халкын тереләй күмүе Тимернең үз тарихчылары тарафыннан да тәфсилләп язып калдырылган. Әлбәттә, бу вәхшилек Туктамышка да тәэсир иткәндер, әмирнең явызлыкларын күреп, ул аңа каршы торырга уйлагандыр, дип әйтергә мөмкин. Хәтта илен саткан Идегәй дә, форсат чыгу белән, Аксак Тимердән качып китә һәм янына кире чакырырга килгән аның нөкәрләренә шулай җавап бирә: «Тимергә әйтегез, моннан соң мин аның тарафын тотмыйм, чөнки Аллаһтан куркам».

> «
> **Урта гасырда татар халкына иң зур зыян салучы, Алтын Урда илен һәлак итүче бу илбасарга Россиядә һич кенә дә һәйкәл булырга тиеш түгел!**

Төрек елгасы буендагы сугыш алдыннан Тимер янында йөргән, хәтта аның белән шахмат уйнаган Көнчә углан да, төнлә җаен туры китереп, үз яраннары белән Туктамыш хан ягына кача. Шәрәфетдин Али Йәздинең әйтүенчә, «Ватанга булган мәхәббәте Көнчә угланны сукырайтты». Ул бу сугышта батырларча шәһид китә. Ватаны алдындагы гөнаһларын үз каны белән юа.

Аксак Тимер Алтын Урдага тагын бер кат бәреп керә. 1395-1396 нчы еллардагы сугышларда да татарлар бик күп батырлыклар күрсәтә. Анда катнашкан шәхесләребез киләчәктә яхшылап өйрәнелер, Йаглы бәй, Удурку һәм башка мәшһүр татар гаскәр башлыклары турында романнар язылыр, фильмнар төшерелер дип ышанасы килә.

Бу сугышта Аксак Тимер татар шәһәрләрен җимереп, талап, халкын кылычтан кичерә. Түбән Идел буен, Алтын Урданың үзәк җирләрен коры далага әйләндерә, пайтәхет булган Сарай шәһәрен яндыра. Башкисәрнең Урта Иделгә үтеп кергәнлеге турында да мәгълүмат бар. Кызганыч, Алтын Урда Тимернең яуларыннан соң яңадан күтәрелеп китә алмый, бөлгенлеккә төшә һәм, 40-50 ел дәвамында барган чуалышлардан соң, аерым татар ханлыкларына таркала.

Урта гасырда татар халкына иң зур зыян салучы, Алтын Урда илен һәлак итүче бу илбасарга Россиядә һич кенә дә һәйкәл булырга тиеш түгел! ■

# Казан татарлары

*(Тарихи- этнографик очерк)*

**Аристарх Сперанский**

**Яшь татар гаиләсе**

*Бер илдә яшәп, уртак тормыш-көнкүреш, эш мөнәсәбәтләрендә торган күрше җирле халыкларның гореф-гадәтләрен, йолаларын белмәү, аз дигәндә, гамәл өчен файдасыз. Бу бигрәк тә аларның этнографияләрен белү, алар белән мөнәсәбәттә булган мәдәният эшлеклеләре, дин, чиркәү хезмәткәрләре, укытучылар, табиблар өчен кирәк. Биредә Казан шәһәрендә, Казан губернасында яшәгән татарлар турында иң мөһим һәм тормышта кирәк булырлык тарихи-этнографик мәгълүматларны гына китерәбез.*

***Автор***

# Казан татарлары – яуда җиңгән татарлар

Казан ханлыгы яулап алынганчыга кадәр, XVI гасырның беренче яртысыннан сакланган рус телендәге язма чыганакларда татарлар турында бер хәбәр дә юк. Бары тик 1229 елда Аврамий Болгарскийның фаҗигале һәлакәте турындагы хәбәрдә генә борынгы бабалары – болгарлар искә алына. Көнбатыш Европа язма чыганакларында Идел буе болгарлары хакында XIII гасырдан сакланган хәбәрләр бар. Татарлар һәм Идел буе болгарлары турында язма хәбәрләр шулай ук әрмән, грузин һәм грек тарихи чыганакларында да сакланган. Ничек кенә сәер күренмәсен, татарлар хакындагы иң җентекле, иң борынгы IX гасыр хәбәрләре кытайлардан калган. Алар татарларны өч ыруга бүлә: Амур елгасы янында яшәүче *су татарлары, дала татарлары, кара татарлар (монголлар)*. Әйтеп үтелгән чыганакларда татарларның, монгол-угыр халыклары нәселеннән булып, Европада, Азиядә яшәүләре турында һәм торган җирләренең географик атамасыннан чыгып, казан, енисей, алтай, тубыл, кырым татарлары һәм башка исемнәр йөртүләре әйтелгән.

«Татар» исемен кайберәүләр фарсы телендәге «тептеръ», ягъни колонист – күчеп килгән кеше дигән сүздән чыгара. Чөнки татарларның борынгы бабалары көнчыгыш Европаның буш җирләренә Азиядән күчеп килгәннәр. Без язган татарлар, Казан каласында һәм аның тирә-юнендә яшәгәнлектән, казан татарлары дип йөртеләләр. Әйтеп үтәргә кирәк, каланың исеме татарча, ә рус телендә «котел» була. Ләкин каланың исеме, кайберәүләр уйлавынча, имеш, бу урында табылган «казан»нан түгел, ә борынгы шәһәргә нигез салган Казан исемле татар морзасы хөрмәтенә куелган.

Казан каласы башта Казан өязенең Арча янындагы борынгы Камай авылы урынында төзелгән. Хәзерге җиргә монголлар явыннан соң, 1447 елда (башка риваять буенча, 1399 елда) Болгар патшалыгының Иске Казан каласын кулга алган һәм үзен Казан патшасы дип игълан иткән Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәд тарафыннан элеккеге Саин Йорты урынына (Яңа Казан, хәзерге Казанский-Федоров монастыре ) күчерелгән.

Казан татарлары губернаның барлык өязләрендә, ә күпчелеге Казан, Мамадыш, Тәтеш, Чистай, Лаеш, Зөя, Цивиль, Спас, Царевококшайск өязләрендә яшиләр. Алар барлыгы 482 089 кеше санала, кайбер чыганаклар буенча, 600 000, хәтта 650 000 диган хәбәр дә бар. Китерелгән өч санның соңгысын дөресрәк дип уйлыйбыз.

Казан татарлары – яуда җиңгән татарлар, мөселманлыкка авышкан фин-угырлар һәм борынгы болгарларның нәсел-токымнары. Болгар патшалыгы XIII гасырда көчле дәүләт булып җитешеп, XIV гасыр урталарында (1361 ел) монгол яулары тарафыннан җиңелеп, басып алынган. Яңа килгән басып алучылар, аз санлы булганлыктан, болгар мәдәниятенә кушылганнар, ислам динен кабул итеп, яңа динне Алтын Урдага да рәсми дин итеп алганнар. Җиңелгән Болгар патшалыгы туздырылган Биләр урынына калган Болгар каласы җитәкчелегендә мөстәкыйльлектә яши алмаган. Торгызылган болгар калалары барысы да монгол ханнары кул астында булып, болгар патшалары үзләренең хакимлекләрен Алтын Урдадан алганнар. Яуда җиңеп килгән күчмә татарлар элеккеге җир хуҗалары болгарлар биләмәсендә яшәгән чирмеш (мари), мордва, мишәр, вотяк (татарча – арлар) халыкларын үз йогынтыларына ала, үз хакимлекләренә буйсындыра башлаганнар.

Болгар патшалыгының байлыгы Батый (Бату, Саин хан) ханнан башлап татар ханнарын бик кызыктыра. Шунлыктан 1447 елда (башка риваятьләр буенча – 1399 елда), инде әйтеп үтелгәнчә, Урдадан куылган хан Олуг Мөхәммәд Болгар каласын алган, аны хәзерге Казан каласы урынына күчергән, үзен Казан патшасы дип игълан иткән. Болгар патшалыгы бетерелеп, Казан патшалыгы башланган. Мөселман болгарлар мөселман татарлар белән кушылганнар.

Югары катлам – Казан патшалыгы барлыкка килгән. Аның хәрби сыйныфын – татарлар, сәүдәгәрләр катламын – болгарлар, җир сөрүчеләрен чуашсуарлар тәшкил иткән. Җирле халык яңа хуҗаларга буйсындырылган, ислам диненә авыштырыла башлаган.

## Татарларның үз-үзләрен тотышлары шактый һавалы

Бу хәлләр 1552 елга кадәр – Казанны Мәскәү яулап алганчы шулай барган, җирле халыкның исламга тартылуы әле бүген дә дәвам итә. Шул сәбәптән татарларда төрки тип чалымы бик аз, башлыча фин-чуаш сурәте чагыла. Татарларның йөз-чырайлары җирле халык йогынтысында шактый үзгәргән, битләре озынча, күзләре соры, бары тик сирәк сакаллары, озын колак яфраклары гына төрки-монгол нәселеннән икәннәрен ачык күрсәтеп тора. Татарларда аларга кушылган җирле халыкның рәвеш-сыйфатлары бик нык чагылган.

Казан татарларының тышкы кыяфәте, буй-сыны бик җитеш. Бит-йөзләре озынча, күзләре зур, соры яисә кара, күз карашлары үткен, борыннары озын, еш кына көнчыгыш халыкларыныкы кебек бөркетнеке сымак күтәренкечыгынтылы, иреннәре калын, яңак сөякләре артык зур түгел, сакаллары кара төстә, пөхтә итеп тигезләп кыркылган, ирен тирәләре, башлары һәрвакыт чиста итеп кырылган һәм түбәтәй белән капланган; колак яфраклары зур, тырпаеп тора; муеннары кыска, юан, җилкәләре киң, күкрәкләре биек. Күбесе озын, төз, туры буйлы. Үз-үзләрен тотулары шактый һавалы, йөрешләре салмак, вәкарь белән. Байтагы калын гәүдәле. Хатын-кызлар да җитеш-тулы санлы, ирләре кебек, үзләрен вәкарь белән тоталар, киемнәре бик сыланып тормаганга, буйсын сылулыклары ачык күренми.

## Татар хатын-кызлары иртә картаялар

Соңгы елларда Казан татар хатын-кызлары, ирләр кебек үк, Азиядән килгән өс-баш киемнәрен Европа өлгеләреннән үрнәк алып ясалган, җайлырак фасоннарга алыштыралар. Татар хатын-кызлары арасында бик сөйкемле, бик чибәрләре күп, ләкин алар бик иртә картаялар. Кияүгә чыккан 27 яшьлек хатыннар бик тиз арада 40 яшьлеккә охшап кала. Моның беренче сәбәбе – алар бик яшьли кияүгә чыгалар, икенчесе – иннек-кершәннәр белән битләрен бозып, курчакка охшый башлыйлар. Карл Фукс язмаларына караганда, аларның тәннәре саргылт төстә. Каз мамыгыннан ясалган җылы, йомшак ястыкмендәрләрдә ятканга һәм авыр, җылы кием кигәнлектән, тиреләре еш кына табигый шомалык сыйфатын югалтып, купшаклана. Инде хәзер алдынгы, хәлле гаиләләрдә түшәк-ястыклар гади, гигиенага яраклашкан пружиналы матрацларга алыштырылалар.

# Татарлар рус халкы арасында милли горурлыгын саклап кала алган

Мәгълүм булганча, һәр халыкта яхшысы да, начары да бар. Татарларда да шулай. Өч йөз елдан да элегрәк буйсындырылып рус халкы арасына таратылган халык үзенең шаккаткыч күп үзенчәлекләрен, гореф-гадәтләрен, милли горурлыгын аерым яшәгән халык кебек саклап кала алган. Татарлар, чынлыкта, руслардан да, башка җирле халыклардан да аерым яшиләр, ата-бабаларыннан калган югары сыйфатларын, өстенлекләрен сакларга тырышалар. Алар үзләрен башка халыклардан аерып торган тарихи чыгышлары, диннәре, югары әхлак кагыйдәләре, тормыш-көнкүреш гадәтләре белән горурланалар.

> «Алар – намуслы, горурланырга яратучан, мал сөючән, сәүдәгә сәләтле халык. Татарлар укымышлы, үзара татулыкта, кунакчыллыкта яшиләр. Алар – чагыштырмача аек тормыш, чисталык яратучы халык.

Алар – намуслы, горурланырга яратучан, мал сөючән, сәүдәгә сәләтле халык. Татарлар – укымышлы, үзара татулыкта, кунакчыллыкта яшиләр. Алар чагыштырмача аек тормыш, чисталык яратучы халык. Әйтелгәнчә, алар бик кунакчыл. Таныш татар авылына кунакка чакырсалар, сез бик юмарт ашау-эчү сыеннан котыла алмассыз. Төп сый – баллы чәй. Аннан соң өстәлгә каймак яки сөт өсте, кура җиләге кагы, кыздырылган юка һәм десерт куела. Барысын да авыз итеп карарга кирәк. Әле болай гына бетми, кунак барын ишетеп кергән ике-өч кеше, таныш булмасалар да, сезне үзләренә кунакка чакыра, бармасаң, яхшы түгел, аларны үпкәләтәсең. Барсаң, шул ук мул сый-хөрмәт йорт саен кабатлана.

## Татарларның яраткан шөгыле – сәүдә кәсебе

Татарлар – җирбиләүчеләр, ләкин җирне сукалап эшкәртүне күрше чуаш һәм чирмешләр дәрәҗәсендә яратмыйлар. Татарларның яраткан шөгыле – сәүдә кәсебе, ул борынгы болгар бабаларыннан калган гадәт. Күчмә тормыштан сакланган сыйфатлары – ат ярату, ат асрауга зур игътибар бирү. Татарлар ат җигү, йөк ташу эшләрен башкаралар. Алар үзләрен руслардан өстен саныйлар. Татар кушаматы аларны гарьләндерә, алар үзләрен мөселманнар дип атыйлар. Татарлар арасында дини фанатиклар да бар, алар ислам кануннарын җирле мәҗүси халыкларга гына түгел, якыннан аралашып яшәгән русларга да тагарга тырышалар. Сәүдә эшләре белән Россиянең көнчыгыш өлкәләрендә йөргәнлектән, тугандаш төрки, фин-угыр халыкларына зур рухи йогынты ясыйлар. Укымышлылык аларда руслардагыдан күбрәк, ләкин ул дини белемгә нигезләнгән. Соңгы елларда татарларда Европа мәгърифәтенә омтылу бик зур, шунлыктан бу өлкәдә ике агым барлыкка килде: мәдрәсәләрдә элеккеге дини белемне өйрәнү юнәлеше һәм дәүләт мәктәпләрендә алдынгы Европа фәннәрен укыту. Хәзер татарлар балаларын дини мәктәп-мәдрәсәләргә түгел, рус-татар дәүләт училищеларына, школаларга бирәләр.

Татар хатыннары

Бер үк вакытта татарлар арасында милләтчелек тә үсә, күрше халыкларны ислам аркылы татарлыкка күчәргә өндәү арта, халыкка төркилек хисләре сеңдерелә, Төркестан дәүләте оештыру турындагы хыяллар уятыла.

Тик күрше халыкларның барысы да татарлар сүзен хупламый. Болын чирмешләре, борынгы җирле халык буларак, татарларны, болгарлар белән катнашлыкларыннан чыгып, «суас», ягъни чуаш дип йөриләр. Татарларны мишәрләр дә (борынгы мордва нәселләре – мещералар) чуашлар дип атый. Чуаш йогынтысында булган тау чирмешләре (дөресрәге, башта чуаш дигән халык булмый, чирмешләр генә. – *Ред.*) татарларны суас дип түгел, тодор дип йөриләр. Бу исемне алар татарларны шулай атаучы чуашларга ияреп әйтәләр.

## Татарлар ел саен йөзләрчә исемдәге китап бастыралар

Татарчылыкның үзәге – Казан. Биредә 25 000 татар кешесе яши. Алар бары да ике бистәдә, шәһәрдән көньякта, Идел ягында гомер итә. Барлык татарлар да Казан белән бик тыгыз элемтәдә тора: Казан мәдрәсәләреннән муллалар китертәләр, татар типографияләреннән китаплар алалар. Татар укымышлылары гарәп, татар, фарсы һәм төрекләрдән алынган сүзләр катнаштырып, үзенчәлекле тел оештырган. Бу сөйләмдә чит тел сүзләренең күплеге кешенең укымышлылык дәрәҗәсенең югарылыгын күрсәтә. Татарларның әлифбалары гарәп графикасына нигезләнгән. Татарлар ел саен йөзләрчә исемдәге китап бастыралар. Аларда китап тарату изге, саваплы эш санала. Элек дини китаплар гына булса, хәзер инде төрле мәдәни әдәбият та басыла. Әйтеп үтәргә кирәк: урта, югары белем алган, рус җәмгыяте белән элемтәдә торган рус телен кулланучы, Европа гыйлеменнән хәбәрле татарлар белемнәрен халыкта милли хис-тойгылар, уй-фикерләр тудыру өчен файдаланалар. Инде татар китапханәләре, клублар бар, татар телендә әдәби кичәләр уздырыла, театрлар оештырыла.

## Иске керәшеннәр ислам диненә күчүдән сакланды

Татарлар исәбенә «керәшен»нәрне дә кушалар. Керәшеннәр алар йә болгарлар, йә татарга әйләнгән фин-угырлар. Алар ике вакытта чукындырылганнар: Казан алынганнан соң һәм XVIII гасырда. Беренчеләре – иске, икенчеләре яңа керәшеннәр дип йөртелә. Иске керәшеннәр, чукындырылганчы ислам динендә саналсалар да, XIX гасыр урталарына кадәр үзләренең мәҗүсилек йолаларын саклап калганнар, ә ислам дине йогынтысын тирәнрәк үзләштереп өлгергән яңа керәшеннәр XIX гасырның икенче яртысында барысы да диярлек яңадан мөселман диненә кайттылар.

Иске керәшеннәр исә христианлыкта калдылар (Казан губернасында керәшеннәр саны – 42 609 кеше). Дини халәтләре төрле төбәктә төрлечә булса да, мөселман татарлар арасында яшәүләренә карамастан, христиан школалары аларны исламга чыгудан саклап калды. Бу эштә ана телендә укытучы керәшен татарлары школалары, дини китапларны ана телендә бастыру, чиркәү йолаларын татар телендә үтәү зур ярдәм итте. Халыкка дини китапларны ана телендә җиткерү, чиркәү хезмәтләрен татар телендә башкару, школаларда

рус графикасында язылган татарча китаплар куллану керәшеннәрне исламга кайтудан саклап калды. Бу гамәлләрне Казан Җирле халыклар семинариясе директоры Н.И.Ильминский башкарды. Казанда ул оештырган Керәшен татарлары школасы әзерләгән укытучылар керәшеннәрдә дини аңны үстереп, аларда русча укуга омтылыш теләге тудырды. Шулай итеп, Ильминский школалары һәм чиркәү хезмәткәрләре ярдәмендә, иске керәшеннәр ислам диненә күчүдән сакланды дип әйтергә була.

## Русларда диндарлык җитешми

Ислам диненә кире кайтучы керәшен татарларының саны – 32 000 кеше. Шундый күплек узган гасырның алтмышынчы еллар (1860) хәрәкәте нәтиҗәсе. Губернада чиркәүдән яңа тайпылучылар саны – 1500 кеше. Бу – 1904-1905 нче азатлык өчен көрәшү еллары.

Христианлыктан китүнең төп сәбәпләре: дин өйрәтүләрен белмәү, авылларда чиркәүләрнең аз, аралары ерак булу, исламга табигый тартылу һәм мөселман кардәшләренең дини йогынтысы. Русларда диндарлык җитешми. Соңгы елларда бу юнәлештә руслар тарафыннан зур эш алып барыла, нәтиҗәдә, христианлыкны ташлау хәбәрләре сирәк килә. Исламга күчкән керәшеннәр соңгы елларга кадәр христиан булып саналдылар, ләкин мөселман булып яшәделәр, икешәр исем йөрттеләр: керәшенчә дә, татарча да. Аларга бик тыгыз берләшкән дини фанатик татар сәүдәгәрләре зур ярдәм күрсәтте, русларның бу мәсьәләгә битарафлыгы моңа юл куйды. Шулай да алар ташлаган диннәрен заман авырлыклары килгән елларда исләренә төшерәләр.

> «
> **Аларның хезмәте зур файда бирми: эшне соң башлыйлар, иртә бетерәләр, акрын эшлиләр, ашарга өчәр мәртәбә тукталалар. Шунлыктан, бер үк эшне русларга караганда икешәр мәртәбә озаграк башкаралар.**

## Татарның хезмәте зур файда бирми: ашарга өчәр мәртәбә тукталалар

Казан татарлары үзләренең милли гадәтләрен саклап калганлыктан, этнографлар өчен аларның тормыш-көнкүреш кагыйдәләрен, көндәлек йолаларын өйрәнү бик кызык.

Татарларны төп өч сыйныфка бүләргә була: сәүдәгәрләр, мещаннар, крестьяннар. Беренче ике сыйныф башлыча Казанда, ә крестьяннар өязләрдә яши. Әйтергә кирәк: татар крестьяннары барысы да игенчелектә түгел, игәргә җир азлыктан, алар Казанда татарларның һәм русларның сабын ясау, тире эшкәртү заводларында эшлиләр, ат олавы белән йөк ташыйлар. Аларның хезмәте зур файда бирми: эшне соң башлыйлар, иртә бетерәләр, акрын эшлиләр, ашарга өчәр мәртәбә тукталалар. Шунлыктан, бер үк эшне русларга караганда икешәр мәртәбә озаграк башкаралар.

# Биредә хуҗа хатынның урыны, аңа ят кешегә күренергә ярамый...

Татарлар, руслар кебек үк, таш һәм агач йортларда яшиләр. Мещаннарның торагы, гадәттә, менә шундый: ишектән кергәч тә аш казаны куелган зур мич. Мич өстендә ике бакыр комган. Берсе – иргә, берсе – хатынына. Икесенә бер комганнан юыну тиеш түгел. Мич артындагы почмакта юыну өчен зур бакыр таз куелган, ике сөлге эленгән: берсе – бит-кул, икенчесе аяк сөртү өчен. Арырак, уң як стена буенда – мамык түшәк-ястык өчен киң сәке. Пәрдә булмаса, аларны стена буена өеп куялар. Ишеккә каршы – эскәтер япкан өстәл, зур булмаган көзге. Сул якта – чәй савыт-сабалары, табак-савытлар, подногслар куелган өстәл, ә самавыр һәрвакыт мич янында тора. Стена янында берничә гади урындык. Өстәлләр арасында матур бизәкле сандыклар. Алар матур япма белән капланган, бүлмәгә ямь биреп тора. Ишеккә каршы түр стенада зур булмаган көзге. Өстәлләр янында идәндә келәмнәр, тәрәзә төпләрендә бохар кынасы, башка хуш исле гөлләр.

> «Күгәрченнәр гөрләве аларга хатыннарына мәхәббәтләрен искә төшереп тора, күрәсең.

Олы мичтән уң як стенага кадәр пәрдә ябылган – биредә хуҗа хатынның ашау урыны, йортта кунаклар булганда аңа ят кешегә күренергә ярамый. Шул ук максаттан, авылларда йорт алдында, куе куаклар утыртып, түр бакча ясыйлар. Хуҗа, гадәтенчә, малайлар яисә кунаклар белән утыра, хатыны аларга аш-су китереп йөри. Өй алдының арткы яктагы бәләкәй, мичсез бүлмәсендә туннар, кием-салым, төрле вак-төяк саклана, җәй көннәрендә хуҗалар шунда йоклый. Югары хәлле татарларның йортлары да шундый ук, бераз байлык белән генә аерылып тора. Стеналары буяла, төрле күренешләр дә төшерелә: урман-кыр, диңгез, кораблар һ.б. Адәм, хайван, кош-корт рәсемнәре бервакытта да булмый, чөнки җан иясенең сурәтен ясау катгый тыелган.

Бүлмәләрдә йомшак җиһазлар, өч яклы зур көзгеләр куела, идәнгә фарсы келәмнәре җәяләр.

Бүлмәнең почмакларында кызыл агачтан ясалган затлы комодлар, табак-савыт киштәләре. Ләкин шкафларда көмеш кашыклар юк, тыелган, ә менә яхшы, хәтта затлы кытай фарфоры байтак. Бер бүлмәдә татарлар өчен иң кирәкле әйбер: зур юыну тазы, аның янында ике чиккән сөлге, алардан югары хуҗаның мәчеткә барганда урый торган ак чалмасы эленгән.

Бай татарларның бүлмәләрендә, гөлләрдән тыш, кәндилләр, сәгатьләр, мисыр күгәрченнәренең читлекләре. Күгәрченнәр гөрләве аларга хатыннарына мәхәббәтләрен искә төшереп тора, күрәсең. Бай йортларының аерым бер махсус өстәлендә Коръән һәм башка дини китаплар ята. Татарларның алгы бүлмәләрендә бервакытта да хатын-кызлар күренми. Алар ирләргә керергә ярамаган түрге бүлмәләрдә яшиләр. Шунлыктан, кунакларга аш-суны да ирләр китереп тора. Татар хатыннарын кирәк вакытта күрүнең дә ничек кыен икәнен Фукс язмаларыннан укыйбыз: *«Мин, табиб буларак, берничә мәртәбә татар хатыннарын дәваладым. Шуларның берсен сөйләп китәм. Хуҗа мине алгы яктан берничә буш бүлмә аркылы йокы бүлмәсе ишегенә озатты. Шунда бер кар-*

*чыкны чакырып, мине авыру янына илтергә кушты, үзе анда кермәде. Авыру яткан йокы бүлмәсендә бай келәмнәр җәйгән киң сәке өстенә күпсанлы мендәрләр өелгән. Бөтен стеналарга туннар, хатын-кыз күлмәкләре эленгән. Келәмнәр белән капланган зәвыклы сандыклар урындыклар итеп файдаланыла. Авыру хатын чаршау артында каз мамыгыннан ясалган түшәктә ята. Мин, татарча белгәнемчә, авырудан йөрәк тибешен тикшерергә рөхсәт сорадым. Ул миңа чаршау астыннан алтын беләзекләр, көмеш тәңкәләр белән бизәлгән кулын сузды. Йөрәк тибешен тикшерү өчен, авыруның кулыннан бизәкләрен салуын сорарга туры килде. Авыруның хәлен җентекләп белер өчен телен карарга әби рөхсәт итмәде, шунлыктан, йөзен дә күреп булмады».*

## Татарлар милли киемгә тугрылыклы, әмма кәләпүшне ташлау күренешләре башланды

Татарларның өс-баш киеме күрше фин халыклары киеменә бик охшаш, бу, бәлки, татарлар арасында элеккеге финнардан чыгышлылар байтак булганлыктандыр. Соңгы елларга кадәр татарлар (ирләр һәм хатын-кызлар) милли киемгә тугрылыклы: кәвеш, азия читеге, киң шароварлар (киң төпле ыштан), озын, киң җиңле, якалы күлмәк, кәләпүш, бүрек, халат һәм бишмәт. Хатын-кызлар ирләр күзеннән халат белән каплана.

Инде яшьләр арасында Азия киемнәрен Европа модасына алмаштыру, озын чәч үстерү, кәләпүшне ташлау күренешләре башланды.

## Татарларның аппетитлары сокландыргыч

Татарларда ризык: мещаннар иртән ак икмәк белән чәй, өйләгә лапша белән сыер ите яисә пилмән ашый. Крестьяннарда ашау-эчү начаррак: иртән тозлы суда пешерелгән арыш оны (талкан). Өйләгә – салма (сарык маенда изеп ясалган камыр кисәкләре); җәй көне әче сөт (катык), кичкә тагын арыш оныннан пешергән болгатма.

Бәйрәм көннәрендә – сарык ите. Җыен, туй табыннарында, зур бәйрәм сыйларында – ат ите.

Байларда ашамлыкларның сыйфаты да, төрлелек күләме дә ярлыларныкы кебек түгел. Байларда ашау-эчү болай: иртән иртүк – сыер итеннән пешерелгән пәрәмәч белән чәй. Көн уртасында, әбәткә: 1) катык белән сыер итеннән ясалган пилмән яисә тары ярмасыннан йөзем кушып пешерелгән пылау; 2) тозлы кыяр белән ашарга түгәрәк ит бөккәне (вак бәлеш); 3) бәрәңге белән кыздырылган каз яисә үрдәк; 4) әче кәбестә яисә керән белән сыер ите; 5) сумала парында эшкәртелгән өрек җимеше; 6) бавырсак дип аталган бик вак, урман чикләвеге зурлык бөккәннәр белән чәй.

Кичке сәгать алтыда тагын каймак, иртәнге кебек, пәрәмәчләр белән чәй эчәләр. Кичкә – лапша, пилмән. Әйтергә кирәк, татарлар күп итеп майлы, баллы ризыкларны ашарга яраталар, аппетитлары сокландыргыч.

*Ахыры киләсе санда*

*Русчадан* ***Николай Петров-Текин*** *тәрҗемәсе* ■

# Истанбул мәктүбләре

Фатих Кәрими

Халидә ханым

1912 елның октябрендә алтын приискалары хуҗасы Закир әфәнде Рәмиевтән (шагыйрь Дәрдемәнд) «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатих Кәримигә мондый эчтәлектәге хат килеп төшә: *«Әгәр сугыш җиренә «Вакыт»ка мөхбирлек кылу (хәбәрче булу) өчен баруны зарур тапсагыз вә мөмкинлек булса, барырга ярый. Төрекчәгез өстенә французчагыз да булганлыктан, ихтимал ки, анда үзегезнең баруыгыз яхшырак булыр иде».* Шулай итеп, Ф.Кәрими ут эченә – Балкан сугышына юл тота. Ул яраланган төрек кардәшләребезгә ярдәм итәр өчен, яшь шәфкать туташлары – Чистайның Закир ишан кызы Гөлсем Камалованы, Петербургтан Рокыя Юнысованы, Ташкенттан Мәрьям Ягъкубованы һәм Ростовтан Мәрьям Поташеваны да Төркиягә чакыра.

Әлеге сәфәрнең нәтиҗәсе буларак, хәбәрче «Шура» журналына барлыгы 70 мәктүб, ягъни хат юнәлтә, 1913 елда алар аерым китап булып та басылып чыга.

Фатих Кәриминең «Истанбул мәктүбләре»ндәге 1-19 нчы хатлар 2000 нче елларда «Мирас» журналының берничә санында кабат дөнья күргән иде. Замнында аны басмага галим Энгель Нигъмәтуллин әзерләде.

Ә хәзер, 20 нче хаттан башлап, әлеге тиңсез хәзинә белән танышуны дәвам итәбез.

## 20 нче хат
## Халидә ханым хозурында

Хәзерге Төркиянең иң мәшһүр әдипләреннән берсе вә беренчесе Халидә ханымдыр. Халидә ханымның әсәрләрен яңа фикерле төрекләр бик сөеп укыйлар. Чөнки ул төрекчә яза, төрекчә төшенә вә каләмнең очыннан тамган каралары милли хәят чишмәләреннән алына. Аның иң зур хасияте дә шундадыр.

Халидә ханым хикәяләр вә романнар яза, мөгаллимлек итә, төрек хатыннарының тәрәккъый вә тәгалисе хакында фикер йөртә вә мөмкин булган кадәресен гамәлгә куярга тырыша. Шул сәбәпле, милләтен сөйгән төрекләр Халидә ханымны бөтен калебләреннән хөрмәт итәләр, аны төркилек истикъбаленең *(киләчәгенең)* йолдызларыннан берсе дип саныйлар вә аның вөҗүде илә ифтихар итәләр *(аның барлыгы белән горурланалар)*. Ялңыз төрекләр генә түгел, төркилекне таныргa теләгән Яурупалылар да Халидә ханым илә күрешүне, аның фикерләре илә танышуны үзләренә лязем *(тиеш, кирәк)* дип беләләр. Истанбулга килеп тә төрек хатыннарының хәят вә мәгыйшәтләреннән хәбәр алырга теләгән әҗнәби *(чит ил)* мөхәррир вә мөхәррирәләр, әлбәттә, Халидә ханым илә күрешми калмыйлар.

Халидә ханым, төрекчәдәге вакыф вә кәмаләте өстенә, Истанбулдагы Америка мәктәбендә мөкәммәл сурәттә инглизчә, французча тәхсил иткән *(укыган)*. Ул телләрдә теләгәнчә укый, яза, сөйли вә инглизчә мәҗмугаларда мөхәррирәлек итә. Лязем булганда француз газеталарында үзенең фикерләрен яза, төрек хатыннары хакында язылган хата фикерләрне тәсхих итә *(төзәтә)*. Хөласа *(кыскасы)*, әсәрләре, язулары вә фикерләре илә, Халидә ханым – чын мәгънәле әдибә, мөхәррирә вә мөтәфәккирә *(фикерле)* бер хатындыр. Шул сәбәпле, Халидә ханым илә күрешеп, биззат *(шәхсән)* аның үзеннән фикерләрен ишетүне күңелемез бик теләде. Хосусән, рус гали *(югары)* мәктәпләрендә укучы вә бунда Һиляле Әхмәр хастаханәсендә мәҗрухлар *(яралыларны)* караучы Гөлсем, Рокыя вә Мәрьям ханымнарның аның илә күрешеп әфкяр вә мәгълүматыннан мөстәфид булулары гарыз ителде *(фикерләре һәм белемнәреннән файда алулары соралды)*.

Шуңа күрә, озын зиярәт итмәк *(күрешү)* өчен, Халидә ханымнан элек вакытын сорап мөсагадә *(рөхсәт)* алдык. Латыйфән мөсагадә бирде. Тәгаен ителгән вакытта янымызда Йосыф әфәнде Акчурин вә Гариф әфәнде Кәримов та улдыгы хәлдә югарыда мәзкүр *(искә алынган)* ханымнар илә бәрабәр аның өенә киттек.

Аның Кадырга җаддәсендәге, Мәрмәр диңгезенә караган гүзәл манзаралы өенә барып кердегемез вакыт безне гаять хуш каршы алдылар. Югары катка чыгып, кунак бүлмәсенә кердегемез вакыт Яурупача киенгән, җилкәсенә гүзәл генә итеп ефәк яулык салган яшь бер ханымга Йосыф әфәнде безне тәкъдим итте вә аның Халидә ханым икәнлеген белдерде. Үзе илә күрешмәк шәрәфенә наил улдыгымыз өчен тәшәккер бәян иттек. Ул да шималь төрекләренең *(ягъни казан татарларының)* мөхәррирләре вә хосусән гали мәктәпләрдә укучы һәм мәҗрухлар *(яралыларны)* карарга килеп, хамиять *(ярдәм)* күрсәтүче һәмширәләре *(сеңелләре)* илә танышуы өчен бик мәмнүн улдыгын сөйләде. Соңра безне шунда булган икенче бер ханымга тәкъдим итеп, аның Истанбулда беренче мәртәбә ачылган кызлар игъдидаи мәктәбенең мөдирәсе Нәкыя ханым икәнлеген белдерде. Ул төрекчә киенгән, ләкин йөзе ачык иде.

Халидә ханым ачык йөзле, ачык сүзле, тәкәллефсез бер зат икән. Шул сәбәпле арада сүз бик тиз башланды. Ул безнең ханымнардан русияле мөслимәләрнең әхвален сорашырга башлады: «Мәктәпләрдә укыйлармы? Үзләренә махсус җәмгыятьләре бармы? Кызлар тәрбиясе ни хәлдәдер? Араларында язу илә шөгыльләнүчеләр бармы?» – диде.

Бунларга каршы мөнасиб җаваплар бирелгәч, Халидә ханым: «Затән, Русия мөселманнарының мәгариф вә тәрәкъкый юлындагы яхшы хәрәкәтләрен ишетеп, мин электән дә бик мәмнүн идем, инде андагы мөслимәләрнең үз вә рус мәктәпләрендә шулай укырга башлаулары, укыганнарының үз халкыңыз арасына китеп хезмәт итүләре, Уфада вә Оренбургта мөслимәләргә махсус җәмгыятьләр ачылуы, мөслимәләрдән шундый мөхәррирә вә әдибәләреңез булынуы әүвәлге сөенечләремне дәхи дә арттырды; бер милләтнең кызлары сезнең кеби гали мәктәпләрдә укый башлагач вә анларның да йөрәкләрендә миллият хисе уянгач, ул милләт югалмас, яшәр, мин буңа әминмен», – диде.

Мин Халидә ханымнан төрек ханымнарының әхвале гыйльмия вә фикрияләрен сорадым. «Анларның зыялы вә мөтәфәккирин кыйсме милләтнең хәл вә истикъбале *(киләчәге)* хакында ниләр төшенәләр?», – дидем. Буңа каршы Халидә ханым, хәзерендә яшь төрек хатын-кызларының бөтен куәтләре илә укырга бирелгәнлекләрен вә һәр шәйдә элек кызларның тәгълим *(уку)* вә тәрбия мәсьәләсен монтазам бер юлга куярга тиеш тапканлыкларын, шуннан башка бернәрсәгә дә керешүе мөмкин түгел игътикадында булынганлыкларын бәян итте.

Аның сүзләреннән аңлашылдыгына күрә, хөррият игъланыннан соң төрек ханымнары арасында яңа бер хәят башланган, кыз мәктәпләрен әсасеннән *(нигезеннән)* ислах итәргә *(яңартырга)* керешкәннәр, хатыннарга Истанбулда махсус клуб ачылган, хатыннарның тәрәкъкыяте фикрия *(фикер үсеше)* вә тәүсиге мәгълүматларына *(белемнәрен арттыру)* хезмәт өчен анда конферанслар бирелә башлаган вә, ниһаять, «Тәгалие нисван җәмгыяте» исемендә хатыннарга махсус бер җәмгыять ачканнар. Ләкин Төркия башына килгән дахили вә хариҗи *(эчке һәм тышкы)* бер чок фәлакәтләр *(төрле фаҗигаләр)* сәбәпле, бу эшләрне монтазам рәвештә тәрәкъкый иттерергә мөмкин булмаган вә,

Балкан сугышы башланганнан бирле, бу мөддәтле *(вакытлы)* хезмәтләрнең күбесе мөвәкъкатан *(вакытлыча)* тукталып торырга мәҗбүрият күрелгән.

Халидә ханым

Халидә ханымның истикъбаль *(киләчәк)* өчен өмидләре бик куәтледер: «Төрекләр кеби яхшы бер милләт, төрек хатыннары кеби яхшы вә саф әхлаклы аналарга малик *(ия)* булган бер кавем югалачак түгел, ихтимал ки, Төркиянең сәяси вазгыяте төрле хәлләргә керер, мондый хәлләр башка милләтләр башында да булып үткән. Ләкин төркилек бетмәс, аның истикъбале бик яктыдыр, монда һич шөбһә итәргә ярамый», – ди.

Халидә ханымның бу өмиденә дәлилләре дә бар: гомум төрекләрдә әхлак вә табигать яхшылыгы, аларның калебләрендә хәмияте миллия *(милли хис)* вә диния *(дини хис)* күплеге, төрек хатыннарының йорт җанлы, шәфкатьле вә мәрхәмәтле булуларыдыр. Мондый сыйфатларга малик *(ия, хуҗа)* булган бер кавемнең тәрәкъкый итмәве мөмкин түгел, бары сәбәпләре табылганны гына көтә, ул көннәрнең дә озак түгеллегенә галәмәт шушы, һәмширәләрем, дип, безнең ханымнарны күрсәтә.

Сүз Яурупа хатыннары хакында ачылды. Халидә ханым анларның хокук вә хөррият теләүләренә янә хак бирә. Һич шөбһәсез, хокук вә хөррият сәясендә генә тәрәкъкый вә сәгадәткә ирешү мөмкин, ди. Ләкин Әнгелтәрә *(Англия)* суфражисткаларының урамнарга чыгып сугышуларын, министрларга һөҗүм итүләрен, бомбалар куеп театрларны күтәртергә маташуларын ошатып бетерми; бунлар инде артыграк вә хатыннарның шанына килешми торган эшләр, ди.

Халидә ханым үзенең Яурупага сәяхәтләре вакытында төрле җирләрдә зыялы рус хатыннары илә очрашып сөйләштегене, анларның бик ачык фикерләре, күп мәгълүматлы булганлыкларыны вә төрле телләр белгәнлекләрене зикер итте.

Тел мәсьәләсенә килгәндә, Халидә ханымның фикеренчә, җәнүб *(көньяк)* вә шималь *(төньяк)* төрекләренең телләре әсасән *(нигездә)* бердер. Тик төрле җирләрдә булыну вә төрле тәэсирләргә табигъ *(дучар)* булу сәбәпле генә, бунлар арасында төрле шивәләр хасил булган. Госманлы төрекләренең телләре киткән саен сафлашачак вә шималь төрекләренеке дә киткән саен байыйачак вә нәзекләшәчәк, вә шул сурәтле бунлар табигый уларак тәдриҗән *(акрынлап)* берләшәчәкләрдер.

Гөлсем ханым Халидә ханымнан: «Ни өчен бу өйнең тәрәзәләрендә дә рәшәткәләр бар?» – дип сорады. Филхәкыйкать *(дөресен әйткәндә)*, Халидә ханым кебек чын мәгънәсе илә Яурупа тәрбиясе алган вә Яурупача төшенә белә торган хөр фикерле бер ханымның рәшәткәле тәрәзәләр эчендә ябылып торуы хәтергә алындыкта, бу сөаль мәгънәле вә урынлы иде. Халидә ханым буңа каршы ярым латыйфә уларак *(көлеп)*: «Гадәттер, әфәндем, ясактыр...» – дип җавап бирде.

Халидә ханымның бу җавабы рәсми җәһәттән тугры икәнлеге мондагы әхвальне белгән кешеләргә мәгълүмдер. Төрекләрнең хатыннарга назарлары *(карашлары)* Яурупаларныкына вә хәтта безнең Русия мөселманнарыныкына нисбәтән күп фәрекъле *(аермалы)* булганлыктан, могтабәр бер әдибәнең тәрәзәләре рәшәткәсез булынуы яки аның урамда Яурупача киенеп качмый йөрүе анлар каршында зур гаеп вә кабахәт саналачактыр. Хәтта төрекләрнең Яурупада укып кайтканнары арасында да хатыннарның качмый йөрүләре вә ирләр илә бәрабәр җыелышларда булынулары хакында карт төрекләр илә бертөсле үк төшенүчеләр бик күптер.

Хатыннарның качулары мәсьәләсе хакында сүз чыккач, Нәкыя ханым үзенең фикерен сөйләп, анларның эшләпә киюләрен ошатмаганлыгын бәян итте вә, һич булмаса, без шәрык хатыннары үземезгә махсус бер нәүгъ *(төрле)* гүзәл бер баш киеме чыгарырга тиеш, диде. Һәм дә бу ханым битләргә өртелгән пәрдәләрнең гыйлем вә мәгърифәт яктылыклары керүгә манигъ *(киртә)* түгеллегенә дә ишарәт итеп куйды. Сөйләгән сүзләреннән Нәкыя ханымның да гүзәл Яурупа тәрбиясе күргәнлеген вә инглизчә әдәбият вә газеталар моталәга иткәнлеге *(укыганлыгы)* аңлашыла иде.

Төркиядә вә бихосус *(аеруча)* бай вә кибар гаиләләр хакында бу ханымның фикеренә каршы игътираз итү *(сүз әйтү)*, ихтимал ки, хаклы булмас, ләкин Русиядәге вә Яурупа мәмләкәтләрендә укучы мөслимәләр хакында бу кагыйдәнең тәтбикы *(үтәлеше)* мөмкин түгеллеге әшкярдер *(ачыктыр)*.

Соңра сүз хәзерге сәяси хәлләргә күчеп, Халидә ханым «Times» газетасының соңгы номерында укыдыгы бәгъзе хәбәрләрне вә Асквит илә Грейның Төркиягә назарлары хакында үзенең бәгъзе фикереннән бик ачык аңлашыла иде. Мин аннан башка төрек ханымнарының сәяси эшләргә даир *(карата)* фикер йөртепйөртмәүләре хакында сорадым. Халидә ханым, көлемсерәп, хәтта кирәгеннән дә артыграк сәясәт белән шөгыльләнәләр, берничәсе бергә очраштылар исә, газета хәбәрләре вә сәяси эшләр хакында сөйләшеп фикер бәян итешәләр, диде.

Байтак мөддәт *(вакыт)* мосахәбәт *(әңгәмә)* иткәннең соңында, күңелләремездә гаять гүзәл тәэсир хасил итеп, Халидә ханымның хозурыннан чыктык вә хәкыйкатән мондый әдибәләре вә хәмиятьле *(булдыклы)* ханымнары җитешә башлаган төрек кавеменең яшәячәгенә иманымыз бик күп артты. Халидә ханымның басылып чыккан әсәрләре вә әдәбияттагы мәсләге хакында язуны башка бер вакытка калдырып торамыз.

*Дәвамы бар*

*Текстны басмага КФУдагы Халыкара мөнәсәбәтләр институтының 3 нче курс студенты **Азат Якупов** әзерләде. Фәнни җитәкчесе – КФУ доценты **Рамил Җәләев*** ■

# «Ул Бибигайшәгә өйләнергә тиеш иде...»

*(Галиәсгар Камалның никахлашу тарихы)*

**Әнәс Камал**

**Бибигайшә Г.Камал белән бергә унсигез ел гомер кичерә һәм алты баланың әнисе була. Ул 1918 елда бакыйлыкка күчә. 1908 елгы фото**

Улына кыз табу кыен эш түгел, әмма Бибигайшәне өйдән озату мәсьәләсе күп төрле сәбәпләргә бәйләнгән. Беренчедән, Бибигайшә, төскә-биткә чибәр, акыллы булса да, зәгыйфь гәүдәле. Икенчедән, әти кешенең кызын һич тә өеннән

читкә озатасы килми. Чөнки аның кызы бу өйдә иң акыллы, иң белемле кеше. Исәп-хисапка гаять оста – зиһенле кыз. Җыеп әйткәндә, ул – Садыйк хаҗиның иң ышанычлы таянычы. Бибигайшә әтисенең барлык мөлкәтенә бөтен доверенныйлар өстеннән дә икенче күз-колак – икенче хуҗа. Янмас шкаф ачкычлары, магазиннарның төп керем-чыгым кенәгәләре дә аның кулында, аның карамагында саклана. Садыйк хаҗи, кызы белән киңәшмичә, бер генә акча кәгазенә дә кул куймый, имзасы ясалган мөһерен басмый. Банк язулары, төрле вексельфәләннәр барысы да Бибигайшә кулыннан уза һәм аңарда саклана.

Аны кияүгә алырга теләүчеләр күп булса да, үзенә түгел, зур приданына кызыгып кына яучылыйлар. Бу яучыларның күбесе – сәүдә эшләре чыгырыннан чыккан, бөлә башлаган тол ирләр яки укып-укып та мәгънә чыкмаган карт шәкертләр. Бай егетләренә килсәк, аларны Бибигайшә үзе дә сөйми. Чөнки аларның күбесе тумас борын картайган, бозык табигатьле, мәгънәсез адәм имгәкләре. Андый йорт тотмас, чи надан, аяклы казалар белән дөнья корып булмаячагын Садыйк хаҗи үзе дә, Бибигайшә дә бик аңлый. Шуңа күрә Бибигайшә очраган бер кешегә кияүгә чыгарга ашыкмый. Ул үзенә кияүне ярлырак, ләкин аңлы, булдыклы шәкертләр арасыннан эзләргә карар кылган.

Мәдрәсәдә бай кияве булып алып, муллалыкка үрелергә, хәтта, бай булса, тол карчыкларга өйләнергә дә әзер торучы пишкадәмнәр аз түгел түгелен!.. Алар, Гайшә күңеленә коткы салырга теләп, озын-озын гыйшык хатлары да җибәргәлиләр. Ләкин Бибигайшә алданмый, аның яшь йөрәге нәрсәгәдер өметләнә, эзләнә... Ниһаять, ул үзенең күңел кошын очрата!.. Бу егет Садыйк байда скорняк булып эшләүче оста камчатчы Галиәкбәрнең олы улы, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең галиясен тәмамлаучы шәкерт Галиәсгар иде.

Мәҗлесләрнең берсендә хатын-кызлар ягындагы бүлмә тактасына махсус уелган ярыктан карап, кызлар залдагы егетләрне күзләделәр. Хуҗа кызы да Галиәсгаргә бер күз төшерү белән үк гашыйк булды. Бибигайшә сайлаган егет шәкертләр арасындагы иң матур, иң акыллы, буйга зур булмаса да, зифа гәүдәле егет иде. Егетнең атасы кул астында эшләүче мастеровой икәнен дә белеп алгач, аннан башка да үзсүзле Бибигайшә, ничек кенә булмасын, Галиәсгарне кулыннан ычкындырмаска ниятләде. Бу егетнең җәмәгать сәкесендә мәдрәсәдәге иске тәртипләргә каршы коткы таратучылар арасында булуын, нindидер көлке, яшерен гәзитә чыгаруда катнашкан өчен күп кенә шелтәләр алганын ишетсә дә, Бибигайшә аларны гаепкә санамады: «Егет кешедә андый гына гаепләр булмыймы соң!» – дип, кул гына селтәде. Күңеле кемгә төшкәнен әнисе Бибикамалдан да яшермичә: «Әнием, бәгырем, сезнең мине бәхетле итәргә теләвегездән һич тә шикләнмим... Зинһар, хәстәренә керешегез, мине әнә шул камчатчыгызның улына кияүгә бирегез!» – дип әйтеп салды. Юк, сер салып кына калмады, җитди рәвештә таләп итте.

Эш зурга китте. Серне Садыйк хаҗига да ачып салмыйча булдыра алмадылар. Садыйк бай баштарак киреләнгән булып маташты: «Тапкансыз икән егет, мөфти хәзрәткә, дамеллабызга каршы сүз каткан, җәдитләр-дәһриләр белән аралаша башлаган кызыл авызлардан башкалар да бетмәгәндер әле, Аллаһы насыйп иткән булса!» – дигән булды. Ләкин шуны да әйтергә кирәк: Садыйк бай үзе дә Галиәсгарне күптән ошатып йөри һәм моның сәбәбе дә бар иде. Хаҗи Пләтән урамы башында ике бистә арасындагы иске зират өстенә мәчет салдырырга керешкән һәм ул тиздән өлгерергә тиеш иде. Шәһәрнең олуг могтабәр кешеләре арасында әлеге мәчеткә кемне мулла итеп кую мәсьәләсе дә тора һәм

бу турыда мәчет хуҗасы Садыйк хаҗиның да фикерен көтәләр иде. Шуңа күрә, әлеге мәчеткә кем мулла итеп билгеләнсә, шул ук кеше Бибигайшәнең кияве дә булырга тиеш. Садыйк хаҗи фикеренчә, Галиәсгарнең мулла булырлыгы да, кияү булырлыгы да бик бар. Дөрес, Галиәсгарнең хөр фикерлелеге, үз хәлфәләренә, дамеллага һәм байларга буйсынмавы, мәдрәсәдә төрле гаугаларга сәбәпче булуы, ниндидер китаплар яза башлавы турында хаҗи ишеткәләгән иде. «Ләкин мондый заманда бөтенләй үк саф, судан пакь, сөттән ак булган кияүне каян тапмак кирәк?» – дип уйлады ул. «Башына тай типмәгән булса, өйләнгәч, ипкә керер әле. Байлык кадерен кем белми? Бөтенләй үк башсыз булмаса, ризыкка арт куймас. Атасы Галиәкбәр дә бик диндар, бик уңган кеше, шаять, үз улына үзе хуҗа була алыр. Бер йөгәнләп алсам, мин дә коры тотармын. Ничек кенә булмасын, Аллага тәвәккәлләп, шушы егетне кулдан ычкындырмаска, тизрәк никах уздырып, үзебезгә кияү итәргә, йортка кертергә кирәк!» – диде ул.

Бибигайшә дә тик кенә ятмады. Бу йортка, әнисе Бибикамалга им-том итеп, аш-су остасы буларак булышырга килеп йөрүче Мәүгыйзә абыстайга аеруча илтифат күрсәтә башлады. Өйгә ул килеп керде исә: «Һай, минем икенче әнкәм дә бар бит дөньяда! Күрегезче, ул килеп кергәч, өйләребез ничек ямьләнде, нурланып китте!»– дип, аны өрмәгән җиргә дә утыртмый иде.

Шулай итеп, Бибигайшә Мәүгыйзә абыстайга һәрвакыт ярарга тырышты. Ашсу әзерләгәндә, кунак-төшем булганда, үзен аксөяк дип күрсәтмәс өчен, асраулар белән беррәттән, җиң сызганып аңа булышты. Казанда бер дигән аш-су остасы Мәүгыйзә абыстайдан Бибигайшә күптөрле нигъмәтләр әзерләргә өйрәнде. Алар бик тиз үз булып киттеләр. Мәүгыйзә абыстай да Бибигайшәнең белемле кыз булуыннан файдаланды, буш вакытларында аның белән бергә утырып, төрле китаплар караштырды, төшенмәгәннәрен Бибигайшәдән сорап белде. Өенә кайткач та, ул Бибигайшәнең уңганлыкларын сөйләп бетерә алмады, бигрәк тә аны улы Галиәсгар өйдә чакта мактарга тырышты. Галиәсгар, Садыйк хаҗи кызын ни өчен болай мактаганнарына әллә ни әһәмият бирмәсә дә, тел төбенең кая табарак борылуын шәйләде. Шик юк, әти-әнисе аны өйләндерергә тели. Өйләндергәндә дә, әлбәттә, бай кызына өйләндерергә тели. Ә Галиәсгарнең әлегә андый уе ике ятып, бер төшенә дә кергәне юк. Хәер, аның моңа вакыты да юк, ул быел мәдрәсәне дә, русча укуын да тәмамларга тиеш. Дөрес, аңа инде үз көнен үзе күрергә дә җыена башларга вакыт. Ул инде берничә әдәби китап та бастырып чыгарган, аңа шул эшен дәвам итәргә, бигрәк тә рус спектакльләрен карарга, театр китаплары белән яхшы танышырга кирәк иде. Шуңа күрә Галиәсгар, астыртын рәвештә булса да, күңелен шул эшләргә баглады. Шәһәр театрына йөрде, русча спектакльләрне калдырмаска тырышты. Әйе, аңа үз көнен үзе күрергә, үз оясын үзе корырга күптән вакыт. «Мөхәммәдия»не тәмамлауга аны бит мәдрәсә бүлмәсендә тотмаячаклар. Әти-әни гаиләсенә яңадан кайтып керү турында уйларга да ярамый. Анда әзмәвердәй ике егет – Габдулла белән Габдерахман да, балигъ булып килә торган сеңлесе Зәйнәп тә бар...

Тора-бара Бибигайшә, Галиәсгардән китаплар соратып алдыру сылтавы белән, аңа хатлар да яза башлады. Бер хатында: *«...Сезнең Миргаяз учительдән урысча укыганлыгыгызны ишеткәнлегемнән, сез нинди уку китапларыннан файдаланасыз? Шул турыларда, мөмкин булса, миңа да белдерсәгез икән. Мин дә шундыйларны алдыртыр идем»,* – дип тә үтенгән. Галиәсгар дә хатка каршы хат язмыйча булдыра алмады. Ләкин шунысы кызык: бай кызы, дини китаплардан бигрәк, яңарак чыккан әдәби китапларны сората иде. Галиәсгаргә бер бай

кызының мондый яңа, дөньяви әсәрләр белән кызыксынуы гаҗәбрәк тоелды һәм Бибигайшәгә язган җавап хатларында, кызның дөньяга карашын белер өчен, төрле сынаулы сораулар язып җибәрде. Кызга шул гына кирәк иде: бер сорауга биш җавап биреп, хатларын озын-озак итеп язарга кереште. Галиәсгаргә кызның шулай аңлы булуы бик ошады һәм ул, аннан бер дә яшереп тормыйча, үзенең күңелендә яткан яңа фикерләрен ачып сала башлады. Кызны русча укуы өчен мактап, үзенә таныш булган кулланмалар, лөгатьләр исемлеген дә җибәрде. Нәкъ менә шул вакытларда гына матбугатта күренә башлаган өр-яңа әдәби китапларны кызга күндерде. Шулай итеп, кыз белән егет арасында фикерләр алышу элемтәсе урнашты.

Бай кызы үзенең соңгы бер хатында, Галиәсгарнең тулысынча олы җанлы, шул ук вакытта гади, кече күңелле кеше икәнлегенә төшенгәннән соң, бөтен эчсерләрен ачып салмыйча булдыра алмады. Бибигайшәнең бер озын хаты шундый иде:

*«Сезки мөхтәрәм Галиәсгар әфәнде! Сезнең белән безнең арада мәзкүр хатлар аша алып барылган танышлыкның уңай яки кире якка хәл кылыныр чагы җитте. Үзегезгә мәгълүм: безнең гаилә илә сезнең гаилә изге кардәшлек җепләре илә баглану алдында тора. Ягъни Сезнең ризалыгыгыз шәрәфендә мин тиздән Сез галиҗәнабнең хәләл җефете булырга тиешмен. Ихлас күңелемнән әйтәмен ки, мин сездән бик мәмнүнмен. Мин Сезне күреп тә, әсәрләрегезне укып та бик яхшы беләмдер кебек. Ләкин Сез мине ишетеп кенә беләсез, гәрчә оят булса да, әйтергә мәҗбүрмен, мин Сезнең дикъкатьне җәлеп итәрлек үк гүзәл кызлардан түгелмен. Ләкин минем фәһемләвемчә, Сезгә олуг максадларыгызга ирешү юлында иҗади хезмәтләрегездә булышчы, аңлы-белемле гомер юлдашы кирәк. Мин Сезне шулай аңладым... Сезнең тирән фикерләрегез, изге максадларыгыз алдында түбәнчелек белән баш иям. Әгәр дә мин үземнең бик үк зурдан булмаган белемем һәм тәҗрибәләрем белән Сезнең бөек эшләрегезне вөҗүдкә ашыруда кечкенә генә ярдәмче әһлиягез була алсам, үземне гомерем буена бәхетлеләрдән санар идем!*

*Сез инде югары белем алган укымышлы гали зат, аңлы, мәгърифәт хезмәткәре булып җитештегез. Әмма дә Сез милләтебезнең кадими олуглары алдында үзегезнең яңа карашларыгызны ачыктан-ачык игълан итеп чыксагыз, зур хата булмагае... Бу мәсьәләдә беркадәр саграк, ягъни «хәйләи шәргыя» ясавыгызны үтенер идем. Сезгә, форсаттан файдаланып, никах шартларын һәм минем белән бергә бирелә торган приданнарын бер дә кыенсынмыйча кабул итү мәгькуль булыр. Мәсәлән, минем приданым итеп биреләчәк, хәзер өлгереп килә торган йортыбызда без аерым, тыныч һәм сәгадәтле гомер кичерү мөмкинлеген табачакбыз. Моның өстенә банктагы акчалата бирелә торган дәүләт тә Сезгә әдәби, иҗади эшләрегезне җәеп җибәрүдә файдалы булыр дип уйлыйм. Никахтан соң, аерым гаилә булып яши башлаганнан соң да, Сез үз ихтыярыгызны күрсәтергә соңга калмассыз дип ышанам. Зинһар, гафу итегез, мин Сезнең дә, үземнең дә мәнфәгатьле, бәхетле тормыш кичерүебезне телим. Ышаныгыз, мин гомеремә Сезгә тугрылыклы булырга һәм дә Сезнең иҗади хезмәтләрегездә һәмишә ярдәмче булырга тырышачакмын.*

*Мондый вәгазь-нәсыйхәтләрем белән Сезне борчырга җөрьәт иткәнем өчен янә бер кат түбәнчелек белән гафу сорап:*

*Бибигайшә Садыйк кызы Хәйбуллина».*

Бу хат үтә нечкә күңелле яшь Галиәсгарне бик тә тәэсирләндерә. Өстәвенә, беркадәр шиккә дә төшерә: «Дөрес, кыз бу хатны ихлас күңеленнән, хәтта үзен кимгә куеп та язган... Әмма болай кимсенүнең сере нидә соң? Үзе әйтмешли, бу бай кызы берәр «хәйләи шәргыя» кылып маташмыймы? Ул приданнар, аерым йортлар миңа нигә хаҗәт?.. Әллә атасының байлыгы белән идарә итә алган «коммерсант» кыз минем шәхси ирегем белән шаярырга чамалыймы? Юктыр ла... Минемчә, ул кыз үзе шул черек, тынчу, иске тормыштан котылу юлын эзлидер. Ихтимал, аның да мәнфәгатьле, якты тормышта яшисе киләдер. «Ышаныгыз, – ди ич, – Мин сезнең дә, үземнең дә мәнфәгатьле, бәхетле тормыш кичерүебезне телим...» – ди. Ә нишләп ышанмаска ди? Бәхетле булырга кем теләмәс?.. Менә, мөхтәрәм Галиәсгар ибне Галиәкбәр әфәнде, сезгә дә көрәш мәйданына чыгар вакыт җитте! Күрсәт каһарманлыгыңны! Азат ит караңгылык патшалыгыннан шул бичара мәгъшукаңны! Һәй, каян килеп «мәгъшука»м булсын ди ул! Минем аны юньләп күргәнем дә юк ич әле... Садыйк хаҗи кызы бит ул, черегән бай кызы... Ысул кадимче ишанга кул биргән мөрит кызы. Ул каян килеп бичара булсын! Менә син ул бичара пишкадәм! Шул йортка кияү булып кереп, рәхәт күрергә өметләнүче! Бу бит күрәләтә үз-үзеңне мещан сазлыгына ыргыту лабаса! Анда, алар коллыгында син үзең дә соры кортка әйләнәчәксең бит! Юк-юк, мин әле, кара үрмәкүч авына эләгеп, җан тәслим кылырга җыенган җыбыткы чебен заты түгел... Бибигайшәнең ихластан сузылган дуслык кулын кире кагу да егетлек булмас. Форсаттан файдаланып, ул ояның түренә узарга да... мәгърифәт эстәүдә дошманның үз байлыгын үзенә каршы сарыф итәргәме? Әйе-әйе, иң әүвәл миңа бу фәкыйрьлектән котылырга...»

***

Булачак кәләшенең фотокарточкасын китереп күрсәткән яучы карчыкка ул:

– Карасана, Мәмдуха абыстай, бу кыз чибәр генә күренә бит? – дип елмаеп куйды. – Бу яктан сүз юк, адәм фәрештә булмас. Акылы ничек, акылы? Мине санлап, дус күреп, тапканыма риза булып торырлыкмы? Син миңа шунысын әйт, Мәмдуха абыстай. Югыйсә, мин ярлы гына егет, ул мине гомерем буена табалап, каһәрләп тормасмы?

– Әй улым, куй юк сүзеңне! Син димәгән сулуы юк. Әйтсәм әйтим инде, ул сиңа күптән гашыйк булган! «Күңелем анда гына, Галиәсгардән бүтәннең, хур егете булса да, кирәге юк кына», – ди. Белдеңме, Галиәсгар! Бәхетең бар икән, Казанда бер дигән бай кызына өйләнәсең бит. Приданнары-бирнәләре генә ни тора! Асты – таш, өсте агач ике катлы йорт, банкыда кыз исеменә салынган ун мең, туй итәргә бер мең... – дип тезде Мәмдуха карчык.

Галиәсгарнең боларга артык исе китмәде. «Ике катлы өйнең бер катында әтиләр яшәсә... Гомерендә юньле фатир күргәннәре юк иде... Ярар, әтиәниләрнең тормышлары бераз рәтләнсә, миңа ничек тә ярар», – дип кенә уйлады ул. Кызның зәгыйфь гәүдәле булуын алдан белсә дә, моны сәбәп итеп каршылык күрсәтмәде. Киресенчә, ул үзенең сәламәтлеге белән боек кызның рухын күтәрермен, бәхетле итәрмен дип ышанды. Аның бөтен курыкканы кешене кимсетү, кешенең бәхетсезлегеннән көлү иде. Юк, ул Бибигайшәгә өйләнергә тиеш иде... Язмышыннан разый иде... ■

# Фин иленә сатылган татар мирасы

*(Заусайлов коллекциясе)*

**Нурулла Гариф**

**В.И.Заусайлов**

Һәр халык тарихи яшәеше чорында үзенә генә хас булган мирас туплый. Бу мираска рухи кыйммәтләр генә түгел, матди байлык та керә. Безнең сүз сөрешебез дә халкыбыз туплаган матди байлыклар турында. Әлеге мирас башка халыклар арасында тоткан урыныбызны, дәрәҗәбезне күрсәтә. Халыкны милләт буларак туплап, үткәнебезгә горурлык уятып, вакыт агышында тарих арбасында ныклы урын биләп, милләтне юкка чыгудан да саклап тора…

Матди мирас музейларда һәм төрле фондларда саклана. Алар өлешчә тарихчылар тарафыннан сурәтләргә басылып, китапларда да чагылыш таба. Әмма вакыт узышында яңа матди байлыклар табыла тора. Алар археологик казу эшләре вакытында да, очраклы рәвештә дә, хәзинәләр буларак, җир астыннан да дөньяга чыга.

Татарстан җирлегендә табылган хәзинәләр бар дөнья буйлап таралган. Аларның эзләрен тирә-яктагы өлкә[1] һәм республикаларда (Башкортстан[2], Чуашстан[3] һ.б.), Мәскәү, Санкт-Петербург кебек шәһәрләрдә, шулай ук Финляндия һәм башка Аурупа илләрендә табарга була.

Хәзинәләрнең бер өлеше дөнья буйлап сәүдә эшчәнлеге, сәяси вазгыять, сугышлар булу сәбәпле таралса, икенче өлеше байлык туплау, сатып акча эшләү нәтиҗәсендә табылган яисә башка максатларда урланган-таланган. Бу тенденция бүген дә дәвам итә.

Татарстан җирлегендә табылган хәзинәләр арасында Кытай, Һиндстан, Иран, Гыйрак, Италия, гарәп, Урта Азия һәм Аурупа илләреннән китерелгән әйберләр дә күп.

Элекке чорларда зиннәтле металлардан торган табылдыкларның зур өлеше, сәнгати кыйммәте юк дип саналып, Петербургтагы акча ясау сараена озатылган. Алар арасында алтын кисемтәләр, көмеш пластинкалар, махсус эретмәләр, бакыр да бар... Соңрак татар җиреннән табылган бу алтын-көмешләрдән урыс дәүләтен, мәдәниятен баеткан көмеш тәңкәләр, зиннәтле савыт-сабалар, байлар өчен кулланылышта булган бизәнү әйберләре эшләгәннәр. Татар халкы мирасын юкка чыгаруга кыйммәтле металл эшләнмәләрне алып-сату эшчәнлеген алып барган зәркәнчеләр дә үз өлешен күп керткән[4].

## Заусайлов коллекциясе турында мәгълүмат

Борынгы чорларга караган каталог В.И.Заусайлов тарафыннан төзелгән. Әлеге каталогта элекке Казан губернасы – Идел-Кама бассейнына кергән җирләрдәге табылдыклар урын алган. Борынгы чорлар – таш һәм бронза гасырларга караган табылдыкларны җыю теләге 1877 елда узган Археологик җыелышта катнашканнан соң туа. 1878 елның көзендә В.И.Заусайлов, үзенең танышыннан таштан эшләнгән өч табылдык алып тора да Казан тирәсендәге авылларга таба юлга чыга. Ул, авылдан-авылга, өйдән-өйгә кереп, әлегедәй ташлар очратканыгыз яисә саклаучы кешеләр юкмы, дип сорашып йөри башлый. Заусайлов әлеге ташларны «яшен ташы» дип атый. Шулай дип атаганда гына ул кешеләрдә аңлау таба һәм аңа андый ташларның кемнәрдә булуын хәбәр итәләр. Табылдыкларның бер өлешен аңа болай гына бирәләр, ә кайберләрен сатып алырга мәҗбүр була. Шул вакытта ул аларның кайда һәм нинди очракларда табылулары турында сорашырга һәм кенәгәсенә язып, урыннарын билгеләп куярга да онытмый. Заусайлов бик еш әлеге ташлар табылган урыннарны барып карый, ул урында казу эшләре дә уздыра.

В.И.Заусайлов үзенең коллекциясен туплауга гомеренең 26 елын багышлый. Соңга таба табылдыкларны аның өенә үк китереп тапшыра башлыйлар. Аларның бер өлешен ул чит илләрдән дә сатып ала.

[1] Лаеш районының Ташкирмән авылында чүлмәк эченнән табылган көмештән эшләнгән чәч каптырмаларының бер өлеше (барлыгы 72 данә) Вятка шәһәре музеенда саклана. Башка табылдыклар Мәскәү шәһәре университеты музее һәм Петербург шәһәрендә урнашкан Географик җәмгыятьнең Археология музее арасында бүленгән.

[2] Мәсәлән, Әлмәт районының Дербеден авылында табылган хәзинәнең зур өлеше Уфа шәһәре музеенда саклана.

[3] Аксубай районының Татар Сөнчәләе авылында табылган ике хун казанының берсе Чуашстан университеты музеенда саклана.

[4] Татар акчаларын ювелир эшләнмәләр ясау өчен эретмә-материал буларак сатып алучылар турында архивта сакланучы тарихи документларда бик еш искә алына.

**Заусайлов коллекциясеннән фрагмент.** ***Н.Ф.Калинин архивыннан***

В.И.Заусайлов коллекциясендә барлыгы 10936 табылдык тупланган. Шуларның 5282се – таш, 1292се – бронза һәм бакыр, 1417се – тимер, 1010ысы – сөяк, 1639ы – балчык (керамик) эшләнмәләр һәм шулардан тыш тагын 295 чоры билгесез төрле табылдыклар. 1884 елда автор тарафыннан таш гасыр чоры табылдыкларына багышланган атлас бастырыла. Анда шушы көнгәчә табылган эш кораллары, 69 таблицага кертелеп, аларның үз зурлыгында эшләнгән 473 рәсеме дә урнаштырыла. Әлеге эшчәнлекнең дәвамы буларак, бронза чорына караган табылдыкларның 12 фотосурәте дә төшерелә, 516 бронза һәм сөяк әйберләрнең рәсемнәре һәм көнчыгыш мөһере бирелә. Алар В.И.Заусайлов каталогына кушымта буларак теркәлгән. Бу табылдыклар аның шәхси музееның байлыгы булып санала. Баштарак ул аларны халыктан үз акчасына сатып ала. Соңрак аңа музейлар һәм төрле җәмгыятьләр аша акчалата ярдәм дә күрсәтелә. Заусайлов шулай ук үзе дә кайбер табылдыкларны музейларга бүләк итә.

В.И.Заусайлов, матди яктан авыр хәлдә калу сәбәпле, коллекциясен Казанда сатуга куя. Әмма аны сатып алып музейга тапшыручы табылмый. 1909 елда гына, фин археологы Н.Н.Тальгрен арадашлыгында, коллекцияне Финляндия милли музее сатып ала. Революциядән соң Финляндия бәйсезлек ала һәм шул сәбәпле безнең төбәктән җыелган коллекция чит илдә кала. Ул коллекция һәм аның каталогы бүгенге көндә Финляндиянең башкаласы Хельсинки шәһәре музеенда саклана. Каталогның күчермәсе исә Казанда – Археология музее архивында. Коллекциядә күрсәтелгән табылдыклар җирле тарихны язганда башлангыч чыганак буларак зур роль уйный. ■

# КОТОЧКЫЧ АЧЛЫК

## СӘХИФӘ ИДЕЛ БУЕНДАГЫ 1921-1922 НЧЕ ЕЛГЫ АЧЛЫКТАН ВАФАТ БУЛГАН МӘРХҮМНӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНА.

# «Йөрәгем кубып өйгә йөгердем»

**Шәкүрә Юзеева**

1921 елның җәе бик эссе булып, июль аенда ук, яңгыр яумаганлыктан, җир йөзе сары төскә керде. Чәчкән ашлыклар чыкмады. Алар урынына чүп үләннәре, урыны белән алабута үләне бик нык уңды. Эшләр кешеләре булгач, көчле кешеләр алабутаны урып алып, сугып, орлыгыннан ярма, он кебек нәрсәләр ясадылар. Саф орлыгыннан гына ясаган ярмасы тәмле, оны бик ачы иде. Кайбер кешеләр имән чикләвегеннән, юкә кайрысыннан он ясыйлар. Ул елның кышы да бик салкын иде. Суыклар, бураннар март азагына кадәр өзлексез булып кына торды. Бөтен җирне тирән кар басты. Безнең әни андый нәрсәләрнең берсен дә әзерли алмады. Эш кешесе булмагач, куркуыннан, әз булса да запас азык булдырган. Шул кышны нәрсәдер суйган. Булган азыкларны бик әзләп, ачтан үлмәслек итеп киләсе ашлыкка кадәре җиткерде.

1921 елның язында бердәнбер җирән биябезне абзардан ат караклары алып чыгып суялар. Җәй сыерны ашлыкка кергән өчен бер аягын балта белән чабып өзәләр.

Авыл, бөтен кеше үлеп беткән кебек, тып-тын. Менә бервакыт капка ярыгыннан нинди тавыш икән дип карасам, коточкыч күренеш шаһиты булдым. Түбән оч Гилүән исемле кешенең һәм хатынының да аркаларына ниндидер тиреләр асканнар да, аларны урам буенча мыскыллап, кыйнап, нәрсәләрдер кычкырып узып баралар. Хатыны да, ире дә яланбаш, пычранып беткәннәр. Йөрәгем кубып өйгә йөгердем.

Кышны чыгып, 1922 елның җәендә бик ачыккан чак та булды. Кемдер Ташкент икмәкле икән дигән сүз тараткандыр. 1921 елның җәендә кайбер кешеләр булган азыгын, балаларын алып, бәләкәй арба белән Ташкентка яки Әмриккә барабыз, дип, юлда бераз баргач та, ачлыктан үлеп бетәләр.

Мин җәйге каникулда булам да яңадан үземнең гомум торагыма китәм. Балалар йортыннан безне күчергәннәр иде инде. Бу торактан безне яңадан Ленин урамындагы төрле буяулы тәрәзәле өйгә урнаштырдылар. Моңа кадәр анда беспризорный балалар яшәгән. Стеналарында кеше каннары каткан, кайбер тәрәзәләр ватык. Укучылар беренче чирек беткәнче укыдылар да кайтып киттеләр. Торакта бары 35 кеше калды. Кызлардан мин берүзем калдым. Шуңа кадәрле Рәйхан исемле бер кыз, ачлык газабыннан котылу өчен, төнлә тышка чыккан да, яланаяк чыгудан суык тидереп, каты авырып, теге дөньяга – тыныч дөньяга китте.

**Ачлык елларда ясалган плакат**

Васфи абый мине караван сыярлык кечкенә бүлмәгә урнаштырды. Караватым ватык тәрәзә янында булганга, аны такта белән кадаклап куйды. Иптәшкә Сәлмәнне бирде. Соңыннан тегүче кызы Сараны әнисе минем янга китереп, бергә тора башладык.

Безгә, ачтан интегеп үлмәс өчен генә (күпме грамм икәнен хәтерләмим), ипи бирәләр. Шуны үзебез иртән бер мәртәбә, кич икен-

че мәртәбә ашыйбыз. Минем организм көчле булгандыр, ашказаным шуңа күнегеп, ач икәнемне дә белмичә яши бирә идем.

Шул ипине малайлар, түбән базарга төшеп, ала-бута ярмасына алыштырып менәләр иде. Кич пичтә котелок белән пешерәләр. Алыштырган ипидән бер котелок ботка чыга иде. Ипине дежурлар бүлеп: «Бу кемгә?» – дип кычкырып бирәләр.

> «
> **Яз көне урамнан сулар акканда зур арба җиккән ат белән канау буендагы үлекләрне җыеп йөриләр.**

Тәрәзәләр ватык, карын ач булганлыктан, аякка киез итек, өстемә тунымны киеп ята идем. Төннәрен бик куркыныч, тышкы ишекләр ачык кала. Бервакыт коридордан узып барганда, пич эченнән 12 яшь чамасы бер ир баланы тартып чыгардык. Ул анда җылынып йоклар өчен кереп яткан, шуңа күрә төнлә куркып, кычкырып уяна идем.

Яз көне урамнан сулар акканда зур арба җиккән ат белән канау буендагы үлекләрне җыеп йөриләр.

1922 елның җәендә ашлыклар бик уңа. Үләннәр, какылар өлгергәч, кешеләр бераз хәл ала. Үлми калган кешеләр ашлык өлгерү белән ашый башлыйлар.

Ул елны без класста өчәү генә укыдык: Кручев, Узбеков һәм мин. Алар базарга ипи алыштыру өчен алмашлап йөриләр. Шуның өчен дәрестә икәү генә калган көннәр күп була иде.

Кручев: «Ач та түгел, тук та түгел, бер өйрәнгәч – чурт та түгел», – дип җырлый иде.

Иртән бирелгән ипи белән кайнаган су эчәбез, төшкә «тозлы шулпа» – йә балыктан, йә кәбестәдән, кич – бүлеп куйган ипи белән тагын кайнаган су. Ул елларны чын чәй юк иде.

Җәй авылга кайткач, әрәмәдән кура җиләге яфрагын җыеп, капчыгы белән өелгән ястык, мендәр астына салып кыздырабыз, аннан кайнаган суда кыздырып, пичтә киптерәбез. Сөт белән эчкәндә тәмле чәй була...

Башта теләсә нинди йортта укыдык. Соңыннан «Реальное училище»ны бетереп, зданиесен педтехникумга бирделәр, иркен сулыш алып шунда укый башладык.

Укытучылар югары белемле, тәҗрибәле, бик яхшы укыталар һәм таләпчән иде. Без, кызлар, математика, физика, химия кагыйдәләрен ятка бикләп, сорасалар чатнатып әйтә идек. Үзем русча әз белгәнлектән, ул фәннәрне уртача гына укып, ана теле, җыр дәресләрен яхшы укый идем.

1922 елның җәендә ашлыклар бик уңганлыктан, әнинең әз генә чәчкән җирен уру, җыештыру да бик авыр иде. Шул җәйне арыш урган җиремнән авырып кайттым һәм күпмедер вакыт ятканнан соң терелдем.

*Текстны басмага **Ләйсән Данилова***
*һәм **Гөлнара Халморадова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2022

# Атлы кешеләр заманы кайтырмы?

*(Гөман)*

**Зәрия Хәбипова**

**Татар атлары**

Безнең борынгы ата-бабаларыбыз атны беренче кулга ияләштерүчеләрдән санала. «Татар» атамасы да үзендә «атлы ир» мәгънәсен йөртә бит. Меңнәрчә елларга сузылган мондый тормыш, беренчедән, тулаем Җир күләмендә энергетик һәм транспорт революциясе булса, икенчедән, ат кешегә үзенең табигать белән бәйләнешләр тирәнлеген аңларга һәм эволюцион үзгәрешләр кичерергә мәҗбүр итүче көч тә була.

Ат кеше кулга ияләштергән эт, сарык, кәҗә, сыер кебек тереклек ияләре рәтенә соңрак кушыла. Бу, бәлки, аның гаять сизгерлеге аркасында шулай килеп чыккандыр. Адәм баласына да мондый җан иясе шәүкәтенә торырлык көч һәм сизгерлек туплау кирәк булгандыр.

Ул вакытта кеше үзе үсешнең кайсы баскычында торган соң? Галимнәр атны кулга ияләштерү якынча 6-8 мең еллар элек Себер һәм Уралның көньягында, Каспий, Дон буйларында, яшел үләнгә бай далаларда башланган, дип исәплиләр. Адәм баласы мал асрау, җир эшкәртү, туку, чүлмәк ясауны үзләштергән һәм бронза гасырына аяк баскан чор була бу. Әлбәттә, 6-8 мең ел дигәннәре – шартлы

сан. Бу вакыйга борынгырак та булырга мөмкин. Әйтик, Башкортстан җирендә урнашкан Шүлгән-Таш тыюлыгындагы мәгарәдә ат һәм мамонт сурәтләре табыла. Әлеге сурәтләрнең төшерелү вакытын 12, хәтта 18-19 мең ел элек дип күрсәтү очраклары да бар.

«Әгәр кеше кыргый атны кулга ияләштереп тулпар иткән булса, адәмнең үзен кеше итеп малкае үстергән, тулпары аны алга алып барган – тукландырган һәм тәрбия кылган, гуманлы булырга, адәм булырга өйрәткән», – дип яза Адлер Тимергалин. Кыска һәм бик тирән мәгънәле фикер бу. Олы язучының сүзләрен куәтләп, атның кайбер сыйфатларын искә төшерик.

Ат – көчле, җитез, чыдам, сизгер, сак. Ул текә ярга якын килмәс, куркыныч җиргә керер алдыннан туктап калыр, колакларын шомрайтып, башын сузып, зур дымлы күзләрен алга төбәп, бөтен гәүдәсе белән калтырап, билгесезлектән хәбәр алырга омтылыр. Ат, башын бормыйча, тирә-якны тулаем, хәтта караңгыда да күрү сәләтенә ия. Ул бер үткән юлны яхшы хәтерли, яхшы ишетә, колак яфракларын боргалап, тавышны сөзеп тота, дүрт чакрым ераклыктагы авазларны аера белә. Атның тәм тоюы һәм ис сизүе бик көчле. Үз колынын ул иснәп таба. Пычрак суны, бозылган ризыкны капмый. Ат йөзә белә. Сүзләрне аңлый, кешенең халәтен тоя, мактаганны, ачуланганны аера.

Танылган режиссер Зәкия Туишева үзенең истәлекләрендә шундый бер очрак турында яза. Сугышта шәфкать туташы була ул. Йөк ташу, яралыларны күчерү өчен аларга ат һәм солдат бирәләр. Солдат атны җигә алмыйча изалана. Тарткаласа да, суккаласа да, тәртә арасына кертә алмый. Ачуы чыккан солдат, агачка бәйләп, ямьсез сүгенеп, атны кыйнарга тотына, шулай тәрбия кылмакчы була. Ат елый, күзләреннән яшь ага, ләкин урыныннан кузгалмый.

Моны күзәтеп торган Зәкия апа, солдат киткәч, ат янына килеп, үгетли башлый: «Сугыш бара бит, ярдәм кирәк, тыңла инде». Кесәсеннән бер кисәк шикәр чыгара. Малкай шикләнеп кенә шикәрне ала. Бераздан ат Зәкия апага ияләшә, аны тыңлый, тәртә арасына да керә, атланып йөрүенә дә карышмый. Дуслашалар. Атыш барганда Зәкия апаны снаряд төшәчәк урыннан йолкып диярлек алып, үлемнән коткарганы да була атның.

Атка сыену кешегә яшәү асылын тирәнрәк аңларга мөмкинлек биргәндер: дөньяда дошманлык кына түгел, яхшылык, җылылык, соклану, ярату кебек хисләр барлыгына да төшендергәндер. Атка таяна башлагач, кешедә тормышка ышаныч туган. Һәр куак артыннан карап торган куркыныч күзләрдән котылган атлы кеше. Кояшның үзен күккә менгерүче көч күргән ул атта. Чиксез күкнең хуҗасы барлыгын, аның үзеннән өстен икәнен таныган адәм баласы. «Тәңре!» – дип эндәшкән ул җиһанның Бөек Хуҗасына. Җир селкетеп чапкан атларның тояк тавышлары, күкне ярган яшен гөрелтесе ишеткән ул бу сүзнең яңгырашында.

***

Борынгы бабаларыбыз дөньяны өч өлешкә бүлгәннәр: Күк, Җир өсте һәм Җир асты. Якты көчләрне өскә – Күккә, кешене уртага – Җир өстенә, кара көчләрне Җир астына урнаштырганнар. Күктә – Тәңре. «Төрки халыкның исеме, көче юк булмасын дип, атам – каһанны, анам – катунны күтәргән Тәңре, ил төзергә ярдәм иткән Тәңре, төрки халыкның исеме, көче юк булмасын дип, ул Тәңре үземне каһан итеп күтәрде», – дип язылган Күлтәгин ташында.

Ирлекне белдерүче Тәңре янында тормыш көчен саклаучы Умай торган. («Умай шикелле әнием», – диелгән борынгы ташта.) Ул бигрәк тә үлемгә якын торганнар-

ны – яңа туган балаларны, сугышчыларны үз канаты астына алган. Мул уңышны, үрчемле терлекне дә Умайдан сораганнар.

«Тәңре, Умай, изге Җир-су – барысы да безне саклый, безгә җиңү бирә, нигә качарга?» – дип эндәшә авыр минутта Тоньюкук. Җир-су – адәм балалары яшәгән Җир өсте алласы. Туган җирне ярату, җиргә табыну, биек тауларны изгеләштерү – Җир-су культының бер чагылышы. Телебездә туган җирне сагынуны белдергән «җирсү», «җирсенү» сүзләре, ант иткәндә «җир йотсын» дип әйтүләр – барысы да Җир-суга табынудан туган.

Җир асты дөньясында Эрлик идарә иткән. Борынгылар әүвәл аның «патшалыгын» кояштан мәхрүм Җир өсте кебек күзаллаган. Шуңа күрә дә үлгән кешене эш кораллары, атлары белән бергә күмү йоласы булган. Кешенең аңы үсә барып, күзаллавы үзгәргәч, «җан», «тән», «кот», «рух» төшенчәләре барлыкка килгән. Яшәүне катлауландырып, аерымлап аңлатучы бу төшенчәләр үлем турындагы авыр уйларга башкача карарга мөмкинлек биргән. Хәзер инде тән – Җирнеке булса, аң, җан, кот, рух Күк белән бәйләнгән, аңа буйсынган. Болар барысы белән дә Тәңре идарә иткән. Тәңре һәр кешегә яралганда күктән кот биргән.

Кот – кешенең яшәү көче. «Котлы булсын», «котың артсын» дип әйтүләр кешегә көч-куәт теләүне аңлата. Үлгәндә кешенең коты-җаны (яшәү көче) юкка чыга, алына. Исән вакытта кылган гамәлләренә карап, Тәңре бу җанны үз хөкеменә тарта. Игелек-яхшылык кылып яшәгән кешеләрнең рухлары – Күккә, оҗмахка юнәлә. Алар, кирәк вакытта, нәсел дәвамчыларына ярдәм итәргә дә мөмкин. Ата-анага, үлгәннәр рухына табыну йоласы шулай барлыкка килгәндер, мөгаен.

Эрлик һәм Җир асты рухлары Якты дөнья кешеләренә зыян китерергә омтылган. Алар җиргә чирләр, афәтләр җибәргән, бәла-казадан котылу өчен, кешеләрдән корбан таләп иткән. Бу карашлар да әкренләп үзгәргән: кешенең алдагы тормышына зыян салучы кара көчләргә үлгәннәрнең каргышын да кертә башлаганнар. Ата-ананы, өлкәннәрне хөрмәтләү, үлем хәлендәге кешедән риза-бәхиллек алу, кылган хаталар өчен гафу үтенү, кичерү сорау исәннәргә кара көчләрдән саклану, күңелне чистарту өчен гореф-гадәткә әйләнгән мөһим адым булган. Әлеге гореф-гадәтләр яктылык – караңгылык, яхшылык – яманлыкның даими көрәшен аерырга өйрәткән, адәм баласына тиешле юнәлешне сайлап гамәл кылырга юл ачкан.

Борынгы төркиләр, Тәңре, Умай, Җир-су, Эрликтән тыш, Ут, Кояш, Һава, Җир, Су, Ай, Йолдызлар, Болытлар, Җил, Давыл, Яңгыр, Яшен, Салават күпере һәм башка табигать күренешләренең дә үз аллалары бар дип ышанганнар. Бу аллалар күп күренсә дә, аларны хәтердә калдыру катлаулы булмаган, чөнки алар барысы да табигатьнең бер өлеше саналган. Һәркемнең балачакта:

*«Кояш, чык, чык,*
*Майлы ботка бирермен!..»*

– дип сөйләнгәне булгандыр. Такмакның монысын да белүчеләр бардыр әле:

*«Күк буйлатып бөркет килә,*
*Кара болыт өркеп килә...*
*Бөркет, бөркет, кил, кил,*
*Яңгыр алып кил!»*

Якты дөнья аллалары шулай балачактан һәркемнең күңеленә кереп урнашкан, кешенең аерылгысыз юлдашы булган. Табигатьне җанландыру, аның күренешләрен Югары көч итеп карау кеше белән әйләнә-тирә арасында үзара аңлашу, гармониягә омтылыш барлыкка китергән. Ел фасылларына багышланган күп кенә бәйрәмнәр дә моңа ярдәм иткән. Балачакта «карга боткасы» пешерүнең, боз китүнең, беренче үлән чыгуның, күктә салават күпере күренүнең нинди сөенечле вакыйга булуын һәркем яхшы хәтерлидер. Шулар арасында Сабан туе – атлар ярыштырып, көч һәм җитезлектә сынашып, җыр-уен белән үтә торган бик борынгы һәм күркәм бәйрәмебез.

Аң әкрен ачыла, дөньяда адәм баласы танып белгән күренешләргә караганда, танып белмәгәннәре күбрәк әле. Караңгылык күзне генә түгел, аңны да томалый. Аңның караңгы өлешендә яшеренгән куркулар түбән рухларга ышануны тудырган. Боларга ияләр (өй иясе, абзар иясе һ.б.), убыр, бичура, шүрәле, өрәкләр керә. Ияләр һәм башка түбән рухлар, үз тирәлеген саклаучылар буларак, кешедән тәртип, чисталык-пөхтәлек таләп иткән. Алар үчекләгәнне-үртәгәнне яратмый, тискәре очракта кешегә төрлечә зыян сала дип уйланылган. Барысыннан да сакланырга кирәк булган. Андый чакта догалар, саклагыч бөтиләр ярдәмгә килгән.

Моннан тыш, борынгы бабаларыбыз төрле хайваннарга, җанварларга (ат, тәкә, эт, бүре) табынганнар, аларны изгеләштергәннәр, кайсыберләрен үзләренең нәсел башы итеп таныганнар. Мисалга Ашина (V гасыр) ыруын китерергә мөмкин. Легенда буенча, аларның нәсел очында Ак бүре торган.

Тәңрегә инану, дөньяны үзенчәлекле күзаллау бездә үзебезгә генә хас әхлакый карашлар (этика) хасил иткән. Танылган тарихчы Лев Гумилев төркиләр этикасын «ялгансыз яшәү» дип атый. Бик төгәл атама бу. Төркиләр этикасы буенча урлашу, ялган сөйләү, хыянәт итү иң каты җәзага – үлемгә китерә торган гамәлләрдән саналган.

Сүзне куллануга бәйле таләпләр аерым кагыйдәләргә буйсынган. Моның өчен сүзне төрләргә бүлгәннәр: гади сүз, теләк (доганы да кертеп), боерык, ант, каргыш, юрау, күпер-хәтер, тоташу-күрү (күрәзәлек). Төркиләр арасында һәр төр сүзне гамәлгә куя белгән үз осталары булган. Өшкерүчеләр, бозымчылар кешенең теләген үтәгән – теләк белән эш иткән. Юраучылар, сынчылар кешене ачучы күпер-хәтер осталары булган. Алар югары дәрәҗәдә сөйләшүләр алып барылганда кешенең уен ачу, кемлеген тану өчен чакырылган. Күрәзәчеләр мәңгелектән мәгълүмат алып, вакыйгаларның киләчәктәге үсешен ачыклаган. Хәрбиләшкән төркиләр җәмгыяте өчен боерык – һичшиксез үтәлергә тиешле сүз, ә антны бозу Тәңрегә хыянәт итүгә тиң саналган. Сүзнең шушы рәвештә кулланылышы «Идегәй» дастанында бик ачык сурәтләнгән. Танылган галим В.В.Трепавлов Нугай Урдасына багышланган хезмәтендә шулай ук бу мәсьәләгә аерым туктала.

Төркиләр Җирдәге гамәлләре өчен җаваплылыкны теге дөньяга күчермәгән, аларның әҗерен җәза, бәла-каза яисә рәхмәт рәвешендә адәм баласы йә үзе, йә дәвамчылары бу дөньяда алачак дип фикер йөрткәннәр, шуның нигезендә үзара мөнәсәбәт корганнар. Безнең холкыбызга хас сүзгә ышану, сүз тота белү, биргән сүзгә тугры калу, кешегә якты йөзле, ярдәмчел булу, алдашмау, урлашмау кебек сыйфатлар шушы тормыш фәлсәфәсе нигезендә үскән.

***

Күчмә халык буларак, атлыларда (хунну) идарә тәртибе бик гади булган – ул вакытта ук «кеше хакы» дигән төшенчә барлыкка килгән. Кеше милке кагылгысыз

саналган, төрмәләр булмаган, фетнә күтәрергә өндәүчене, җанкыярны үлемгә хөкем иткәннәр, урлашкан кеше малны уны белән кайтарып бирергә тиеш булган, тән җәрәхәте өчен ат белән түләткәннәр. Шуңа күрә атлылар даирәсендә тәртип бозулар булмаган диярлек. Һәрхәлдә, Эдуард Паркер шулай яза. Ир-атлар һәрвакыт үз җирләрен якларга, сугышырга әзер торган. Моның өчен малайларны кечкенәдән атта йөрергә, уктан атарга, көрәшергә өйрәткәннәр. Икенче яктан, нинди дә булса һөнәр үзләштерү, яшәү даирәсен киңәйтүгә омтылу тыелмаган. Нәтиҗәдә, Баһадур чорында төрки империя Бөек Кытай диварына кадәр җәелгән. Соңыннан да безнең халык яңа җирләр үзләштергән, ханлыклар оештырган, ул җирләрдә үз тәртибен, телен таратып, халыкларны атка утыртып гомер сөрүен белгән. Көчле атлы гаскәр булып туплану, һәркемгә аңлаешлы яшәү тәртибе алып бару аларны җиңелмәс иткән. Күк төркиләр, хәтта Чыңгыз хан империясе дә, борынгыдан килгән шушы гореф-гадәткә таянып яшәгән. Бөек «Яса» яшәү тәртибен канунилаштырган.



**Эдуард Паркер (1849-1926) һәм аның «Татарлар» («Татары») китабы**

Эдуард Паркер «Татарлар» («Татары») китабында язганча, кытайлар хунну белән аралашу нәтиҗәсендә генә дөньяда Һиндстан, Бирма, Япония кебек илләр-җирләр барлыгын белгәннәр. Атлы халык тәэсирендә кытайлар да Мәңге Зәңгәр Күккә табына башлаганнар, илләрен «Күк асты дәүләте» дип атаганнар, атны изгеләштергәннәр.

Төркиләрнең дәүләт төзелешен, психологик үзенчәлекләрен, сугыш һәм дипломатия серләрен ныклап өйрәнү өчен, алар иленә сәяхәтче шпионнар агылган. Бу халыкның йомшак ягын да тиз тапканнар: сүзгә ышаналар, вәгъдәләрендә торалар, алдый белмиләр. Ә ныгый барган католик дөньясы өчен сүзгә ышану көлке саналган. Куйган максатка ирешү юлында барлык ысуллар да (шул исәптән мәкер, хыянәт, ялган) үзен аклый дип санаган алар. Бу турыда сәясәтче, дипломат һәм язучы Никколо Макиавелли (1469-1527) үзенең «Государь» дигән әсәрендә дә аермачык яза. Әлбәттә, мондый система атлы кешеләр табынган системаның капма-каршысы булган. Ике система үзара бәрелешкән. Гаҗәп түгел: ялган дөньясы өскә чыккан. Вакыт алышынган, атлы кешеләр заманы узган.

***

Безнең көнгә кадәр сакланган борынгы язулар, китаплар ата-бабаларыбыз тормышын, аларның яшәү кануннарын һәм омтылышларын теркәп калдырган.

Төрки каһанлыклар чорына кагылышлы ташъязмалар, «Котадгу белек» («Котайткыч белем»), бөек «Яса» кебек әсәрләр безгә шушы эзләнүебездә әһәмиятле һәм ышанычлы терәк булып тора.

«Котадгу белек»не Йосыф Баласагуни 1069-1070 нче елларда Кашгар шәһәрендә язып тәмамлый. Әлеге әсәр XI гасыр төркиләренә хас әдәп-әхлак кагыйдәләре, илдәге кануннар турында сөйли, халык һәм идарәче катламнар арасындагы мөнәсәбәтләрне ача. Әсәр хакимнәргә һәм киләчәк буыннарга ата-баба белемен җиткерүне максат итеп куя. «Котадгу белек»не үз заманында «патшалар китабы», «бәхет ачкычы» дип тә йөрткәннәр. Ул Һиндстанда, Кытайда, Мисырда киң таралыш алган. Эчтәлеге дә, язылышы да бик югары бәяләнгән.

Исеменә килгәндә, «кот» сүзе безгә таныш – «җан», «тереклек көче», «бәхет» дигән мәгънәләрне белдерә. «Котым очты», «котлы булсын» тәгъбирләре бүген дә кулланылышта. Димәк, әсәрнең исемен «көч бирүче белем», «бәхет китерүче белем» дип аңласак, ялгыш булмас. Хәзерге татар теленә әсәрне Рифкать Әхмәтҗанов тәрҗемә итте. Ул 2013 елдан башлап, бүлек-бүлек булып, «Безнең мирас» журналында басылып килде. Кызганыч, әлегә кадәр аның татарча аерым китап булып чыкканы юк.

«Котадгу белек»не Макиавеллиның «Государь» әсәре белән янәшә куеп карасаң, боларның бер-берсенә бөтенләй охшамаган ике галәмне сурәтләве аңлашыла; католик һәм христиан дөньясы белән төрки дөньяның рухи кыйммәтләре никадәр үзгә, капма-каршы икәнлегенә төшенәсең. Баласагуни әсәрендә хакимнең сүзгә, кешегә мөнәсәбәте нинди булырга тиешлеге менә ничек билгеләнә:

*«Түбәндәге ике гадәт күрсәтсә,*
*Гөнаһ булмас кусаң хакимне хәтта:*
*Берсе – ялган сүзләр чыкса теленнән,*
*Икенчесе – үзен зур куйса синнән».*

Сүзгә шундый катгый һәм илаһи мөнәсәбәттән чыгып, тагын бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк: Чыңгыз хан заманында да башка дәүләтләргә хаким сүзе белән барган илчеләр кагылгысыз саналган. Илчеләрне үтерү һәрвакыт зур сугыш башлануга сәбәп булган. Баласагуниның шигъри юллары да өстенлекне рухи көч тудыручы Сүзгә бирә бит:

*«Күңел яралтылган ихлас сүз өчен,*
*Сүзең кыек икән – юк рухи көчең».*

Гаделлек сүздә генә калмасын өчен, хакимнәргә халык белән шул максатта даими эшләргә, хәрәкәттә булырга, һәр гамәлен ашыгып түгел, уйлап, киңәшеп башкарырга кирәклеге турында «Котадгу белек»нең күп бүлекләрендә кат-кат әйтелә.

Тарихтан укып белгәнебезчә, XIV-XV гасырларда татар дәүләтләре таркала башлаган, хан арты хан алышынган. Вазгыятьне Сүз урынына Кылыч ярдәмендә хәл итәргә омтылганнар. «Котадгу белек» өйрәткәннәр онытылган. Буталчыклык, бәлки, хәйлә-мәкер коручыларның сүзен хак сүз итеп кабул итүдән, ялганга ышанудан башлангандыр? «Кем җиңүче?» соравына да: «Сүзендә тормаучы һәм кирәкле кешеләрне кәкре каенга терәтә белүче», – дип җавап бирә бит Никколо Макиавелли.

Без бүген өзеклек чорына килеп кердек. Алда безне нәрсә көтә? Җайдаклар заманы кайтырмы? Анысы инде үзебездән тора. ■

Безнең мирас №2 февраль 2022

# «Ирләрне каракүл бүрекләре таныта»*

Мирхәйдәр Фәйзи

**Дерекуй гүзәлләре чишмәдән су ташый.** ***Огюст Раффе рәсеме***

## Кырым. 1926 ел, апрель

***27сендә*** Кырым Республикасының үзәк каласы булган Симферопольнең берничә урамын ярып үттек. Шәһәр, зур булмаса да, матур, бакчалы, трамвайлы.

Автомобиль белән заулатып шәһәрдән чыгып киттек. Шәһәрдән чыгу белән таулар арасына керә башладык. Яшел, матур таулар, чәчәк белән чолганган алма агачлары, үзләренә аерым стильдә салынган Кырым авыллары, барысы да матур булган кырым татарлары һәм башка халыктан кырым тугмалары, чишмәдән су алып кайтып килгән татар кызлары, үгез җиккән арбалар, өчәр ат җиккән фургоннар – минем өчен һәммәсе ят, кызык, күңелле.

Барган саен тау арасына керә барабыз, җыракта түбәләре карлы таулар күренә. Үзләренә җитеп булмый да, җитеп булмый.

---

* Көндәлекләрдән кыскартып бирелә. – *Ред.*

Монда һәм башка авылларда татарлар күп күренә. Башларында каракүл бүрек. Телләре төрекчәләү. Төскә бар да диярлек матурлар. Украин, яһүд, урыслар да күп очрый. Матур җирдә яралгангамы, күбесе матурлар. Игеннәре, бакчалары – һәммәсе дә тау итәкләре, чокырлар кебек җайсыз җирләрдә. Ат белән йөреп эшләргә мөмкинлек юк. Көрәк белән казып игәләр. Тигез җир юклык шундый кызык рәвештә: өеңнән чыгып бер күршеңә барасы булсаң – тауга менәсең; икенчесенә барыйм дисәң – төшәсең. Тауга менеп, йә түбән төшеп, тигез булып азрак киткән җирне очрату кыен.

Ат-арба белән булса, барасы ике чакрым җиреңне 5-6 чакрым итеп борылып йөреп бару аз газап түгелдер. Арбаны тормозлап түбән төшәләр. Менсәң – атлатып мен, төшсәң – бәйләп төш, шунда күпме җир бара алырсың?

Алуштадан чыгу белән тагы җылан кебек борыла-борыла тауга менеп киттек. Менәбез, менәбез, Алушта җәһәннәм чокырында калды. Менеп җитеп төшәргә тотынгандагы матурлыкны язып бетәргә тагы булдырып булмый. Без биек тауның битен кисеп ясалган юлдан борыла-борыла төшәбез.

Ялта күренде. Ул да диңгез буенда. Тау битенә утырган, әллә кайда түбәндә ята иде. Куркырлык текә юллардан автомобиль Ялтага таба очты һәм барып җиттек.

***28ендә*** пансионга күчеп бардым. Бер татар извозчик алып барды. Элек татарча сөйләшеп карадык. Авыр, аңлашып бетеп булмый. Аннан ике татар урысча сукаларга тотындык. Аерылганда «мөселман кардәш» дип эндәште. Башын иеп: «Сәлам!» – диде.

> «
> **Ирләрнең бик күбе каракүл бүректән, күлмәкне эчкә калдырып, киң чалбар киеп, билен буган. Яшьләре бөркәнеп чәчен мотлак чыгарган була. Бүрекләре килешсез түгел. Матур төсләр янә килешеп тора.**

Кич диңгез буена барып утырдым. Ул, өстенә карасаң, тыныч кебек, ә читкә шау-у итеп дулкын бәреп шаулый да тора. Бик кызык. Городской бакчада да утырдым. Бу да бик матур җир. Их, кипарис агачлары матур. Озын, төз, куыш, мәһабәт. Тагы әллә никадәр безнең якта юк агачлар тулган. Пальма бар; бер яфрагы кызыл, берсе яшел булган бер агач бар; каштан агачлары, тагы әлләниләр, әле исемнәрен белеп алыр хәл юк. Әле яфрак ярмаган агачлар бар. Гөлләр яңа чәчәк ата. Матурлык яңа тәгәлләнә әле.

Кич, ут алгач, диңгез буеннан Ялта өстенә карау ифрат ямьле. Шәһәр тау итәгенә таба үрләгәнгә, электрик лампалары бөтен тау буена чәчелеп күренә. Тауны лампочкалар куеп бизәгән кебек була, карап туеп булмый.

***29ында*** Кузнецов дигән докторга барып күрендем. Старый туберкулез, ди. Ләкин тик ята; үпкә бөтен, йөрәк тә яхшы, ди. Үлчәндем. 3 пот та ¼ кадак булдым. Әллә ничә җирдә урамда точный үлчәүләр тора. 10 тиен түләп үлчәнәсең.

Кырым татарлары белән танышып, тормышларын-фәләннәрен өйрәнү уема ирешә алганым юк. Җае чыкмый.

Дерекуй мәчете

# Ялта. 1926 ел, май

***1есендә.*** Бүген май бәйрәме. Бүген татарларны да аныклап күрдем. Аларның карты-карчыгы, ире-хатыны, җегете-кызы, баласы – бар да бар. Ирләрдә каракүл бүрек нык кына саклана икән. Хатын-кызның шарфы да еш кына күренә. Шулай ук кепка, платки да байтак. Ирләрнең бик күбе каракүл бүректән, күлмәкне эчкә калдырып, киң чалбар киеп, билен буган. Яшьләре бөркәнеп чәчен мотлак чыгарган була. Бүрекләре килешсез түгел. Матур төсләр янә килешеп тора.

Су кергән татар малайлары янына барып, сөйләшүләрен тыңлап тордым. Яхшылап аңлап булмый. Төрекчәләп, аңланмый кала торган әйтебрәк сөйләшәләр.

***9ында.*** Дерекуй* урамнары тар, кәкре бер авыл. Матур йортлар бар. Агачлык, бакча күп. Мәчете кечкенә, урамы тулган татар. Менә мин шуларны эзләп килдем дә.

Иң элек эшем ишәккә менеп барган малайны карау булды. Аннан ул күземә ташланган зур, матур ак йорт каршында туктады. «Дерекуй халык йорты» дигән вывескасы бар. Сөальләремә җавапны тапсам, шушыннан табармын дип, эченә кердем.

Элек мәктәп булган икән. Эче тәмйиз, матур, җыйнак. Сәхнә залына кердем. Бер татар пианино уйнап утыра. Сәхнәләрен карагач, уйнаучы янына бардым. Ул: «Татармын, татар көйләре уйныйм», – дип җавап бирде. Утырып тыңладым. Матур гына көйләр булгаласа да, башын-ахырын таба алмадым.

Бу җегет нардомның мөдире икән. Кыйраәтханәгә алып төште. Кыйраәтханәләре полный җиһазлы, матур бизәлгән ике бүлмәдән тора. Бик килешле төзелгән Ленин һәм саулык саклау почмаклары бар. Зур көзгеләр, йомшак мебельләр куелган.

Шушы зәвык белән җыелган читальняда күп татар яшьләрен – җегетләрен, кызларын, балаларын табып алу миңа тагы да күңелле булды. Мөдир күрсәтте, сөйләде. Симферопольдә «Яңа дөнья» дигән хөкүмәт газетасы һәм «Яшь куәт»

---

* 1944 елда кырым татарлары депортацияләнгәннән соң, бирегә Ростов руслары күчерелә, авылның исеме Ущельное дип атала башлый. Хәзер Ялта шәһәре эчендә.

дигән комсомол газетасы чыга икән, аларны укып карадым. Азәрбайҗанчадан күп җиңел булса да, безнең татарчадан байтак аерым тора теле. Укыганда мәгънәне тулы аңлап була, тик сөйләгәннәрендә генә аңлап калуы кыен.

«Кызыл дәгъват» исемле комсомол, «Яшь нәсел» исемле пионер стенгазеталары бар. Техника һәм эчтәлек ягы белән бик байлар. Һәммәсе белеп, дикъкатьләп эшләнгән. Матур Кырымның матур яшьләре эшләгән матур газеталарга ямьсез күзләрем белән озак карап тордым. Художниклары 16-17 яшьлек кенә бер татар малае.

Җәгъфәр Гаффаров дигән бер яшь комсомолец белән сөйләшеп утырдым. Шулай танышырга килгәнемне әйткәч, бик кызыксындылар. Күп яшьләр, исәнләшеп, килеп утырдылар. Өстәл тирәсен утырып-утырып аңлаштык. Байтак нәрсә сорашып белдем. Алар – минемчә, мин аларча аңлаша алмый, урысчага барып тотынабыз. Кырык корама тел белән беседа ясадык. Бер Әстерхан җегете килеп кереп, аның белән татарча (ягъни безнеңчә) сөйләшеп, иркен тын алып куйдым. Мәскәүдән чыкканнан бирле үзебезчә сөйләшү насыйп булганы юк иде.

« **Мин кырым татарларын Кырымның башка халыкларыннан да матуррак дип таптым. Шуның белән бергә хатыннарга караганда ирләре матуррак.**

Кырымда мөхәррирләр, пьесалар бик аз. Казан татарчасын халык аңламый, шуңа күрә пьесалары куелмый. Хатын-кызлар качмый йөри башлаганнар. Картларда фанатизм бар әле, Кырым аң-белемдә түбән тора, сөйләшкән яшьләремнең Татарстан, Башкортстан хакында мәгълүматлары юк, «Галиябану»ны белмиләр.

**Дерекуйдагы татар мәктәбе укучылары. 1904 ел**

**Ялтадагы Бохара әмире сарае. 1921 елдан Шәрык музее**

***10ысында*** докторга бардым. Ул миндә хронический слепой авыруны таба. Иш янына куш. Элеккеләре аз иде шул. Доктордан чыккач, диңгез буена барып йөрдем. Якшәмбе булганга, халык бик күп. Читтән килгән халык та күп. Ябыклар белән кыланчык хатыннар, ирләр Кырымның ямен алып йөриләр. Табигый матурлыкка кер кундыралар.

***16сында.*** Мин кырым татарларын Кырымның башка халыкларыннан да матуррак дип таптым. Шуның белән бергә хатыннарга караганда ирләре матуррак. Хатыннарын иске каты коллык, стена изгән булырга кирәк, карт чырайлы күренәләр. Алардагы матурлык моң аша сузылып кына күренә. Кызларын аз күрергә туры килә. Йә башка халыктан аерып булмаслык булганнар, йә стена арасыннан чыгып бетә алмаганнар. Бер генә бик матур татар кызы күреп, хәйран булып карап тордым. Какао төслерәк йөзле, кап-кара күзле, озын керфекле, сәрви агачы кебек зифа буйлы бу кыз хикәяләрдә сөйләнә торган комганлы кырым татары кызларын күз алдыма китерде.

Ирләрне каракүл бүрекләре таныта. Комсомоллар, укучы яшьләр кепкалардан йөрсәләр дә, күпчелек бу бүрекне ташлый алмаган әле. Ул безнең казан татар бүрегеннән килешлерәк. Яшь җегетләрнең бөдрәләп чыгарган күгелҗем кара чәчләре өстендә бик матур булып утыра. Татар җегетләре, гомумән, матур, шат, уенчак. Төсләренең күмер кебек булуы, чәчләренең күгелҗем каралыгы, күзләренең ялкынлылыгы, буй-сыннарының купшылыгы Кырымның җәнүби табигатенә бик килешеп, нур өстенә нур биреп тора.

Татар җегетләрен тасвир иткәндә рус мөхәррире Куприн болай ди: *«Зифа буй, каракучкылрак тән; каш, борын, иреннәрнең тәгърифтән тыш төз һәм туры эшләнүләре; күпереп торган кара мыеклар; кырын салган бүрек астыннан чыгып торган күгелҗем кара чәчләр; күзләрне камаштырырлык гаҗәеп ак тешләр; бадьян агачы төслерәк куе кара һәм ялкынлы җәнүби күзләр; кибарани төз муеннар... Кырымның җәнүб яры бу урынга, үзенең, инсаният җенесенең һиндуз, юнан һәм татар каннарының фәүкыльгадә бәхетле кушылуыннан пәйда булган кавемнең иң матур үрнәкләрен җибәргән...»* Мин Купринның сүзләренә пичәт сугам.

Бүген Шәрык музеен карарга бардым. Музей борынгы Бохара әмиренең сараенда. Читтән үк сарайның ай-йолдызлы купол һәм манарасы агачлар арасыннан күренеп тора. Элек сарайның бакчасын карадым. Кипарис, пальма, каштан, слива, инжир, алма агачлары арасындагы шәрыкча салынган саргылт буяулы дворецны бик сокланып карап йөрдем. Парадный ишеге бөтенләй шәрыкча төрле буяу белән чуарлап буялган.

Сарайның эченә кергәч, 30 тиенгә билет алдым. Аягыма кызыл киез башмак кидерделәр. Музейны карый башладым. Иң элек персидский бүлмә. Аннан кавказ, гарәп, үзбәк, кытай, япун, татар бүлмәләре. Персиян, кавказ, гарәп, үзбәк бүлмәләре бөтенләй келәм белән чорналган. Киемнәр, кораллар, йорт җиһазлары, китап – Коръән, намазлык кебек дини нәрсәләр – бар да монда бар. Иң матуры – гарәп бүлеме. Бу бүлем бай. Бик нәфис, матур нәрсәләр бар. Бүлмәсе дә ифрат шәп. Ул шулкадәр нечкә сырлар белән чуарлап, алтынлап буялган ки, карап туйгысыз. Төрле җирләргә вак көзгеләр кыстырып калдыру тагы да матурлап тора. Тәрәзә пәрдәләре ай-йолдызлап ука белән чикләгән ал җефәк. Алар озын булып сөйрәлеп торалар. Чынлап та, чын мөселман падишаһының сарае. Монда әмирнең үз җиһазлары да күп. Яуропачаларын монда куймаганнар. Андыйлардан бөтен җире чын сәдәф белән чуарланган бер иш мебельләрне күрдем. Сарайда әмирнең үзе утырган бер креслосы бар. Тоташ алтын белән буялган. Кызыл хәтфә мендәрле, тагы әллә никадәр нәрсә. Бүлмәләрнең төрлесе-төрлечә буялган. Бер бүлмәнең стенасына гарәпчә нечкә генә итеп төрле шигырьләр язылган. Шәрыклык аңкып тора. Шәрык музее бу сарайны хаслап бик дөрес эшләгән. Үзбәк бүлемендәге түшәмгә Бохара Шәрифләре белән әллә нинди матурлык бирә белгәннәр. Кырым татарлары бүлеме өске этажда. Кырымның үзендә булуында карамый, ул ярлырак. Күрергә теләгән күп нәрсә юк. Һәрхәлдә, Ялтага килүчеләр өчен бу музей күрергә тиешле бер урын. Мин, музейдан бигрәк, бер падишаһның сарае булу ягы белән кызыксындым.

***17сендә*** «Дерекуй халык өе»нә бардым. Галириза Хөсәенов аркадаштан күп нәрсәләр сорашып белдем. «Коммунага»мны көтепханәгә бүләк иттем. Ул минем күрергә кызыксынган җирләремне күрсәтергә дип алып китте. Бакчаларга, су буйларына бардык. Агачлар, таулар, җылгаларны өйрәтте, яфраклар өзеп бирде. Комсомоллар хәлен дә сораштым. Үз хәлен дә сөйләде. Кругом ятим, ярлы бер батрак. Хәзер бакча эшенә практикант булып кергән. Бик аз хак ала. Үзе 18 яшьтә, сөйкемле, матур җегет. Миңа күп-күп булышлыгы тиде һәм шәһәргә чаклы озатып, тагы булышлыклар вәгъдә итеп калды.

***19ында*** барып үлчәндем. Арту урынына атна эчендә ¼ кадак кимегәнмен. Шуны көтәдер идем. Докторга бардым. Ул нык карады. Бер авыру да юк дип ышандырды. Бу нервный кешеләрдә була торган бер хәл икәнлекне әллә никадәр мисаллар, гыйльми күрсәтүләр белән сөйләде. Эчәкләрнең ничек эшләвен, фәләнен иренмәстән сөйләп бирде. Эчәргә бер дару (бром, валерьяннар) һәм боржом бирде. Иң нык дару – авыру юк дип уйлау, ди. Мин дә шуның белән канәгатьләнеп, рухланып чыктым. Теләсәгез нишләгез, әфәнделәр, минем эчемдә авыру юк!

Аннан чыккач, диңгез буена төштем. Бу як сахраракак. Җирләр үләнле. Иркенләп, рәхәтләнеп йөрдем. Диңгез белән уйнадым. Дулкын белән куыштым. Пароходлар, катерлар, моторлы лодкалар үтә. Күңелле җир бу диңгез буйлары, җанны ирексез рәхәтләндерә.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2022

# Татарның таланган алтыны

*(Дәрдемәнд гаиләсе буенча яңа чыганаклар)*

**Лилия Габдрафикова**

Дәрдемәнд, гомумән, Закир белән Шакир Рәмиевләр турында шактый материал дөнья күрде. Бигрәк тә Лирон Хәмидуллинның шул юнәлештә эзләнүләре зур урын алып тора, һәм, әлбәттә, «Шәхесләр» сериясендә чыккан бик яхшы китап бар. Моннан тыш, шагыйрь иҗаты буенча диссертацияләр дә яклаган. Бу, билгеле, бик күркәм күренеш. Әмма алар калдырган эзләр болар белән генә чикләнми. Бигрәк тә музей фондларында сакланган чыганаклар әлегә тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән.

Мәкаләмдә сезне кечкенә генә ике документ белән таныштырырга уйлыйм. Ул документлар Закир Рәмиевнең Җәгъфәр исемле улы һәм оныгы Зөбәрҗәт белән бәйле. Беренчесе – улының автобиографиясе. Датасыз, әмма чыганакның эчтәлегеннән һәм кара белән язылуыннан, аны 1960 нчы елларда язылгандыр дип фаразлый алабыз. Икенчесе – оныгы Зөбәрҗәт ханымның 1989 елда язган кыска гына истәлекләре. Ике документ та урыс телендә һәм Башкортстандагы Учалы шәһәре муниципаль музеенда саклана.

***

«Шәхесләребез» сериясендә чыккан китапта Закир Рәмиевнең улы Җәгъфәр турында шундый мәгълүмат китерелә: 1893 елда туган, 1976 елда үлгән. «Хөсәения» мәдрәсәсендә рөшди сыйныфларында укыгач, Оренбург реаль училищесын тамамлый. Гражданнар сугышы вакытында Муса Мортазин җитәкчелегендәге башкорт атлылары бригадасы белән Киевка кадәр барып җитә, поляклар белән сугышта бер кулсыз кала. Аннары Орск шәһәренә, әти-әнисе янына кайта. Әнисенә кардәш Гөлнур Борнаевага өйләнә. Ике улы – Морад белән Фуад һәм бер кызы Зөбәрҗәт туа. «Варисларында үзе язган шигырь дәфтәрләре саклана. Җәгъфәр, Дәрдемәндкә багышланган истәлек кульъязмасын һәм атасының кайбер язмаларын тотып, илленче еллар урталарында Казанга да килгән. Ул язмалар язмышы әлегә билгесез», – дип яза Лирон Хәмидуллин. Кызы Зөбәрҗәт: «Бездә андый язмалар юк», – дигән.

Бу язмаларның язмышы әле дә ачыкланмаган. Учалы музеенда, кызганыч ки, Дәрдемәнднең шәхесенә багышланган истәлекләр юк. Әмма тәкъдим ителгән

**Шагыйрь Дәрдемәнднең шәкерт вакыты**

чыганаклар Закир Рәмиев балаларының язмышлары хакында бераз өстәмә мәгълүмат бирә.

Мәсәлән, Җәгъфәр Рәмиев үзенең автобиографиясендә туган елы дип 1895 елны күрсәтә («Шәхесләребез»дә – 1893 ел). Туган җире – Орск өязенең Юлык авылы. Җәгъфәр әфәнде үзенең алтын табучы эшкуар гаиләсендә тууын да әйтеп уза. Балачагының тәүге еллары Верхнеуральск өязендә үтә. Бу урыннарда Рәмиевләрнең алтын приискалары булган. Зөбәрҗәт ханым үз язмаларында Рәмиевләр гаиләсе җәйне приискаларда, ә кышны Оренбургта үткәргәннәр дип ассызыклый.

Җәгъфәр Рәмиев үзенең беренче белем алуы турында язганда, 8-9 яшеннән алып Оренбург реаль училищесында укыганын гына күрсәтә. «Хөсәения» мәдрәсәсе турында сүз бу чыганакта юк. 1915 елда реаль училищены бетергәч, ул Воронеждагы авыл хужалыгы институтына укырга керә. Әмма, инкыйлаб һәм Гражданнар сугышы башлану сәбәпле, 1918 елда укуны ташлый. Җәгъфәр Рәмиев 1919 ел башында Оренбургка кайта һәм шушы елның август аенда Башкорт кавалерия бригадасына эләгә. Уралдагы бәрелешләрдән соң, Украина фронтына җибәрелә. Монда 1920 елда була һәм, шушы сугышлар нәтиҗәсендә, сул кулы каты яралана. Соңрак кулы корый башлый, инвалид хәлендә Орскига кайта. Бу вакытта әле аның әтисе исән була. «Беренче ел бер кәсеп белән дә шөгыльләнмәдем», – дип яза Җәгъфәр әфәнде.

1921 елда Закир Рәмиев, тиф чире белән авырып, бакыйлыкка күчә. Булган мал-мөлкәтен ул исән чагында ук хөкүмәткә тапшыра. Әмма, Зәки Вәлиди язуынча, Закир Рәмиев үзенең яңа хәятенә бик хафаланмый, тәкъдирем шулдыр, дип кабул итә. НЭП заманында аның гаиләсе, үзләре өйрәнгәнчә, искечә, тырышып сәүдә кәсебе белән көн күрә, ахрысы. Мәсәлән, Җәгъфәр Рәмиев, инвалид буларак пенсия акчасын алмыйча, бушлай сәүдә патенты ала. Бу заманда сугыш инвалидларының шундый хокуклары була. Шул патент буенча ул 1927 елга кадәр сәүдә итә, патентларны бирми башлагач, «кустарь-приказчик» булып теркәлә. Бу инде кооператив карамагында сәүдә итү булгандыр. Җәгъфәр Рәмиев шушы кәсеп белән 1931 елга кадәр шөгыльләнә. Моннан соң ике ел чамасы төрле эшләрдә эшләп карый. Орскида «Жигули» сыра кайнату трестында да хезмәт итә, умартачы булып та хезмәт куя…

Җәгъфәр Рәмиев әлеге язмаларында НКВД органнары белән мөнәсәбәтләре турында язмый. Әмма кызы Зөбәрҗәт әтисе турындагы истәлекләрендә: «Подвергался преследованию: порой вызывали на допрос, не приняли в партию», – ди. Шушы тынгысыз тормыш аны 1933 елда туган ягын калдырып Башкортстанның Учалы районындагы Поляковка дигән урыс авылына күчеп китәргә мәҗбүр иткәндер, мөгаен. Монда XIX гасырдан ук төрле шахталар һәм приискалар була. Бу урыннар «Алтын үзәнлек»кә керә. Аның территориясе Миәс шәһәреннән башлап Миндәк дигән бистәгә кадәр сузыла. Совет чорында монда Миәс алтын сәнәгате округы булдырыла һәм Поляковкада икенче Башкомбинат эшли башлый. Соңрак ул «Миассзолото» дип атала, ә 1933 елда инде «Башзолото» трестына кертелә.

Закир Рәмиевнең Искәндәр атлы улы Поляковкага алданрак килеп урнаша. Ул монда инженер булып эшли. Искәндәр Рәмиев 1886 елда дөньяга килә һәм Петербургта гимназия бетерә, аннары, немец телен яхшы үзләштергәч, Германиядәге Фрайберг тау академиясендә укый. 1914 елда аны бетереп, туган ягына кайта. Әлбәттә, мондый затлы гаиләдән чыккан һәм чит илдә белем алган

**Искәндәр Рәмиев (сулдан беренче) Германиядә Тау академиясендә укыган иптәшләре белән. 1914 ел**



**Бәшир Рәмиев уйлап тапкан «Урал-1» электрон хисаплау машинасы**

кеше НКВД органнарының игътибарына да эләгә һәм 1938 елда репрессияләнә. 1943 елда Искәндәр Рәмиев Томск шәһәре янындагы ГУЛАГта вафат була. 1950 нче елларда аклана.

Искәндәр Рәмиевнең улы Бәшир – техник фәннәр докторы, бу өлкәдә зур казанышларга ирешә, беренче ЭВМның баш конструкторы була. Әлеге компьютер, галимнең туган ягын истә тотып, «Урал» дип атала. Моннан тыш, аның җитәкчелегендә «Погода», «Гранит» һәм Кристалл» исемле ЭВМнар да ясала.

Җәгъфәр Рәмиев

Җәгъфәр Рәмиев абыйсы Искәндәр янына килеп урнаша һәм озак еллар Поляковкада бухгалтер булып эшли. Шул юнәлештә махсус белем ала. Кызы язганча, сугыш алдыннан ул Мәскәүдәге Югары бухгалтерлар курсын читтән торып бетерә. Аның башкалага күчеп китү нияте дә була. Абыйсы Искәндәр репрессияләнгәч, зур шәһәргә, кеше нинди гаиләдән икәнен белмәгән җиргә күчәсе килгәндер, күрәсең. Эш буенча чакыру да ала, әмма, сугыш башлангач, Поляковкада кала, приискадагы эшчеләр арасында зур хөрмәт казана. 1950 елда Поляковка приискасының күләме кимү сәбәпле, Җәгъфәр әфәнде кыскартылуга эләгә. Соңгы елларда ул Учалы районыннан ерак булмаган, әмма Чиләбе өлкәсенә кергән Алтын Таш бистәсендә эшли. 1967 елда Җәгъфәр Рәмиев «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнә. 1977 елда Алтын-Ташта вафат була.

Аның 1932 елда туган игезәк уллары, бабалары кебек үк, техник белемгә омтыла. Фуад Җәгъфәр улы Рәмиев Новосибирск тимер юл институтын тәмамлый, Чиләбедәге гыйльми-тикшеренү институтында баш инженер булып хезмәт итә һәм шундагы училищеда укыта. Аның гаиләсе булмый. Морад Җәгъфәр улы Рәмиев Тау техникумын тәмамлый, Мәскәү Тау институтында белем ала. Күпмедер вакыт шушы юнәлештә Махачкалада эшли. 1980 нче елларда инде, Зөбәрҗәт ханым истәлекләреннән күренгәнчә, ул Чиләбе өлкәсенең Конашак районындагы Усть-Багаряк дигән авылда торган һәм гипс карьерларында эшләгән. Аның гаиләсе турында мәгълүмат бу чыганакта юк.

Зөбәрҗәт Җәгъфәр кызы Рәмиева 1928 елда туган, Чиләбе өлкәсендәге Златоуст шәһәрендә педучилищеда укыган. Ул озак еллар дәвамында Учалы районының төрле авыл мәктәпләрендә урыс теле укыта һәм башлангыч классларда укытучы булып эшли. 1973 елдан бирле Учалы районындагы Сәфәр авылында укыта. Хәзер инде Зөбәрҗәт Җәгъфәровна үзе дә мәрхүмә. Истәлекләрендә ул өч улы булганлыгы турында язып үтә. Аларның фамилияләре – Иксановлар. Бер улы 19 яшендә вафат була. Ике улының 1980 нче еллар ахырында Николаев һәм Сургут шәһәрләрендә яшәве мәгълүм.

Сәфәр авыл халкы Зөбәрҗәт Җәгъфәровнаны гади, тыйнак, әкрен генә сөйләшә торган ханым дип хәтерли. 1990 нчы елларда да ул бабасының атаклы шагыйрь Дәрдемәнд икәнлеген авыл халкына сөйләп йөрмәгән. Шулай да, укымышлырак авылдашлары аның кыз фамилиясе Рәмиева булганын белеп, шагыйрь белән туганлык мөнәсәбәтләре хакында сораштырганда, ул үзенең нәселен инкяр итмәгән. Музейдагы чыганак та Зөбәрҗәт ханымның бабасы Дәрдемәнд һәм башка туганнары белән горурлануы турында сөйли. ■

# Сиринә Сәлимшина: «Җиңүгә иманлы кешеләрнең кылган догалары китерде!»

*Ата-баба мирасы, дип, элеккеләрдән калган кульязмаларны кадерләп саклаучы, өйрәнүче шәхесләребез күп түгел. Шуларның берсе – Татарстанның атказанган көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре, «Дөнья – ахирәтнең игене яки Нарыш җәүһәрләре» һәм «Маңгай сырларына уелган язмыш хатирәләре» исемле китаплар авторы* ***Сиринә Сәлимшина-Шаһимәрданова.*** *Редакциябездә очрашып, без аннан нәсел шәҗәрәсе төзү һәм борынгы китапларны өйрәнү юнәлешендәге тәҗрибәсе белән уртаклашуын үтендек. Моннан тыш, ул әтисе – совет чоры имамы, фронтовик, күп кенә дини китаплар авторы һәм гап-гади тегермәнче Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин турындагы истәлекләрен дә сөйләде.*

***– Совет чорында динне дә тоткан, дөньялыкны да онытмаган Исмәгыйль хәзрәт кем ул?***

– Әтиебез Исмәгыйль Сәлимшин 1893 елны Башкортстан Республикасының Туймазы районындагы Нарыш авылында дөньяга килә. Шунда аның яшьлек еллары уза. 1921 елгы ачлыкта ул, эш һәм ризык эзләп, Ютазы районындагы Кәрәкәшле авылына барып чыга. Шунда үз көче белән тегермән корып, дөнья көтә башлый. 1922 елда Урыссу авылында яшәгән Сөләйман кызы Гайнелҗинан белән гаилә кора. Гайнелҗинан тегермән өендә яшәгән вакытта тугыз бала табып, аларны бергә тәрбиялиләр. Кызганыч, дүртесе яшьли вафат була. 1930 нчы елларда әти гаиләсе белән Казакъстан якларына бәхет эзләп чыгып китә. Бөек Ватан сугышына исә Ютазы хәрби комиссариатыннан юл ала. Сугыш вакытында бөтен Европаны гизә ул. Бу хакта аның көндәлекләре сөйли. Ике мәртәбә яраланып,1945 елның августында гына туган ягына кайта әтиебез. 1946-1950 нче елларда Кәрәкәшледә тегермәнче булып эшли. 1950 нче елларда Нарышта яши башлый һәм шунда дини эшләр белән шөгыльләнә. 1959 елда әниебез дөньядан китте. Әни авырган чагында да, вафат булгач та, әти безгә әни дә, әти дә булды. 1975 елда әтиебез Исмәгыйль хәзрәтнең вафат булуы турында кайгылы хәбәр килде…

***– Сез – Исмәгыйль хәзрәтнең васыятьнамәсен байрак итеп күтәреп, татар дини-мәдәни тормышында әлеге традицияне яңартып җибәргән кеше...***

– Бу эшкә урау юллар аша килдем. Гомернең иң гайрәтле чагы бөтенләй башка өлкәдә – ТАССР Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министрлыгында үтте. 1996-1999 нчы елларда гына, Болгар мәчетенә барып, Халисә абыстайда дини гыйлем алдым. Әти мулла булса да, аннан дини белем алу насыйп булмады, намаз да укый белми идем. Автобус белән хаҗга юл тотып, үземнең туган көнемдә – 1 февральдә изге Мәккә җиренә аяк бастым.

Дөрес, өлкән абыстайлардан васыять һәм шәҗәрә дигән сүзләрне еш ишетә идем. Әтиемнең 1973 елда язган васыятьнамәсе күңелемә һич кенә дә тынгы бирмәде. Үтибезме без анда язылганнарны, әллә дөнья мәшәкатьләренә чумып оныттыкмы? Күз нуры, җан авазлары белән язылган васыять бит бу. Әтинең вафатыннан соң, ул апаларда сакланган. Ул туры юлны ничек табарга, ничек итеп шуннан тайпылмыйча гомер итәргә, балаларыбызны тәрбияләргә, яшь чактан ук дин гыйлемен өйрәтергә кирәклеген аңлата. Әтиебез аны озак уйлап, һәр сүзен җентекләп бәян иткәндер дип уйлыйм. Бу васыятен сөекле балаларына атап язса да, аны хәзерге көндә барлык кешеләргә дә бик кирәкле дип саныйм. Аны васыять язу буенча өлге-үрнәк итеп кабул итәм. 2014 елда мин шушы васыятьне «Ярдәм» мәчетендә узган остабикәләр җыенында укып, барлык абыстайларга да үз васыятьләрен язып, конкурс уздыруларын тәкъдим иттем. Татар кешесенең васыяте ул

**«И балалар, и туганнар! Барчагызга да шуны әйтәм: үзегездән кечеләрнең килешмәгән эшләренә нык күзәтчелек итегез. Шулай, балалар, Аллаһ риза булмаган эшләрдән бөтен көчегез белән сакланыгыз. Коръән кушканча яшәгез, чөнки безнең мәңгелек бәхетебез Коръән бит. Ягъни Коръән юлы гына безнең тугры юлыбыз. Коръәнгә ышанмаучыларга бик нык куркыныч».**

***И.Сәлимшин васыятеннән***

матди мирасны балаларга бүлеп калдыра торган рәсми документ кына түгел, ә киләчәк буынга әйтер сүз, үгет-нәсыйхәт тә булырга тиеш. Ә иң мөһиме – яшьләргә дин исламны саклауны һәм өйрәнүне васыять итеп, үзеңнән соң догачылар калдыру. Монда матди байлык кына түгел, ә рухи кыйммәтләр – тугрылык, намус, әхлак турында да сүз бара. Исмәгыйль хәзрәтнең васыятьнамәсе вакытлы матбугатта да дөнья күрде, соңрак мин аны дини чараларда һәм мәҗлесләрдә тарата башладым. Миңа калса, әтием әлеге эшне борынгы имамнар, укымышлылар үрнәгендә башкарган булырга тиеш.

***– Шуннан шәҗәрәләр гыйлеменә кереп чумдыгыз...***

– Милли тарихыбыз, әдәбиятыбыз өчен борчылып йөрүче Мәдинә Әбделганиева белән таныштым. Ул миңа: «Исмәгыйль хәзрәттән шундый мәгънәле васыять калган, ул, һичшиксез, затлы нәселдән булырга тиеш. Сиңа үзеңнең нәсел шәҗәрәсен торгызырга, борынгы бабаларыңны барларга вакыт», – диде. 2015 елда Мәдинә ханым әтисе – совет чорының күренекле мулласы, дин эшлеклесе Хәниф Вәлиевнең нәсел шәҗәрәсе турында китап бастырып, барлык туган-тумачаларына таратты. Нәсел шәҗәрәсен барлау борынгы бабаларыңны өйрәнү генә түгел, ә дөнья буенча сибелгән туган-тумачаларыңны бер канат астына җыю дигән сүз дә. Үз-үземә: «Мин дә, башкалар кебек, бу эшне башкара алам түгелме соң?» – дигән сорау бирдем һәм, тарих дәрьясына чумып, әлеге юнәлештә үз эшенең осталары булган кешеләр белән аралаша башладым. Архив материалларын барлаудан тыш, әлбәттә, әтиебезнең кече ватанына кайтырга, туганнар белән дә якынаерга кирәк иде. 2015 елда Нарыш авылына ике мәртәбә барып, әтием узган юллардан йөреп, элеккеләрнең яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен өйрәндем. Исмәгыйль хәзрәтләр буыны ничек көн күргән? Дингә каршы пропаганда чорында дини йолаларны ничек итеп башкара һәм саклап кала алган? Ничек итеп дини мәгариф белән шөгыльләнергә җөрьәт иткән? Миңа боларның барысы да кызык иде. Шәхсән үзем әтием кебек шәхесләрнең үҗәтлеге, кодрәте, көч-куәте белән генә динебез, борынгы йолаларыбыз исән калгандыр дип уйлыйм. Безне хәзерге мул, матур тормышка, һичшиксез, аларның кылган догалары китереп җиткергән. Әйе, әтиләребезгә бик авыр булган, әмма шунысы хакыйкать: һәр авырлыктан соң җиңеллек килә. Аллаһка шөкер, бүген динебез үсештә, мөселманнарның саны елдан-ел арта.

**«Яхшы булсак та үзебез өчен, начарлыкка да җәзасы үзебезгәдер».**

***И.Сәлимшин васыятеннән***

**«Һәр эшегезне Аллаһыга тапшырып башкарыгыз. Хак Тәгалә Үзенә багышлап эшләгән гамәлне һич вакытта артта калдырмас».**

***И.Сәлимшин васыятеннән***

Шәригатебез туганнар белән мөнәсәбәтне ныгытырга куша. Әлеге сәфәрдә мин Нарыш авылында һәм Октябрьск шәһәрендә яшәүче туган-тумачаларым белән күрештем. Алардан әти турында бераз булса да мәгълүмат аласым килде. Шәҗәрә төзегәндә болар бик мөһим! Бер генә шәхес тә, исем дә читтә калырга тиеш түгел! Шушы вакытта Сәлимшаһ бабай ыруыннан булган барлык балаларының, онык-оныкчыкларының исемнәрен, туган елларын, торган җирләрен ачыклап, күп мәгълүмат җыйдым.

Кызык кына бер очрашу турында да сөйлим әле. Эзләнә торгач, Төрекмән авылы мәчетенә килеп чыктым. Нарышта мәчет булмау сәбәпле, әтием, 12 чакрым юлны җәяү үтеп, шунда намазга йөри иде. Мәчеткә килеп керү белән, иң карт бабай белән таныштыруларын үтендем. 100 яшьлек Габделхәй бабайның каршына килеп бастым. Аның белән озак гәпләштем. Бабай бик матур итеп әтием турында сөйләде. Ул: «Исмәгыйль бабай бик гыйлемле, галим кеше иде. Җомга намазларын ул килеп җитмичә башламый тора идек», – дип искә алды. Әтиебез бу көнне чын күңеленнән көтеп алып, әзерләнеп, мәчеткә барган. Авыл халкының аңа карата хөрмәте зур булган. Мәчетнең үз имамы булса да, җәмәгать намазларын укытуны аңа тапшырганнар. Моннан тыш, Төрекмән авылының имамы әтигә Нарышта дини йолаларны башкару вазыйфасын да йөкләгән. Әтием Исмәгыйль хәзрәт вафатына чаклы балага исем кушу, никах уку, җеназа кебек бик тә мөһим дини йолаларны җиренә җиткереп үтәде.



**Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин. 1965 ел**

***– Исмәгыйль хәзрәтнең язма мирасы нидән гыйбарәт?***

2015 елның азагында мин шәҗәрәне тәмамладым. Аллаһка шөкер, Сәлимшаһ бабай нәселенең алты буынын архивтан чокып чыгардык. Иң борынгы бабабыз Габделкәрим 1770 нче елларда яшәгән икән. Ә оныкларым унынчы буын балалар була инде. Шәҗәрәне гади генә итеп ясап, барлык туганнарыма да тараттым. Инде диндар дустым Мәдинә: «Сиринә, васыятең бар, шәҗәрәң әзер, әтиең турында китап язарга кирәк», – диде. Бу вакытларда ул, әтисе турында китап язып, миңа бүләк иткән иде инде. Минем алга тагын бер мөһим мәсьәлә килеп басты. Дөрес, китап язарга әзер түгел идем, бер ярдәмчем дә юк, апалар вафат... Шулай итеп, җиң сызганып, татар галимнәренең китапларын укый башладым. Бу эш миңа өр-яңа дөнья ачты.

Совет чорында ислам динен башкаларга өйрәтү өчен махсус китаплар, догалыклар хәзерге кебек күпләп басылмаган. Бу эшне Исмәгыйль хәзрәтнең үзенә эшләргә туры килгән. Ул революциягә кадәр дөнья күргән дини китапларны күчереп, башка-

> **«Аның рухи-әхлакый кыйммәтләрне шигъри калыпка салып җиткерүен, совет чорында китапны кулдан күчереп язу традициясен дәвам итүен аеруча мөһим факт дип саныйм.**

ларга бүләк иткән, халыкка үгет-нәсыйхәт биргән. Үзе дә вәгазь китаплары язган, төрле догалыклар төзегән, тәфсир-тәрҗемәләр ясаган һәм дини эчтәлекле шигырьләр иҗат иткән. Аның рухи-әхлакый кыйммәтләрне шигъри калыпка салып җиткерүен, совет чорында китапны кулдан күчереп язу традициясен дәвам итүен аеруча мөһим факт дип саныйм. Борынгы татар мәгърифәтче әдипләреннән, Шәмсетдин Суфи, Габденнасыйр Күлтәсиләрдән килгән традиция бит бу! Нарыш авылында туганнарым белән очрашып, бер йөк материал төяп кайттым. Анда әтидән калган 160 данә китап, кульязмалар, календарьлар, газета-журналлар һәм фоторәсемнәр бар иде.

**«Үзегезне зур күреп йөрмәгез, бер төрле җан иясен дә гаепләмәгез. Һәрбер гаептән пакь булучы Раббыбыз Үзе генәдер. Авырлыклар килсә, кешедән күрмәгез, һәр авырлык һәм тарлык үзебезнең начарлык сәбәбеннән киләдер».**

***И.Сәлимшин васыятеннән***

Наҗия апамның кызы Зөһрә, Фәния апамның кызлары Ләлә белән Лилия, икетуганым Зәкуан һәм Флүрә миңа бик кирәкле һәм бай ядкярләрне бирде. Алып кайткан кыйммәтле мәгълүматлар әлеге китапның нигезен тәшкил итте. Әмма бер проблема килеп туды: әтиемнең бөтен кульязмалары иске имляда татар яки гарәп телләрендә язылган. Мәчеттә укып, башлангыч белем алсам да, кульязма мирас белән эшли алырлык тәҗрибәм юк иде. Әмма бу өлкәдә эшләүче яхшы белгечләр бар. Миңа яшь галим Александр Долгов ярдәм күрсәтте. Улым Айдар, 2017 елда китабымны бастырып, 1 февральдә юбилеема бүләк итте.

Шулай итеп, алдыма дүртенче сорау килеп басты. Ул да булса – әтиемнең исемен мәңгеләштерү мәсьәләсе. Китап халыкка, җәмәгатьчелеккә барып җитәргә, укылырга тиеш! Тәкъдим итү кичәсен өч мәртәбә үткәрдем, Нарыш мәчетендә «Мирас» киштәсен оештырдым. Анда әтиемнең васыяте, кульязмалары, кайбер шәхси әйберләре урын алды. Төркия, Германия, Австралия һәм Кыргызстанда яшәүче туганнарыма, дусларыма, абруйлы дин галимнәренә дә китабымны бүләк иттем. Шулай итеп, хезмәтем төрле илләр буенча таралды.

***– Хәзрәтнең тормыш юлында ачыкланмаган ак таплар калдымы? Рәсми хакимият тарафыннан аны эзәрлекләүләр булганмы?***

– Кызыксыну моның белән генә бетмәде. Әлбәттә, кайбер сорауларга җавап таба алмадым. Мәсәлән, әтием Исмәгыйль хәзрәт кайда укыган һәм кемнән белем алган? Гомере буе тегермәнче булып эшләп тә ул халыкка ничек аң, мәгърифәт нуры чәчә алган? Һичшиксез, зур галим булган! Миңа бу турыда сөйләүчеләр күп булды. Коръән укыган һәм шунда ук тәфсир-тәрҗемәсен дә әйтеп бирә алган. Ул яшәгән заманда кемнән гыйлем алуны әйтергә ярамый иде. Әмма бу минем өчен бик мөһим. Революциягә кадәр тирә-яктагы галимнәр Бәйрәкә мәдрәсәсендә белем эстәгән. Әтием дә, мөгаен, шунда укыгандыр дигән фикергә килдем. Әмма төпле дәлил таба алмадым. Әлбәттә, Исмәгыйль хәзрәт зур мәдрәсә тәмамлаган кеше булырга тиеш. Ул бөтен гомерен, хезмәтен дингә багышлаган. Дин, иман ныклыгы аны сугыш кырыннан исән-имин кайтарган. Без еш кына Бөек Җиңү, фронтовикларның батырлыклары турында сөйләргә яратабыз. Әмма сугышта җиңеп чыгуда дини кешеләрнең зур өлеше бар икәнлеге, Бөек Җиңүгә аларның кылган догалары китергәнлеге турында онытып җибәрәбез.

**Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин яшәгән йорт**

Эзәрлекләү булгандырмы-юкмы – анысын белмим. Бәлки, аңа гап-гади тегермәнче булуы ярдәм иткәндер. Әмма Исмәгыйль хәзрәт дин-гыйбадәт мәсьәләсендә совет органнарыннан куркып яшәде, чамалап-үлчәп кенә сөйләште, бик сак булды. Әти-әниемнең тәрәзә пәрдәләрен корып, ишекне бикләп, яшертен генә намаз укуларын, сәхәр ашауларын, ураза тотуларын яхшы хәтерлим. Күрше-тирәдәгеләр дә, кача-поса булса да, аның янына укырга керә иде. Ул үзенең васыятендә дә: «Их, балалар! Мин бит сезнең өчен дә бик куркам әле...» – дип язган.

***– Әтиегезнең васыяте үтәләме?***

– Бу васыять – безнең тормыш китабы. Шәхеснең нигезле дәвамчылары булмаса, ул югала. Аллаһка шөкер, без, балалары, оныклары, аның васыятен үтибез, ул салып калдырган юл белән алга барабыз. Гаиләләребезнең тыныч һәм дустанә яшәвенең сере дә шунда дип уйлыйм.

Теләгем шул: һәр кеше фани дөньядан киткәндә дин исламны саклауны васыять итеп әйтеп калдырырга тиеш. Яшь буын, әгәр дә сине хөрмәт итә һәм рухыңны рәнҗетергә теләми икән, васыятьтә әйтелгәнне үтәргә мәҗбүр. Журнал укучыларыбыз ата-бабаларының нәсел шәҗәрәсе белән кызыксынсын, мирасларына битараф булмасын һәм туганлык җепләрен ныгытып, мал-мөлкәте, гыйлеме, сәламәтлеге җиткәнче башкаларга ярдәм итеп яшәсен иде.

***– Татар дөньясында Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин кебек шәхесләр һәм аларның өйрәнелми-барланмый калган ядкярләре әле бихисап күптер дип уйлыйм. Хезмәтегез башкаларга үрнәк булсын!***

*Әңгәмәдәш* – ***Ленар Гобәйдуллин*** ■

Безнең мирас №2 февраль 2022

# Без – Чыңгыз хан варислары!

Фарук Нәфиев



**Чыңгыз хан уллары белән. XIV гасыр фарсы манускриптыннан миниатюра**

Галәм, дөнья, материя, җисем һәм яшәеш, тормыш, гомер – ифрат катлаулы төшенчәләр. Аларны тирәнтен аңлау һәм гади халыкка җиткерү өчен, Җир шарында йөзләгән академия, университет, институтларда йөзләгән галимнәр эшли. Шулай да хакыйкать, чынбарлык укымышлылар өчен дә һаман катлаулы мәсьәлә булып кала бирә. Әйтик, белепме-белмичәме, әллә үзләренең милли мәнфәгатьләрен күздә тотыпмы, махсус рәвештә кайбер тарихчыларның ялган-ялгыш мәгълүмат таратуы аркасында бик күпләрнең гасырлар буена инанып килгән караш-фикерләрен яңабаштан өйрәнеп, анализлап, тәфтишләп тамырыннан үзгәртергә туры килгән очраклар да аз түгел.

Көннәрнең берендә мин күрше-тирәдә яшәүче шактый укымышлы танышбелешләремә бер үк сорауны бирдем. Сүз куешканнар диярсең, барысының да җавабы бертөсле иде.

«Бөек Даланы, Кытайны, Азиядәге күп дәүләтләрне – ул чордагы ярты дөньяны яулап алып үз империясен төзегән Чыңгыз хан кайсы милләттән булган?» – дигән сөаль иде ул.

– Моны Мәнди алашасы да белә. Ул, кәнишне, монгол булган, – диде күп еллар элек Казанда төзелеш-архитектура институтын тәмамлаган күршем Мөби Корбангали улы Әхмәтов.

– Башта урта мәктәптә тарих укыткан, соңыннан авыл хуҗалыгы институтында да хезмәт куйган, чәчләренә чал кергән профессорның да Чыңгыз хан монгол булган дип раслаганын яхшы хәтерлим. Монысы агрофирма җитәкчесе булып эшләүче икенче иптәшемнең җавабы.

Бер уйлаганда, әлеге җавапларга бер дә гаҗәпләнәсе юк кебек. Хәтта университетыбызның тарих-филология факультетында укыганда да мәшһүр профессорларыбыз: «Ярты дөньяны яулап алган полководец Чыңгыз хан монгол булган», – дип өйрәттеләр.

Чын дөреслек-хакыйкатьне ачыклау, ялган мәгълүматларны юкка чыгару өчен бер генә юл бар: ул да булса – дөньядагы бай мәгълүматлы хроникаларга, төрле архивларга, шул чорда яшәгән галим һәм язучылар акка кара белән язып калдырган истәлекләргә мөрәҗәгать итү.

Үз дәүләте тирәсендә һәм ерактарак җирләрдә дә яшәгән халык-кабиләләрне җентекләп теркәп, махсус өйрәнеп барган Кытай хроникалары XII гасырда яшәгән күпсанлы татар кабиләләренең өч төркемнән торуы хакында язалар. Беренчесе – Ак татарлар. Алар Гоби чүленнән көньяктарак, Бөек Кытай дивары буенда яшәгәннәр, Чин мәдәнияте тәэсирендә булып, сәяси яктан Төньяк Кытайга буйсынганнар. Икенче төркем – Кара татарлар. Алар Бөек Далада гомер иткән, үз ханнарына гына буйсынып, иген игү, мал-туар асрау белән шөгыльләнгән. «Үз ирекләрен ефәк чүпрәк бәрабәренә Кытайга саткан кавем», – дип, алар Ак татарларны яратмаган, хәтта күралмаган. Өченчесе – Кыргый татарлар, «урман халыклары» дип аталган Көньяк Себернең аучы-балыкчы кабиләләре. Алар, ханнар хакимиятен белмичә, кабилә юлбашчылары тарафыннан идарә ителгән.

Тимучин – Чыңгыз хан Кара татарлардан булган. Бу хакта «Татар-монголлар турында тулы мәгълүмат» дип аталган Кытай һәм башка урта гасыр документларында ачык әйтелгән.

Аннары үзебезнең Казан университетында XIX гасыр уртасында эшләгән, алдарак күрсәтелгән мәгълүматларны махсус өйрәнгән профессор, академик Василий Павлович Васильев (1818-1900) Чыңгыз ханның татар булуын кире каккысыз дәлилләр белән раслаган. Чөнки ул – махсус рәвештә кытай телен өйрәнеп, аннары байтак еллар Кытайда яшәп, андагы архивларда эшләп, бай мәгълүмат туплап кайткан галим. Шуңа күрә ул В.П.Васильев акка кара белән 1859 елда: «Чыңгыз хан татар булган, чөнки аның милләте барлык хроникаларда татар дип күрсәтелгән», – дип яза. (В.П.Васильев. История и древности восточной части Средней Азии. – Спб., стр.159) Моннан да ачыграк әйтеп буламы? Университет профессоры, академик галимнең катгый раславы җитмиме инде? Җитми икән шул. Чөнки Россиядәге сәяси вазгыять иягендә сакал-мыек түгел, төк тә үсмәгән, ә татар ирләренең (шул исәптән Чыңгыз ханның да) куе сакал-мыек йөртүе бәхәссез.

Заманында Чыңгыз ханны күргән рәссам-сынчылар аны куе сакал-мыеклы, шар кебек түгәрәк ачык күзле итеп сурәтләп калдырганнар. Бу очраклы хәл була аламы? Юк, әлбәттә.

Кыскасы, Чыңгыз хан биографиясенең эзләрен монголлар арасында түгел, ә төркиләр арасында гына эзләргә кирәклеге көн кебек ачык. Шуңа күрә безнең алда бернинди монгол түгел, ә борынгы Һун-татар сугышының атаклы вәкиле, дәүләтләр төзүдә күп гасырлык тәҗрибәсе булган чын төрки шәхес! Ул бит – борынгы каһаннар варисы. Андый кешенең армияләр, дәүләтләр, язма кануннар булдырудагы бай тәҗрибәсе бернинди шик тудырмый.

Кайсы гына яктан килеп карасаң, тикшерсәң дә, Чыңгыз хан: «Мин – татармын!» – дип кычкырып тора. Әйтик, Чыңгыз ханның ул чордагы Иран тарихчысы Рәшидетдин китергән нәсел шәҗәрәсендә бер генә монгол исеме дә юк! Киресенчә, барысы да төрки-татар. Мәсәлән, Тәмай, Киши-Мәргән (ягъни төз атучы кеше), Хәяр-Тумәт (татарлар арасында бүген дә Хәяр, Хәяровлар күп), Хайду, Бай-Санкур, Төмән хан, Бердәм-Баһадир, Есугәй Баһадир (Чыңгыз ханның атасы) һ.б.

Ә монголларга килгәндә, Чыңгыз хан аларны тулысынча буйсындырып, үзенә хезмәт иттергән. Яулап алулар вакытында барлык гаскәри берәмлекләр башында татар полководецы торган. Монголлар сан ягыннан да хәлиткеч роль уйный алмаган. Чөнки 20 татарга туры килгән 1 монгол нишли ала? Әйтик, берничә дистә елдан соң, Чыңгыз ханның оныгы Бату (Батый) хан 1240 елда Көнбатыш Европага поход оештырганда, Бату гаскәрләрендә бер монгол да булмый! (Кайсы элекке сугышларда үлгән, кайсы татарлар арасында «эреп» юкка чыккан!) Бөек вакыйгаларга кагылышы булган кечкенә генә монгол халкы галимнәренең дә үзләрен зур, батыр итеп күрсәтәселәре килүе табигый хәлдер. Шуңа күрә алар үз халкын ышандыру гына түгел, бөтен дөньяга: «Чыңгыз хан монгол булган!» – дип сөрән салалар. Әмма теләк бер, ә тарихи хакыйкать икенче нәрсә шул…

1206 елда 51 яшьлек Тимучин барлык татар һәм монголларның императорыханы итеп сайлана. Шул чорда яшәгән Ли Си Чуань 1227 елда Чыңгыз хан турында: «Ул – төз озын буйлы, киң маңгайлы, озын сакаллы, бик көчле, дәһшәтле шәхес», – дип язып калдырган. Гадәттә, тәбәнәк, карсак буйлы булган, табак битле, кысык күзле, сакал-мыексыз (чөнки үсми) монгол белән чагыштырып карагыз инде баһадир татар полководецын!..

Чыңгыз ханның беренче улы, шулай ук бөек яугир Җүчи оештырган дәүләт башта аның үз исеме белән аталса, соңыннан аның улы Бату Идел Болгарстанын һәм Русьне дә яулап алып кушкач, Алтын Урда империясенә әйләнә.

Шунысы игътибарга лаек: аның өч башкаласы да – Сарай Бату, Сарай Бәркә, Сарай Шык (ягъни Сарайчык) – барысы да төрки-татарча аталган. Алтын Урда ханнарының исемнәре дә татарча (монголча түгел!): Җанибәк, Үзбәк (соңыннан үзбәк халкы нәкъ менә шушы хан исемендә үз дәүләтен төзи һәм милләтен аның исеме белән атый), Туктамыш. Менә шушы хан, Дмитрий Донской Куликово кырыннан Мамай гаскәрләрен куып җибәреп: «Барлык татарларны җиңдек!» – дип мактанып ике ел үткәч, гаскәрләре белән килеп, Мәскәүне пыр туздырып ташлый, татарларның бик дәһшәтле көч булуын мактанчык Дмитрийның исенә төшерә (бу вакытта ул, куркуыннан, Мәскәүне ташлап кача).

Ул чорда татарлар арасында киң таралган Нугай, Бирдебәк, Каһанбәк, Гарәпша һ.б. исемнәрне бүген дә үзбәк, казакъ, кыргыз һ.б. төрки халыкларның балаларына кушулары очраклы түгел.

Әйдәгез, кызык өчен, гадәти монгол исемнәрен карыйк: Журдимидигейн, Гуррахча, Дамдинсурен, Лодойдамба, Цевегемед, Эрдена Сенгийн (монгол язучысы)… Әйе, аларны дөрес әйтү өчен дә телеңне сындыра-сындыра сәгатьләр буе кабатларга кирәк. Ирексездән уйлап куям: гади башкортларның түгел, ә галимнәрнең ничә меңләгән ел бай тарихлары булган татарлар белән ярышкан булып, алардан өскә чыгарга азаплануларын, ә инде украин түрәләренең һәм галимнәренең, урыслардан өстен чыгарга тырышып: «Без бит – Киев Русе варислары, ул чактагы бөтен мәдәниятне саклаучылар, ә бүгенге урыслар исә шуннан таралган – арбадагы бишенче тәгәрмәч кенә», – дип мактануларын, фактта исә үзләренең олы урыс туганнарыннан көлүләрен күреп-ишетеп торабыз. Әйе-әйе, һәр халыктагы

түрә һәм галимнәрнең үзләрен дөньяның кендеге итеп күрсәтергә тырышулары табигый хәлдер. Әнә, күршемдәге бик бай чуаш эшмәкәре дә татарчалап (ярыйсы ук яхшы белә): «Пес, чуашлар, Идел буе пылхарларының варисы пит», – дип куйды бервакыт. Мин аңа каршы: «Ничек алай була ала инде, Николай Николаевич? Син генә түгел, галимнәрегез дә (үзләрен әллә кем итеп күрсәтергә тырышып), ул данлы-шанлы халыкның хәтта исемен дә дөрес әйтә алмыйсыз бит (пылхар, имеш). Аннары 1100 ел элек бу шанлы халык ислам динен рәсми дин буларак кабул иткәндә сез нишләп соң бүгенгә чаклы чукынучылар динендә, исемнәрегез дә болгар-татарча түгел?» – дигәч, берни җавап бирә алмады. Чөнки ул, тарихны белмәгән килеш, үзләренең галимнәре һәм түрәләренең сүзләрен тутый кош кебек кабатлап йөрүдән узмый.

Әйе, лирик чигенүләр дә тиешле урында бик кирәк. Наданнарның сүзен җөпләп утырмаска, аларның үзләрен тиешле урыннарына утырту лязем...

Ул чордагы татар-монгол империясенең башкаласы исеме дә татарча – Кара Корым булган бит. Кыскасы, һәрнәрсәдә – дәүләт, гаскәр, шәһәрләр төзү, кануннар булдыру һәм хәтта дипломатиядә дә монголларның эзе дә, тәэсире дә юк.

Бу вазгыятьтән чыгып, төрки-татар һәм монгол халыкларының санына игътибар итеп карыйк. Үзбәк, казакъ, татар, башкорт, төрек, азәрбайҗан, төрекмән, нугай, кумык, гагауз, чуаш, уйгыр, кыргыз, тувалы, шорлы, балкар, карачай, караим, хакас, якут һ.б. Барысы 160 миллионнан артык кеше. Ә монгол телле (монгол, бурят, калмык) халыклар саны 15 миллионга да тулмый. Шуңа күрә татарлар оештырган империя-дәүләтләрнең нинди милләт кешеләре ресурсларыннан оешуы һәм ничәмә гасырлар яшәве ачык аңлашыла. Тарихи хәлне коры сүз түгел, әнә шундый конкрет дәлилләр, фактлар раслый.

Шулай да тарихны сәяси максатларда файдалануның бер «рычагы» дип саналган И.В.Сталин дәүләтнең куркыныч боҗра-кыршау эчендә, капиталистик чолганышта яшәвен һәм СССРның ул чордагы бердәнбер «дусты» Монголия Халык Республикасына һәрьяктан булышырга кирәклеген истә тотып, үзе яхшы белгән хакыйкатькә күз йомып, монгол түрәләре һәм галимнәренең Чыңгыз ханны үзләренеке дип санау турындагы «тәгълимат»ны яклап чыга һәм илдәге барлык фәнни оешмаларга шундый күрсәтмә бирә. Шул рәвештә мәктәпләрдә, югары уку йортларында әнә шушы ялган мәгълүмат таратылуның тәэсире бүгенгәчә дәвам итә...

***P.S.*** Мин дә, тарихчы академик Миркасыйм Госманов белән университетта бер группада белем алдым, шул ук тарихчы профессорларны тыңладым. Шуңа күрә хәтер сандыгымда нихәтле тарихи мәгълүматлар ята, дип, кулыма каләм алырга һәм данлы-шанлы үткәнебез турында фикер йөртергә яратам.

*Октябрь, 2021 ел*

**Редакциядән:** Даими авторыбыз, милләтпәрвәр шәхес, танылган журналист Фарук Нәфиев гомере буе халкыбыз язмышын кайгыртып яшәде. Бу аның редакциябезгә килеп ирешкән соңгы язмасы булды. Мәрхүмнең рухы шат, урыны җәннәт түрендә булса иде. ■

# «Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – язучылар, галимнәр, журналистлар, дин һәм сәнгать әһелләре февраль аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

**1 февраль** – гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы, батик остасы, 1997 елдан – ТР Рәссамнар берлеге, 2003 елдан РФ Рәссамнар берлеге әгъзасы, Яшел Үзән шәһәре тумасы **Дилә Рәшит кызы Галиуллина-Барышева**га 60 яшь (1962);

**2 февраль** – актер, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1983), Полтава (Украина) шәһәре тумасы **Сәлим (Александр) Григорий улы Мифтахов**ка 75 яшь (1947);

**3 февраль** – хор дирижеры, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1987), Казан шәһәре тумасы **Ирнис Әхмәдулла улы Рәхимуллин**га 80 яшь (1942);

**8 февраль** – театр белгече, ТАССРның (1983) һәм РФнең атказанган сәнгать эшлеклесе (2000), «Тантана» премиясе лауреаты (2020), Екатеринбург шәһәре тумасы **Ильтани Исхак кызы Илялова**га 90 яшь (1932);

**12 февраль** – тарихчы, сәясәтче, публицист, философия фәннәре кандидаты, тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, ТРның атказанган фән эшлеклесе, ТРның дәүләт премиясе лауреаты, 2007 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы, Казан шәһәре тумасы **Рафаил Сибгат улы Хәкимов**ка 75 яшь (1947);

**17 февраль** – баянчы, музыка белгече, педагог, ТАССРның (1983) һәм РФнең атказанган сәнгать эшлеклесе (1998), Әгерҗе шәһәре тумасы **Рәгъде Әбелфатыйх улы Халитов**ка 80 яшь (1942);

**18 февраль** – язучы, ТАССРның (1989) һәм РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре (2005), Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе (1999), 1972 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның Сарман районындагы Алангазар авылы тумасы **Рәфкать Кәрами**гә (Рәфкать Кәраметдин улы Кәрамиевкә) 80 яшь (1942);

**28 февраль** – журналист, шагыйрь, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (2002), 2007 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның Спас районындагы Иске Рәҗәп авылы тумасы **Камил Шәмгун улы Сәгъдәтшин**га 70 яшь (1952).

**Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз!** ■

# Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов



Пекин базары. 1910 ел

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

# Кытай иленең төбәкләре

Кытай иленең бөтен җирен гизү-күрү һәм өйрәнү өчен гомернең шактый елын һәм йөз меңнәрчә сум акча сарыф итәргә, әгәр язарга уйласаң, әллә ничә китап язарга кирәк булыр иде. Ул дәрәҗәдәге олы вазыйфалар, әлбәттә ки, минем көчем җитәрлек түгел. Шул сәбәпле, мин туплаган мәгълүмат бик аз, бары тик үземнең көчем җиткән кадәрле генә булачак. Кытайның төрле төбәкләрендә яшәүче мөселманнарның күпчелек өлеше хакында мин җиткерәчәк хәбәрләр, барыбер дөреслектән әллә ни ерак булмас дип уйлыйм. Мин Кытай мөселманнары турында язган кайбер Аурупалы язучыларның хезмәтләрен укыдым. Дубровицкий (?), Ладыгин, Потанин кебек Шәрык дуслары булган кешеләрнең дә үз әсәрләрендә язганнарын монда күргәннәрем белән туры килә дип әйтә алмыйм. Боларның күбесе Коб-Норкның (Көб Нур) көньягында һәм көнчыгышында төркиләрнең эзләрен таба алмаганнар, ләкин андагы җир һәм су атамаларының күбесе төркичә: Кызыл, Корук-даг, Ошакдал, Шуртуз, Шурбулак, Туксин һәм башка сүзләр һәммәсе дә төрки телдән. Төрле җирләрнең һәм елгаларның мондый исемнәр белән аталып йөртелүе, һичшиксез, биредә борынгы чорларда төркиләр яшәгәнлеккә дәлил булып тора.

Ул җирләрдә яшәгән халык теленең монгол теле һәм күпчелекнең мәҗүси булуы – уйланылырга тиешле җәһәт. Шулай булса да, бу да төркилеккә каршы төшә алырлык күренеш түгел дип уйлыйм. Вакытлар үтү белән, тел югалырга мөмкин һәм югалган очраклар да бик күп. Мәсәлән, бүгенге Литва татарларында татар теленнән бер генә сүз дә калмаган булуы – үз күз алдыбызда. Кытайның көньягында, Хан-Кан һәм аның әйләнә-тирәсендә, димәк, төркиләр яшәгән. Аларның хәтта Маньчжуриянең көнбатышында да яшәгән булулары ихтимал. Хан-Кан һәм аңа якын җирләрдә Узун Булак, Хотак атамалы җирләр бар, моннан тыш, Дал Булак, Кызыл атамалы елгалар да очрый. Бу исемнәр, һичшиксез, төрки телдән калган эзләр. Тагын шуны да истә тотарга кирәк: Аурупа карталарында күп кенә атамалар бозып язылганнар. Йонансидән Шанхайга таба ага торган елганы кытайлар Йанҗийан дип йөртәләр. Килеп чыгышы буенча, Йанҗи Ангы – «уңнан сулга» дигәнне аңлата, имеш. Үзәктән караганда, уң яктан сул якка таба акканга шулай аталган да, соңрак Йанҗийан булып киткән. Бу елгадан түбәндәрәк мәшһүр Нан-Кин шәһәре бар. Нан сүзе фарсы телендә «икмәк» дигән сүз, кин – төрки телдә «каршылык, каршы тору» мәгънәсендә. Сәбәбе нинди булгандыр, менә шундый исем бирелгән. Нан-Кин шәһәренең төньягында кечерәк кенә елга бар, аны хәзерге көндә дә Аксу дип йөртәләр. Моннан тыш, Карбан Ангар күле дә бар. Менә шундый билгеләр, эзләр бик күп. Болар бар да бу җирләрдә кайчандыр төркиләрнең яшәгәнлегенә дәлил булып тора.

Монголиянең көньягында Синин шәһәрчегеннән көньякка таба җәелеп киткән Иле өлкәсе, көнчыгышындагы Кансу һәм Шансы өлкәләре, Саларйе, Йонанси, Сиҗиванарга кадәр бөтен җирләр – төркиләрнең җире, монда яшәүчеләрнең күпчелек өлеше саф төрки телдә сөйләшә.

Бигрәк тә Байан Җонги, Сонхи тирәләрендә гел төркиләр яши. Тормыш-көнкүреш рәвешләре дә гел төркиләрчә: бакырчылык һәм тимерчелек белән шөгыльләнәләр, мылтык һәм башка төрле кораллар ясау да боларның борынгы сәнәгать төрләреннән икән. Ланҗо, Гаҗо һәм Соҗо дигән җирләр – бик бай өлкәләр, биредә Япониядән, Англиядән, Германиядән китерелгән чит ил тауарлары да күпләп сатыла. Русиядән килгән тауарлар да бар, ләкин чагыштырмача бик аз.

Бу җирләр Кытайның урта төбәкләре булып санала һәм аның иң төзек өлкәләрен тәшкил итә. Комдәрья ягындагы Чагрин, Йарлин һәм Титон тирәләрендә җир астында бик күп алтын булуы да мөмкин икән. 1899 елда кайбер кешеләр алтын эзләп караганнар. Өч ай эчендә, кәйлә белән генә казып та, 26 кг алтын җыйганнар. Болар гади халык арасыннан чыккан кешеләр икән, бары тик саф алтын гына таба алганнар һәм 6 кг авырлыктагы бер кисәк алтын рудасы да тапканнар. Аннары хөкүмәт тыйган, алтын эзләргә рөхсәт итмәгән.

Кытай иленең төрле төбәкләрендә борынгырак чорларда төрки кавемнәр яшәгән булырга тиеш. Күп кенә тауларның, тигезлекләрнең, чүлләрнең, елгаларның атамалары төркичә. Хайдык Күл, Кыйук Йоллук Күл, Тургавыт, Аучы Алгы дигән күлләр, елгалар; Кече Йолдыз, Таш Кайын һәм Ком таулары, Комдәрья, Ачык Болдык кебек җир атамалары бик күп.

Боларның кайберләре, хәтта Көб Нурның көньягында урнашкан җирләрдә дә очрый. Биредә, төрки телдә сөйләшүче кавемнәр бөтенләй булмаса да, атамасы төркичә булган җирләр күп: Биш Булак, Бурата, Алынмыш Булак, Конҗы Дәрья, Төрли (бу җирне хәзер инде Синҗин дип тә атыйлар), Җийули Күл, Илак Сой, Лачин, Алтынтау, Җаскантау (Җаскандау) кебек атамалар – барысы да төркичә. Боларның кайберләре Тибетка карый. Тангут дигән җирдә дә мондый төрки атамалар очрый: Какты Күл, Сарысу, Җангурлу.

Моннан тыш, көньяк Көб Нурда *түленг*[1] кавеме бар. Шундый ук түленгетләр безнең Себердә, Тубыл һәм Томск өлкәләрендә дә яши. Әмма безнең Себердәгеләрнең күбесе мөселман, Тангуттагылар исә буддачылар.

Мин болар турында бик күп эзләнергә, тикшеренергә теләгән идем. Тик, ни кызганыч, 436 нчы биттә[2] язып киткән тәкъдимнәр биредә киң һәм тирән эзләнүләр алып баруыма мөмкинлек калдырмый иде. Шул сәбәпле, мондагы хәлләр турында кытайларның үзләреннән ишеткәннәремне язу белән генә чикләнәчәкмен.

Мин бик күп йөри дә алмадым, күп вакытымны Пекинда һәм аның әйләнә-тирәсендә үткәрдем. Шулай булса да, бу мәмләкәтне гизеп, турыдан-туры кәгазьгә төшереп, кытайлар турында шактый мәгълүмат туплаган кеше мөселманнар арасыннан янә дә мин булачакмын. Әйе, «Кытайны аркылыга-буйга гизеп чыктым» диюче Аурупалы кешеләр дә юк түгел. Болай дисәләр дә, хөрмәтле укучыларыма шуны әйтергә телим: «Кытай иле – алай бик җиңел генә аркылыга-буйга гизә торган мәмләкәт түгел».

Мин – Русия кешесе, Русия эчендә дә бик күп сәяхәт иттем. Минем кадәр Русияне белүче бик аз, дип тә әйтә алам. Тик шулай да Русиядә әле мин күрмәгән шәһәрләр, мин белмәгән милләтләр күп. 140 миллион кеше яши торган Русиядә туып-үстем, әллә ничә ел сәяхәт иттем. Инде килеп, 400 миллион кеше яши торган Кытайда берничә ай яки бер-ике ел яшәп, күпме мәгълүмат тупларга мөмкин?!

Менә шундый уйлар белән, хөрмәтле укучыларым, сезгә: «Күпме генә сәяхәт итсәм дә, Кытай турында мин бирә алачак мәгълүмат барыбер бик чикле була-

[1] Төрки телләр тарихына багышланган хезмәтләрдә, *теленгит һәм телеутлар* (аз санлы төрки халыклар) борынгы *теле* кабиләсеннән килеп чыкканнар, дигән фикер әйтелә. Теленгитлар, аерым төркемнәр хәлендә, Монголиядә һәм Кытайда да яшиләр, дип белдерелә. Бүгенге көндә Русия җирләрендә – Алтайда һәм Себердә яшәүче бу төрки халыклар алтай халкының этник төркемнәре итеп тә күрсәтелә. Алар үзләрен *теленет, теленнет* яки *теленут* дип йөртәләр. Биредәге -ет, -ут кушымчасы, галимнәр фикеренчә, монгол телендә күплек санны белдерә *(тәрҗ.иск.)*.

[2] Бу бит саны әсәрнең госманлы-төрек телендә Истанбулда басылган беренче басмасына карый *(тәрҗ.иск.)*.

Пекин. 1910 ел

чак», – дип әйтәм. Ләкин барыбер тагын бер тапкыр кабатлыйм: иң беренче булып Кытай илен гизгән һәм калебләрне берләштерүгә хезмәт итәчәк мәгълүматлар туплаган беренче мөселман кешесе булу миңа насыйп булды.

Киләчәктә безнең яшьләребез, һичшиксез, Кытай илен аркылыга-буйга гизәрләр, киң мәгълүматлы, әһәмиятле хезмәтләр язып бастырырлар. Шулвакыт безнең хезмәтләребез, әлбәттә, китапханә киштәләрендә иске китаплар киштәсенә күчәр. Әмма бүгенге көндә, минем әсәрем – иң беренчесе, иң яңасы. Әйе, миннән алдарак, хәтта бик күптән, моннан 595 ел элек, һиҗри 734 нче елда, бу җирләрдә Ибн Батута сәяхәт иткән, дип әйтергә мөмкин. Кывамуддин әс-Сәбтинең дә әлеге мәмләкәтне гизүе турында риваятьләр бар. Ибне Батутаның сәяхәте мәгълүматлы булган, шактый җирне үз эченә алган. Әлбәттә, алты гасыр элек булган сәяхәт, хәтта кечкенә генә булган булса да, безнең бүгенге сәяхәтебез янында гаять зур булып күренер иде. Шуңа күрә биредә бу мөхтәрәм затның сәяхәте турында да бераз әйтеп китәсем килә.

Ибн Батута (Аллаһының рәхмәтендә булсын) Һиндстаннан Кытайга килә. Башта Җава утравына туктый, Суматрадан Тавалискә китә. Инде ул җирләрдә бу шәһәр юк. «Кешеләре төрки йөзле, ханнары Кытай ханы», – диюенә күрә, Тонкин-фәлән булуы ихтимал. Чөнки: «*Вә ләһум шәҗ’атун вә нәҗдәтун хисану’с-сувәр вә йа’будунә’л-әвсан вә ниса’иһим йәркәбнә’л-хийәл вә йухассину’р-рәмайә вә йукатилнә кә’р-риҗал* [Анда кыю-батыр йөрәкле, күркәм йөзле, потларга табынучы кешеләр яши. Хатын-кызлары да атка атланып йөри, оста ук ата һәм ир-атлары кебек үк сугышка керә]», – ди.

Аннары ул җирләрдән Килугәри портына китә (бүгене көндә бу порт та билгеле түгел). Әлеге җирләрнең мәликәсе Ибне Батутаны үзенең хозурына чакырта. Сәламнән соң: *«Һысәнмисән, йахшимисән, хошмисән, йахшымисән?»* – ди. Бу сүзләр – бүгенге көндә Русиядә яшәгән татарларның теле. Тик бездә баштагы сүз *һысән* рәвешендә түгел, ә *исән* рәвешендә әйтелә, ягъни: *«Исәнмесин?»* – дигән, шулай дип уйлыйм.

Шуннан соң мәликә хезмәтчесенең язу карасы белән каләм китерүен тели: «Дивит вә мүрәккәп китер!» – ди. Хезмәтче китереп биргәннән соң, Мәликә бисмилла-и шәрифә язып күрсәтә һәм: «Нам-ы Таңдыр», – ди. Ихтимал ки, Таңры/Тәңредер.

Ибн Батута ул җирләрне гел «Тавалиси бәлдәләре (шәһәрләре)» дип атый. Аннан соң Кытайга кадәр һавалар бик яхшы тора, ул 17 көндә Кытай мәмләкәтенә килеп җитә. Килүгә, Аб-ы Хәят (Әбү Хәйәт? – *Ред.*) дип атала торган елганың диңгезгә коя торган урынына туры килә. Бу елгага «Себер елгасы» диләр икән һәм ул алты

айда барып җитәрлек ераклыкта урнашкан Хан Балык[3] дигән шәһәр янындагы таулардан башлана, ди.

Аннары: «Кытайларның падишаһы – Чыңгыз хан нәселеннән, татар. Кытайда бөтен шәһәрләрдә дә мөселманнар бар, мәчетләр бар», – ди. Ибне Батутаның Кытай илендә беренче килгән һәм күргән каласы – Зәйтун шәһәре. (Хәзерге көндә андый шәһәр инде юк. Тасвирлауларына караганда, бүгенге атаклы Шанхай шәһәре булырга тиеш.) «Шәһәр портында йөзләрчә кораб бар. Бу – дөньяның иң зур портларының берсе», – дип тә өсти.

Аллаһының рәхмәтендә булсын, мөселман казыйлардан Таҗеддин әл-Әрдәвили, Шәйхү'л-Ислам Җәлаледдин әл-Исфаһани, Таһир Шәрафүддин әт-Тәбризи белән күрешә.

Шуннан соң, Сину'с-Син дигән җиргә юлга чыга. Аны Син-Кәлан (Кантон) да диләр икән. Кытайның һәр шәһәрендә мөселманнар белән җитәкчелек итүче Шәйхү'л-Ислам һәм казыйлар бар икән.

Ибне Батута, ниһаять, шул җиргә барып җитә. Аннан соң инде бер генә шәһәр дә юк. Йә'җүҗ вә Мә'җүҗ сәдде[4] белән араларында 60 көнлек юл кала.

Аллаһының рәхмәтендә булсын, ул 28 көн елга буйлап сәяхәт иткән. Синкәлан каласына кадәр (инде мондый шәһәр дә юк, Сичуан бар). Биредәге Бәйум Кутлу һәм Канҗинфу шәһәрләрендә булуын да белдереп үтә. Аннары, Ханса шәһәрен күз алдында тотып: «Җир йөзендә мин күргән мәдәнилекнең иң бөеге бу», – ди. Монда Госман бин Гаффан токымыннан булган әл-Мысри гаиләсенең өендә кунак була. Ул вакытта анда бик күп санда мәчет һәм голәмә булган. Шәйхү'л-Ислам исә Әфһаруддин исемле кеше икән. Биредә Госманлы төрекчәсендә сөйләшүче кешеләр булган, 15 көн шунда яшәп калган. Бу җирнең – тасвирлавы буенча – хәзерге Нанкин шәһәре булуы ихтимал. Әлеге җирләрдә *ата, той,* ягъни туй сүзләре кулланыла икән. Болар – төрки сүзләр. Соңыннан ул Каракурум, Биш Балык дигән җирләргә бара. Бу атамалар да төркичә. Ясак дигән сүз әле дә кулланыла. Ибн Батутаның (Аллаһының рәхмәтендә булсын) «Сәяхәтнамә»сеннән менә шулкадәр мәгълүмат китереп үтәм. Аллаһы үзенә киң рәхмәтләрен әйләсен, бик зур хезмәт куйган, ул вакытлар өчен мондый хезмәт могҗиза булып санала ала дисәк тә, урынлы булыр. Минем бу сәяхәтнамәгә мөрәҗәгать итүемнең төп максаты – Ибн Батута заманында – эчтәлектән аңлашылганча – бу илнең һәр тарафында, хәтта көнчыгыш Кытайда да, төрки кавемнәрнең һәм күп санда голәмәнең булуын күрсәтү. Ул заманнарда биредә голәмәдән Ширази, Исфаһани, Мысри һәм Мәгърибиләр булган.

Хәзер исә, биредә ул кешеләрнең эзе дә юк. Ясак сүзеннән башка, төркичә бер сүз дә ишетмәссең. Әлбәттә, ул төркиләр әле дә бу җирләрдәдер, ләкин инде кытайлашканнардыр. Катышып-кушылып беткән булулары бик мөмкин. Җаһиллекнең дә ярдәме зур булган, билгеле, эзләре дә калмаган. Булмастай хәлләр түгел бу.

Бүген Русиядә саф рус булып саналучы Максудов, Мансуров, Кашаев, Янгаличев һәм башка шактый санда гаилә бар. Алар моннан 300 –бәлки, аннан да артыктыр – ел элек христианлашканнар һәм руслашканнар. Бүген инде ата-бабаларының татар булганлыгын белмәүче меңнәрчә гаилә бар.

---

[3] Бүгенге көндә бу – мәшһүр Ханко елгасы. Бу елга тагын да югарыдан, Тибет тауларыннан башланып китә. Инде шәһәрнең дә исеме Хан Балык түгел, Йанхийан булган *(Габдерәшит Ибраһимов иск.)*.

[4] Йә'җүҗ вә Мә'җүҗ сәдде дигәндә, Кытай диварын күз алдында тоткан булса кирәк *(тәрҗ. иск.)*.

Кытайда да нәкъ шул рәвешле югалган төрки кавемнәр күп булгандыр. Хәзерге вакытта бары тик төрки телдә сөйләшүчеләре генә төрки булып санала ала.

Ибн Батутаның язмаларыннан да аңлашылганча, ул заманнарда Кытай мөселманнары арасында голәмә, казыйлар һәм ислам шәехләре күп булган. Инде бу исемнәрнең берсе генә дә калмаган, бары тик ахун гына сакланган.

Бүгенге көндә Кытайда ислам белән бәйле кытай телендә язылган бик күп китап бар. Әлбәттә, боларны тәрҗемә иткән кешеләр гарәп телен мөкәммәл дәрәҗәдә белгәннәр. Шулай булмаса, ул кадәр китапны тәрҗемә итә алмаслар иде.

Хәзер исә, ике-өч төбәкне санамаганда, хәтта бөтен Кытайда да, ул кадәр гарәпчә белгән кеше табыла алмас. Бигрәк тә көньяк-көнчыгышта берәү дә юк. Тышкы килеш-кыяфәте белән дә голәмә исеменә лаек булырлык кеше очрата алмассың. Голәмә һәм ахун исемен йөртүче кешеләр юк та юк, голәмә дип түгел, безнең Русия мөселманнары яки башка мәмләкәт мөселманнары белән чагыштырганда, шәкерт дип атарга мөмкин булган кешене берничә төбәктә берне очратсаң да, күңелгә юаныч була.

Пекин, Тензин, Шанхай, Ханко, Кантон, Хонкага кадәр бөтен көньяк-көнчыгышта дисеңме, Маньчжуриядә дисеңме – һәр җирдә исламият кычкырып еларлык дәрәҗәдә. Болай дәвам итсә, 15-20 елдан соң миссионерларның, зур көч куеп, ул мөселманнарны христианлаштырачаклары көн кебек ачык.

## Кытайда миссионерлар

Кытайның һәр тарафында миссионерлар бар. Тауларда, елгаларда, калкулыкларда – һәр җирдә бар алар. Кайда берәр бушлык күрсәләр, шунда оялаганнар. Боларның Кытайдагы кадәр монастырьлары дөньяның бер генә җирендә дә юктыр. Бигрәк тә Сичуан, Йонанси төбәкләрендә, 3-5 километрда һичьюгы кырмыска оясы кадәр генә булса да бер җирләре очрамый калмый. Аларның бу төбәктә күп булуының сәбәбе – Тибетны, ничек кенә булса да, исламият йогынтысыннан саклап калырга теләүләре. Чөнки әлеге җирләр – Тибетның капкасы. Анда килеп-китеп йөрүче мөселманнарга, булдыра алган кадәр комачау итүләре, гайрәтле берәр шәхес күрсәләр, җанын кыюдан да тартынып тормаулары турында мәшһүр сәяхәтче Ладыгин җәнапларыннан ишеткәнем булды. Бу юлы әлеге ишетеп белгәннәремне дәлилләрлек вакыйгаларның шаһите дә булдым. Әлеге кемсәләрнең, гомумән, дөньяның кай төшендә генә булсалар да, уйлары гел исламияткә каршы юнәлдерелгән була.

Нәтиҗәдә, боларның Кытайда корган оялары нәкъ тә үрмәкүч пәрәвезе кебек булып чыга. Көннәрнең берендә кытайлар бу пәрәвезләрне себерке белән бер селтәнүдә юк итәчәкләр. Һичшиксез, инсан каны елга кебек агачак, ләкин барыбер себереп түгәчәкләр. Моның нәтиҗәсе башка төрле була алмас. Бу миссионерлар, дөресе белән барганда, дин җәелдерүчеләр дә түгел, алар христианлыкка да хезмәт итмиләр, ул исем астында фетнә орлыклары гына чәчәләр. Тагын да ачыграк итеп әйтсәк, боларның бөтен тырышлыгы тәре сугышы өчен мәйдан хәзерләүдән гыйбарәт булып кала.

XX гасырның мәдәнияте дә моңа ярдәм итә. Ник дисәгез, дөньяда күпчелекнең мәгърифәте, сәясәте, дипломатлыгы шул болганчык суда балык тотудан гыйбарәт. Башка төрле итеп әйткәндә, дөньяда берничә кеше яшәсен өчен миллионнарча кеше ахмакка чыгарыла.

*Төрекчәдән* ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

# Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре*

Әхмәдвәли Рәхими

13

Әбү һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Ислам гарип хәлдә, ягъни аз юлдашлы булып ачылды. Яңадан, ачылганы кебек, гариб булып кайтыр. Ни сөенеч ул гарибләргә, ягъни исламда сабит (нык) торучыларга гариб (зәгыйфь) заманда».

**Укы һәм исеңдә калдыр!**

14

Габдулла бине Гомәр разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Бөек Ислам груһына (өммәтенә) иярегез. Кем алардан аерылса, утка да аерылган булыр».

**Укы һәм исеңдә калдыр!**

15

Әбү һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Кеше вафат булганнан соң барлык гамәлләреннән өзелә, ләкин аның өч төрле гамәле файда китерәчәк: 1) сәдакаи-җәрия, ягъни кеше үлгәннән соң да файда китерә торган сәдака; 2) башкаларга биреп калдырылган белем; 3) балаларының догалары».

**Укы һәм исеңдә калдыр!**

16

Ибн Габбас разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Шайтанга диндә галим булган бер адәм мең надан гыйбадәт кылучыдан катырак».

**Укы һәм исеңдә калдыр!**

17

Әбү һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Монафыйкта ике сыйфат җыелмас: күркәм холык һәм дини гыйлем».

**Укы һәм исеңдә калдыр!**

18

Әбү Сәгыйд әл-Худри разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Мөэмин кеше Җәннәткә ирешкәнчегә кадәр хәерле гамәлләр кылудан туймас».

---

Дәвамы. Башы журналның 12 нче (2021) санында.

*Хәдисләр Шәех әл-Камил Вәли әд-Динмөхәммәд бине Габделхатыйб әт-Тәбризинең «Мишкәтүль мәсабих» китабы буенча әзерләнгән һәм 1913 елда 3 китапта басылып чыккан.

*Текстны басмага* ***Айсылу Вәлиева*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2022

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

# Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

## Сигезенче дәрес

### Адәм вә Хәваның яралтылуы. Аларның Җәннәттә торулары. Иблиснең аларны котыртуы. Адәм белән Хәваның Җәннәттән чыгулары. Иблиснең Адәм балаларына дошман булуының сәбәпләре.

**Мөгаллим:** Йә, Шакир, әйт әле: элек бу дөнья булганмы-юкмы?
**Шәкерт:** Юк, булмаган.
**Мөгаллим:** Элек кем генә булган соң?
**Шәкерт:** Аллаһы Тәгалә генә булган.
**Мөгаллим:** Аллаһы Тәгалә дөньяны нәрсәдән яралткан?
**Шәкерт:** Юктан бар кылган.
**Мөгаллим:** Иң элек Аллаһы Тәгалә кемнәрне яралткан?
**Шәкерт:** Фәрештәләрне яралткан.
**Мөгаллим:** Дөрес. Фәрештәләрне яралткан шул. Аллаһы Тәгалә фәрештәләрне, безгә күренгән дөньяны яралтмас борын ук яралткан. Аннан соң дөньяны, ягъни күкләрне, җирләрне яралткан. Җирне менә без күргән хәлгә китергән. Аны үләннәр, агачлар, таулар, чишмәләр, күлләр, елгалар, диңгезләр белән зиннәтләгән. Аннан соң Адәм исемендә бер кеше яралткан. Беләсезме, Аллаһы Тәгалә Адәмне нәрсәдән яралткан?
**Шәкерт:** Нәрсәдән?
**Мөгаллим:** Аллаһы Тәгалә Адәмне балчыктан яралткан. Әнә шул балчыктан яралтылган кеше безнең иң әүвәлге атабыз була. Аның исеме – Адәм. Шуның өчен дә безгә, Адәм балалары, диләр. Аллаһы Тәгалә Адәмне яралткач, аны Җәннәткә урнаштырган. Ул шунда бик тыныч, бик рәхәт кенә торган булган. Аннан соң аңа бер хатын яралткан. Аңа Хәва диләр. Синең боларны ишеткәнең бар идеме моңарчы?
**Шәкерт:** Бар иде, әнкәй миңа аны сөйләгән иде.
**Мөгаллим:** Ишеткән булсаң, бик яхшы. Әнә шул Адәм белән Хәва – безнең иң әүвәлге ата-аналарыбыздыр. Без шуның өчен дә аларны атабыз Адәм, анабыз Хәва дибез. Без бөтенебез шулардан таралганбыз. Атабыз Адәм белән анабыз Хәва Җәннәттә торганнар, дигән идек. Аларга анда бик рәхәт булган. Аларга кирәк барысы да булган: төрле җимешләр дисеңме, татлы сулар дисеңме… Аллаһы Тәгалә аларга шунда булган бар нәрсәдән дә файдаланырга рөхсәт биргән. Теләгән җимешен генә ашарга аларга ирек куйган. Тик аларга бер агачның җимешен генә ашарга рөхсәт

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

бирмәгән. Ул агачтан ашасалар, үзләренә авырлык киләчәген аңлаткан. Алар озак вакытлар шулай Аллаһы Тәгалә рөхсәт биргән нигъмәтләрдән файдаланып, әлеге агачның җимешен ашаудан тыелып торганнар. Бервакыт Иблис килеп, боларны котырта башлаган. Аларга Аллаһы Тәгалә тыйган әлеге агачтан ашарга киңәш биргән: «Ул – мәңгелек агачы, шул агачның җимешен ашасагыз, сез Җәннәттә мәңгелеккә калачаксыз. Сезгә бетмәс-төкәнмәс нигъмәтләр булачак. Мин сезгә яхшылык телим. Моны сезнең үз файдагыз өчен әйтәм», – дигән. Атабыз Адәм белән анабыз Хәваның күңелләре гел яхшылыкта, үзләре яхшы кешеләр булганлыктан, бу да яхшылыкка әйткәндер дип уйлаганнар һәм Аллаһы Тәгаләнең теге агачның җимешен ашаудан тыйганын да онытып җибәргәннәр. Җәннәттә мәңге каласылары килеп, әлеге агачның җимешен ашаганнар. Иблиснең бу эше тегеләрне тозакка төшерү өчен генә булган. Ул атабыз Адәм белән анабыз Хәваны, бу агачның җимешен ашатып, Җәннәттән чыгарырга тырышкан. Сез Иблиснең ни сәбәпле Адәм белән Хәвага, дошман булганлыгын беләсезме әле?

**Шәкертләр:** Ни сәбәпле дошман булган?

**Мөгаллим:** Белмисез шул. Менә мин сезгә аны сөйлим әле. Аллаһы Тәгалә фәрештәләрне Адәмне яралтмас борын, хәтта безгә күренгән дөньяны яралтканчы ук яралткан. Аннан соң Адәмне яралткан, дигән идек. Атабыз Адәм яралтылгач, Аллаһы Тәгалә бөтен фәрештәләргә аңа баш иярга – сәҗдә кылырга кушкан. Бөтен фәрештәләр, шул җөмләдән Җәбраил кебек олуг фәрештәләр дә, «ләм-мим» дими, Аллаһы Тәгаләнең әмерен карусыз үтәгәннәр, шунда ук баш игәннәр. Шулвакыт Иблис Адәмгә баш июдән тартынган. Аның, үзенең олуглыгына сыя алмыйча, Адәмгә баш иясе килмәгән, тәкәбберлек кылган. Шулай итеп ул, Аллаһы Тәгаләнең боерыгына карышып, гаять зур гөнаһ эшләгән. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә аны үзенең хозурыннан, ягъни Җәннәттән сөргән. Иблиснең бөтен эше Кыямәт көненә кадәр халыкны котырту-аздыру, яман юлга салудан гына гыйбарәт. Ул үзе дә, аңа ияргән башка шайтаннар да гел котыртырга-аздырырга гына тырышалар. Менә Иблиснең безгә вә атабыз Адәмгә дошман булуы ни сәбәпле икәнен белдегез инде.

**Шәкерт:** Белдек, хәлфә, белдек.

**Мөгаллим:** Иблис үзенең дошманы булган атабыз Адәм белән анабыз Хәваның алай рәхәттә торуларын күралмаган. Аларның андый тормышларыннан көнләшкән һәм үзенең хәйлә вә мәкере белән аларны Җәннәттән чыгарткан. Аллаһы Тәгалә Адәм белән Хәваның болай үзенең сүзенә каршы килгәнлекләре өчен аларны Җәннәттән куган. Шулай итеп, Адәм белән Хәва, Иблиснең котыртуы буенча, онытылып, гөнаһ кылып ташлаганнар. Шул сәбәпле алар рәхәт тормыштан чыгып, дөньяда михнәт вә мәшәкать күреп мәгыйшәт итәргә мәҗбүр булганнар.

*Текстны басмага **Мәдинә Әбделганиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2022

# Сәрвәретдин хәзрәт мирасын барлыйк!

Ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсәдә, «Безнең мирас» журналы редакциясе белән берлектә, Сәрвәретдин Сабитовка багышланган «Шәхес, иҗат, заман» исемле «түгәрәк өстәл» узды. Чарада сүз галимнең шәхесен өйрәнү, иҗатын хәзерге заман укучыларына җиткерү хакында барды.

**Мәдрәсә шәкертләре Сәрвәретдин хәзрәт рухына дога кыла**

**Шагыйрь Ләбиб Лерон**

**Академик Энгель Таһиров**

Ильяс хәзрәт Җиһаншин
һәм Җәлил хәзрәт Фазлыев

Шагыйрь Разил Вәлиев

## Сәрвәретдин Мифтахетдин улы Сабитов

**(1870-1916 елдан соң) – дин эшлеклесе, имам-хатиб һәм мөдәррис, Ризаэддин Фәхреддин чыгарган «Шура» журналында актив язышкан мәгърифәтче. Галим «Вәзаифе инсания» («Кешенең вазыйфалары»), «Коръән газыйм», «Әдәбе тәзәввуҗ» («Өйләнешү әдәбе»), «Ислам, тәрәкъкый, ислах» һ.б. китаплар авторы. ■**

Сәрвәретдин Сабитовка багышланган «түгәрәк өстәл»дә катнашучылар

Сәрвәретдин бине Мифтахетдин

# Ислам, тәрәккъый, ислах

*Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим*

## *Ислам бинасының егылуы*



اسلام،

ترقی، اصلاح

محرری:

سرورالدين بن مفتاح‌الدين.

ناشری:

بدرالدين رفيقف.

КАЗАНЬ.
Электро-типографія „УМИДЪ".
1913.

Исламият бинасы, гаять нык торучы вә чыдамлы булган нигезенә, хәзрәте хатимел-әнбияи галәйһиссәлам[1] тарафыннан төзелүе хәлдә моны шулай ук аның сәхабәләре[2] вә һәм дә салих[3] өммәтләре булган табигун[4] вә табигы табигыйн[5] хәзрәтләре дә шул бинаны һаман үстерделәр.

Соңра буыннан-буынга акрынлап ислам хәлифәләре, әмирләре, хамиләре[6], мөхафизләре[7], баниләре[8], мөһәндисләре[9], мигъмарлары[10], галимнәре, мөзаһирләре[11] билгеле булып, ул бинаны һаман төзекләндереп үстерделәр. Вә аның шулай ук гүзәллек вә матурлыкларын да күрсәткәннәре хәлдә мәнар[12] вә нурларын да шуның белән күтәрделәр. Аның тирәсенә бөтен инсаннарны да җәлеп итеп вә үзенә тартып, һәммәсе аның күләгәсе, химаясе[13] астына керделәр. Вә һәммә төрле инсаннар бу бинаның химаясенә тупланып, матди вә мәгънәви һәлакәтләрдән сакланырлар иде. Аның гүзәл вә нәфис булган сарайлары, бакчалары, мәнзарәләре[14], баганалары, терәкләре, тәрәзәләре астында нәзакәтле булган хуш һавасы вә табигате белән тәрбия кылынырлар иде. Вә ул олуг бинаның эчендә шулай ук олуг китапханәләре булып, миллионнарча китаплар сакланыр иде. Төрле дәресханәләре булып, меңнәрчә-йөз меңнәрчә мәдрәсәләр вә мөгаллимнәре булыр иде. Вә ул бинаның почмакларында рәсадханәләре[15], шифаханәләре, даруханәләре вә гыйльме хәйванат вә нәбатат бакчалары[16] бар иде. Вә мәхкәмәләре, дарел-казалары[17] бар иде. Вә ул бинаның бөтен эче гыйлем, вә белем, вә өстенлек вә камиллек, гаделлек, хаклылык белән балкыр иде. Аның шулай ук бәрәкәтләреннән, игелекле эшләреннән һәркем файдаланыр иде. Аның матди вә мәгънәви булган малларыннан вә ризыкларыннан һәркем ашар вә эчәрләр иде.

Вә бу бинаның төп нигезе тәүхид[18] вә кәлимәте имания[19] иде ки: бу шулай ук Коръәне Шәрифнең *(Аллаһның ничек мисал итеп яхшы сүз китерүен күрмәдеңмени: ул яхшы агач шикелле, тамыры аның нык, ботаклары исә күктә. Ул һәрвакыт Раббысының изен-рөхсәте белән җимеш китерә...)*[20] изге аяте белән аңлатылган вә мисал итеп китерелгәндер. (Диянәте исламиянең[21] төп нигезе Ибраһим галәйһиссәламнең дине булып, бәлки дә, аны яңадан торгызудан гыйбарәттер.

---

[1] Хәзрәте хатимел-әнбияи галәйһиссәлам – Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең күркәм исемнәреннән берсе.
[2] Сахабәләр – Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрне күреп белгән һәм аңа ияргән кешеләр.
[3] Салих – изге.
[4] Табигун – сахабәләрне күреп белгән, алардан дини белем алган кешеләр.
[5] Табигы табигыйн – табигуннарны күреп белгән кешеләр.
[6] Хамиләре – яклаучылары.
[7] Мөхафизләре – саклаучылары.
[8] Баниләре – нигез салучылары, төзүчеләре.
[9] Мөһәндисләре – инженерлары.
[10] Мигъмарлары – архитекторлары.
[11] Мөзаһирләре – ярдәм итүчеләре.
[12] Мәнар – маяк.
[13] Химаясе – яклавы.
[14] Мәнзарәләре – күренешләре.
[15] Рәсадханәләре – обсерваторияләры.
[16] Гыйльме хәйванат вә нәбатат бакчалары – зоология һәм ботаника бакчалары.
[17] Дарел-казалары – хөкем чыгару йортлары.
[18] Тәүхид – бер генә Аллаһыга ышану.
[19] Кәлимәте имания – иман кәлимәсе.
[20] «Ибраһим» сүрәсе, 24-25 нче аятьләр. Монда һәм алдагы аятьләрнең мәгънәләренең татарчага тәрҗемәсе Фәрид Сәлман тәфсиреннән алынды.
[21] Диянәте исламиянең – ислам динен тотуның.

Бәни Исраил[22] пәйгамбәрләре гәрчә аның динен торгызсалар да, исраилиләрнең һәртөрле исраилият вә хорафатлары белән ул һаман югалды. Ахырда гарәп пәйгамбәре (с.г.в.) төптән төзекләндерде вә торгызды. Аны кагыйдәләр вә кануннар белән кулга алып, таза рәвештә төзеде. Ләкин моны да аудардылар.

Хәзрәте Ибраһимның динен гәрчә бәни Исраил пәйгамбәрләре төзәтсәләр дә, исраилиләр үзләре аннан файдаланмадылар. Бәлки дә, аның әсәре иске юнан[23] фәлсәфәчеләренә күчеп, аларга насыйп булды. Әмма ислам бинасының әсәрләре исә Аурупалыларга насыйп булды. Үзләре мәхрүм калдылар.)

Вә шуңа күрә бу бина гаять нык торучы вә чыдамлы булган ысул вә кагыйдәләргә корылган иде. Шуның өчен дә аңа катнашы булып сыенган вә ябышкан инсаннар да һәрвакыт тук вә сакланып калачаклар иде.

Ләкин бу бина тәмам булмады, тиз җимерелә башлады. Аңа да эчтән вә тыштан балталар чабыла башлады. Вә шул сәбәптән моның гомере өч-дүрт буын вә гасырлардан артык заманнарга бармады. Моның диварлары егылды.

Чөнки бу гүзәл вә нәфис бинаны эчтән вә тыштан җимерделәр. Эчендә булганнарның һәммәсеннән: залим мөстәбидләр[24], мөсрифләр[25], мөтрәфиләр[26] бу бинаның диварларын басып ектылар. Пакь вә гүзәл сарайларны җәберләүчеләр, мөсрифләр, җинаятьчеләр, тиләләр пычраттылар.

Вә төрле фикердә, вә карашларда булган мөһәндисләре, мигъмарлары, мәзһәб башлары, баниләре кайвакытта бер тараф вә кайвакытта икенче тарафка тартулары хәлдә бинаны төрле якка бордылар. Вә бинаның төзәтелүендә вә тәмамлануында талашып эшләр тукталды. Моның сәбәбеннән шулай ук бина тәмам булмыйча калды.

Әмма бинаның тышыннан җимерүчеләр: гареб[27] вә шәрык тарафларыннан билгеле булган иде. Мәсәлән, гареб тарафыннан салибиюн фиркаләре[28] бинаның китапханәләрен, мәдрәсәләрен яктылар вә боздылар. Эчендәге бөек галимнәрен, мигъмарларын, хәким[29] вә фәлсәфәчеләрен үтерделәр.

Шәрыктан: Чыңгызлар[30], Һөлүкүләр[31], Тимерләр[32] килеп, шулай ук ислам бинасының астын-өскә әйләндереп капладылар. Моның сәбәбеннән бөтен китапханәләре, рәсадханәләре, мәсҗед вә мәдрәсәләре, сарайлары, бакчалары, мәхкәмәләре, хакимнәре[33], галимнәре, мөһәндисләре, хәкимнәре, мөхафизләре, хамиләре, баниләре, мөгаллим вә мөдәррисләре, мөслихләре[34], салихләре, – бөтенесе һәлак булып, һәммәсе юкка чыктылар. Моның белән берлектә шулай ук голүм[35] вә белемнәре, вә өстенлек, вә камиллекләр дә – һәммәсе югалды-

---

[22] Бәни Исраил – Исраил балалары, ягъни яһүдләр.
[23] Иске юнан – борынгы грек.
[24] Мөстәбидләр – деспотлар, изүчеләр.
[25] Мөсрифләр – исраф итүчеләр.
[26] Мөтрәфиләр – иркен тормышта яшәүчеләр.
[27] Гареб – көнбатыш.
[28] Салибиюн фиркаләре – хач йөртүчеләр (крестоносецлар) төркемнәре.
[29] Хәким – бик акыллы һәм белемле кеше.
[30] Чыңгыз хан (1155 ел тирәсе-1227) – Монгол империясенә нигез салучы, аның беренче бөек ханы.
[31] Һөлүкү хан (1217-1265) – Чыңгыз ханның оныгы, Илханилар дәүләтенә нигез салучы.
[32] Аксак Тимер (1336-1405) – әмир. Урта Азиядәге төрки дәүләт идарәчесе, Тимуриләр нәселенә нигез салучы.
[33] Хакимнәре – судьялары.
[34] Мөслихләре – реформаторлары.
[35] Голүм – гыйлемнең күплек саны.

лар. Бинаның асыл планнары вә осуле һәндәсияләре[36] бөтенләй юк булды. Бинаның ялгыз төп нигезләре Коръәне Шәриф вә рәсүлулла хәдисләре дә яшерен рәвештә калып, аның ирешкәннәреннән һичнәрсә калмады. Гәрчә беркадәр әсәрләре калган булса да, бу шулай ук аның ялгыз хәрабәләреннән вә калдыкларыннан гыйбарәт иде. Вә черек, бозык булган нәрсәләре җөмләсеннән иде. Барысы файдасыз иде.

## Соңгы әдәбият вә хөкүмәтләр

Олуг ислам бинасы вә гарәп мәдәнияте тәмам егылып, аның күркәм эшләре, бөекләре, гыйлем вә белемнәре, әдәбият вә фәннәре бөтенләй юкка чыгудан соң, аның әсәрләреннән вә эзләреннән булган бераз гына нәрсәләр калган иде. Болар исә ислам әдәбияты вә гыйлемнәре исемендә кулланыла торган иде. Вә моның ияләре, вә саклаучылары да галимнәр исемендә булырлар иде.

1. Мәсәлән, бу әдәбият, гарәбияттән калган нәхүләр[37], сарыфлар[38], лөгатьләр[39], бәян[40], бәлягатьләр[41] булып, һәммәсе каршылыклы кагыйдәләрдән гыйбарәт иде. Ягъни хиҗазиюн, басриюн, куфиюн, бәгдадиюн[42] имамнарының каршылыкларыннан билгеле булган, бер-беренә каршы булган кагыйдәләрдән гыйбарәт гарәбият[43] китаплары иде.

2. Кәлям[44] вә мантыйк[45] китаплары иде ки, болар исә ялгыз мәзһәб фиркаләре вә өммәтнең үзләре арасында билгеле булган төрле гакыйдәләрнең[46] проблемаларын хәл итү өчен низаглар вә бәхәсләшүләрдән гыйбарәт иде. Ягъни могтәзиләләр[47], батыйнилар[48], шигыйләр[49], мөшәббәһәләр[50] кебек фиркаләрнең арасындагы мәсьәләләр хакында иде. Вә боларның бөтенесе исламның хакыйкый ысулларының тышында булып, ялгыз буш хыяллардан гына гыйбарәт иде. Коръән тәгълименнән дә булмыйча, шулай ук тәгълим вә тәрбиянең дә ысулларына бик ерак иде. Бәлки дә, хакыйкый нәрсәләрдән дә бөтенләй ерак иде.

3. Фикъһ исемендә булган берничә төрле әсәрләр вә китаплар иде ки, болар шулай ук тик ялгыз каршылыклардан гыйбарәт иде. Ягъни, хәнәфиләр, шафигыйлар, маликиләр, хәнбәлиләрнең[51] арасында булган каршылыклы кагыйдәләр

---

[36] Осуле һәндәсияләре – асыл проектлары.
[37] Нәхүләр – синтаксислары.
[38] Сарыфлар – морфологияләре.
[39] Лөгатьләр – сүзлекләр.
[40] Бәян – әдәбият теориясенең метонимия, метафора, аллегория һәм чагыштыру кебек сурәтләү чаралары турында сөйли торган бүлеге.
[41] Бәлягатьләр – сөйләү осталыклары.
[42] Миҗазиюн, басриюн, куфиюн, бәгдадиюн – гарәп әдәбиятында булган агым-мәктәпләрнең исемнәре.
[43] Гарәбият – гарәп әдәбияты, филологиясе.
[44] Кәлям – мөселманнарның схоластик дин белеме системасы, дин фәлсәфәсендә акылга таянып фикерләү.
[45] Мантыйк – логика.
[46] Гакыйдәләрнең – иман китерү шартларының.
[47] Могтәзиләләр – мөселманнар арасында күпчелектән аерылып чыккан бер юнәлеш. Үзләрен «әһлел-гадел вә тәүхид» – «гаделлек вә тәүхид әһелләре» дип атыйлар.
[48] Батыйнилар – Коръәнне аллегорик рәвештә аңлату һәм дини тәгълиматның «яшерен хакыйкатен» ачу тарафдарлары, секта.
[49] Шигыйләр – Мөхәммәд (с.г.в.) нәселе генә мөселманнар өммәтенә башлык – имам булырга тиеш дип санаучы агым.
[50] Мөшәббәһәләр – Аллаһының сыйфатларын башка яратылган әйберләр белән тиңләүчеләр.
[51] Хәнәфиләр, шафигыйлар, маликиләр, хәнбәлиләр – Ислам диненең сөнни юнәлешендәге гомуми танылган 4 хокук системасы тарафдарлары.

вә мәсьәләләрдән генә гыйбарәт булган китаплар булып, һичберендә бер карар юк иде. Вә шуңа күрә бу китапларның һичбере дә өммәткә фикъһ тәрбиясен бирмәделәр.

4. Чамадан тыш арттырулардан барлыкка килгән әхлак вә тәсаувыф[52] китаплары иде ки, бу китапларның һәрбере дә өммәтнең дөньяви тормышын вә матди максатларын вәйран кылып, китап вә сөннәтнең юлыннан бөтенләй ерак иде. Бәлки дә, бу ислами тәсаувыфның да кагыйдә вә ысулларына туры килмичә, рәһбаннар[53], күрәзәчеләр тоткан юлларга якынайган иде. Вә шуңа күрә бу да өммәткә исламият тәрбиясен бирмәде.

Менә, соң дәвердә булган өммәтнең голүм вә әдәбияттан булган сәрмаяләре[54] моннан гыйбарәт иде. Коръән Шәрифнең тәфсирләре дә ялгыз исраилият белән аңлатудан гыйбарәт булып, шулай ук рөхсәт ителгән хәдис китаплары да төрле шәрехләрдән генә гыйбарәт иде.

Соңгы өммәт исә, шуларны нигез итүләре хәлдә мәдәниләштерергә теләде вә шул нигезенә тәгълим вә тәрбия ысулларын куеп, ислам диянәтен белдерде вә күрсәтте. Вә илаһи динне моның белән дөньяга күрсәтеп, мөселманнарны да бу тәрбия белән мәйданга чыгардылар; бөтен ислам галиме дә, ялгыз шул тәрбия белән генә тәрбияләнеп, дөньяда билгеле булдылар.

Шул тәрбия вә тәгълимне төп нигез итеп, шәрык вә гаребтә яңа ислам хөкүмәтләре оешты.

Мәсәлән, Шәрыкта төзелгән яңа хөкүмәтләр исә төрек вә төрекмән кабиләләреннән булырлар ки, болар шулай ук Чыңгыз вә Һөлүгүнең кисәкләреннән соңра билгеле булган Илханилар дәүләте, Тимур дәүләте, шимальдә[55] – Дәште Кыпчак дәүләте[56], Һиндта – Баберия дәүләте[57], Анатулыда – Госмания дәүләте, Иранда – Сафәвия дәүләте[58] кебек хөкүмәтләрдән гыйбарәт булырлар.

Әмма гаребтә билгеле булган ислам хөкүмәтләре исә: Мисырдан алып Мәгърибкә кадәр булган Тунис, Җәзаир[59], Фас[60] кебек гарәпләр, мәгърибиләрдән гыйбарәт булырлар ки, болар исә шулай ук гарәпләрнең вә әндәлүслиләрнең[61] юкка чыгуларыннан соң билгеле булган хөкүмәтләрдер.

Бу хөкүмәтләрнең эчендә иң мәшһүр вә бөек булганнары Төркестанда билгеле Тимур хөкүмәте булып, икенчесе шулай ук Госманлы хөкүмәте иде.

Чөнки бу ике хөкүмәт исә, соңгы ислам хөкүмәтләренең эчендә аерым хәлдә мәдәниләштерү юлына кереп, ислам голүм вә әдәбиятын да башкалардан күрә артыкча торгыздылар вә тараттылар. Башкалары исә голүм вә әдәбият өлешендә боларга иярделәр.

---

[52] Тәсаувыф – мистицизм, суфичылык.
[53] Рәһбаннар – монахлар.
[54] Сәрмаяләре – төп байлыклары.
[55] Шимальдә – төньякта.
[56] Дәште Кыпчак дәүләте – (Кыпчак даласы), Иртыш елгасыннан Дунай елгасына кадәр, Балхаш күленнән Сыр-Дәрьяның түбән агымына, аннан Кырымга кадәр сузылган, Идел буе Болгары белән рус кенәзлекләре чигенә хәтле булган кыпчак җирләренең атамасы.
[57] Баберия дәүләте – хәзерге Һиндстан, Пакыстан һәм көньяк Әфганстан җирләрендә төзелгән төрки-могол дәүләте. Бабер шаһ тарафыннан 1526 елда корылган.
[58] Сафәвия дәүләте – Урта Көнчыгыштагы феодаль дәүләт (1502-1736); исеме анда идарә иткән Сафәвиләр нәселеннән алынган. Үзе эченә Азәрбайҗан, өлешчә Әрмәнстан, Иран, хәзерге Әфганстан җирләрен алган.
[59] Җәзаир – Алжир.
[60] Фас – Африканың төньягында урнашкан ислам дөньясының иң зур мәдәният һәм мәгърифәт үзәге булган шәһәр (хәзерге Марокко җирлегендә).
[61] Әндәлүсиләр – Әндәлүс (хәзерге Испания җирлегендә) хәлифәтендә яшәүчеләр.

Фәкать шул кадәресе бардыр ки: бу хөкүмәтләр гәрчә хөкүмәт төзеп ислам голүм вә әдәбиятын яңадан торгызсалар да, исламиятнең хәрабәләре вә черек диварларына яңа биналарын кордылар. Ягъни егылган иске ислам бинасының хәрабәләрен вә черек диварларын алып ташламаенча, вә шуның өстенә яңа бина салдылар. Бәлки дә, асыл төп ислам нигезен дә яхшы аңламадылар.

Вә шуңа күрә бу соңгы биналарның да шулай ук диварлары, нигезләре таза булмады. Шуның өчен бик тиз заман эчендә егылырга, җимерелергә лаек булды. Вә шуңа күрә болар, гәрчә исламиятне яңадан торгызган вә тараткан булсалар да, төбеннән төзәтү вә яңарту белән булышмадылар.

Тимур дәүләте исә Хөрасан[62] вә Мавәраннәһер[63] тарафларында VIII гасыр һиҗриялә рдә оешып үзе вә угыллары гәрчә ислам мәдәниятенә хезмәт итеп, ул заманда Тәфтазаниләр[64], Җөрҗаниләр[65], Кушҗиләр[66], Гыясетдинләр[67], Казыйзадәләр[68], Шаһрухлар[69], Олугбәкләр[70] кебек соң дәвернең иң бөек вә мәшһүр ирләре билгеле булып, ислам голүм вә әдәбиятын яңадан торгызган, вә таныткан булсалар да, алар шулай ук ислам диянәтен төп нигезеннән төзәтмәделәр. Аларның корган әдәбият вә рәсадханәләре, вә, бәлки дә, бөтен планнары ислам бинасының ялгыз черек диварлары, хәрабәләре үзәрендә иде. Алар исә төп нигезне төзәтмичә вә яңартмыйча яңадан бина салдылар. Вә шуңа күрә аларның яңадан салган биналарының эченнән яңа дәвер өчен Бохарилар[71], Мөслимнәр[72], Нәвавиләр[73], Бәгавиләр[74], Сәрхәсиләр[75], Газалилар[76], Ибне

[62] Хөрасан – үзенең эченә көнчыгыш Иран, өлешчә Әфганстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан һәм Таҗикстан җирләрен алган тарихи өлкә.
[63] Мавәраннәһер – Үзәк Азиядәге тарихи өлкә. Бу исем VII-VIII гасырларда гарәп яулап алулары вакытында барлыкка килә һәм башлыча Амударья елгасының уң як ярында урнашкан өлкәләрне үз эченә ала.
[64] Тәфтазани, Сәгъдетдин Мәсгуд бине Гомәр (1322-1390) – атаклы мөтәкаллим-фәлсәфәче, математик. Хезмәтләрен гарәп телендә язган.
[65] Җөрҗани, Гали бине Мөхәммәд (1340-1413) – атаклы фәлсәфәче, мөтәкаллим-фәлсәфәче, астроном һәм грамматик. Күпсанлы хезмәтләр авторы.
[66] Кушҗи, Галәветдин Гали бине Мөхәммәд (1403-1474) – Урта Азия математигы һәм астрономы, Сәмәрканд обсерваториясе җитәкчесе. Олугбәкнең вафатыннан соң, Константинопольгә күчеп, Ая Суфия мәчете каршында мәдрәсә ача. Тел белеме буенча хезмәтләр авторы.
[67] Гыясетдин Әбүлфатих Гомәр ибне Ибраһим әл-Хәййам Нишапури, Гомәр Хәййам (1048-1131) – атаклы шагыйрь, математик, астроном, фәлсәфәче, табиб.
[68] Казыйзадә (1360-1437) – Урта Азиянең бөек галиме, математик, астроном. Сәмәркандта яшәгән, Олугбәкнең астрономия гыйлеме буенча укытучысы.
[69] Шаһрух (1377-1447) – Аксак Тимернең дүртенче улы, Хөрасан (1397 елдан), Тимерлеләр дәүләте (1409 елдан) һәм Гыйрак (1420 елдан) хөкемдары. Атаклы астроном Олугбәкнең атасы.
[70] Мөхәммәд Олугбәк (1394-1449) – астроном һәм математик, Аксак Тимернең оныгы, 1409 елда Сәмәркандның идарәчесе, атасы Шаһрух үлгәннән соң (1447) Тимерлеләр династиясе башлыгы. Ул дәүләт җитәкчесе булганда шул заманның атаклы галимнәре Сәмәркандка туплана.
[71] Бохари, Мөхәммәд ибне Исмәгыйль ибне Ибраһим (810-870) – атаклы ислам галиме, «Әл-Җамигес-сәхих» яки «Сахихел-Бохари» исемле иң мәшһүр һәм абруйлы хәдисләр җыентыгы авторы.
[72] Имам Мөслим яки Мөслим ибне Хөсәен ибнел-Хәҗҗәҗ (821-875) – мәшһүр ислам эшлеклесе, танылган хәдисләр җыентыгы – «Сахихел-Мөслим»нең авторы.
[73] ИмамӘн-Нәвави (1234-1278) – мәшһүр ислам галиме, шәфигый мәзһәбе фәкыйһе (шәригать кануннарын яхшы белүче), хәдисләр белгече. Күпсанлы хезмәтләр авторы.
[74] Имам Әбү Мөхәммәд әл-Бәгави (1044–1117) – мәшһүр ислам галиме, шәфигый мәзһәбе фәкыйһе, хәдисләр белгече. Мәшһүр тәфсир авторы.
[75] Мөхәммәд бине Әхмәд әс-Сәрхәси әл-Хәнәфи (?-1097) – хәнәфи мәзһәбе галиме, фикъһ буенча хезмәтләр авторы.
[76] Әбү-Хәмид Мөхәммәд ибне Мөхәммәд әл-Газали (1058-1111) – ислам дине галиме һәм фәлсәфәчесе. Тумышы белән Хөрасан өлкәсеннән. Суфичылык һәм фикъһ буенча хезмәтләр авторы.

Тәймияләр[77], Ибне Кайимнәр[78], Ибне Синалар[79], Фарәбиләр[80], Әбү Рәйханнар[81], Ибне Гасакирләр[82], Ибне Әсирләр[83], Ибне Гарәбиләр[84] кебек яңа бөекләр чыкмады.

Әгәр дә Ал Тимурлар исламның төп нигезеннән төзәтеп яңа бина кылган булсалар иде, ягъни асыл Коръән Шәриф вә сәләфе салихийиннең тарикате[85] нигезенә планнарны корган булсалар иде; искә алынган бөекләр кебек, шулай ук ничә бөекләр соң дәвердән шөбһәсез билгеле булачак иде. Хәзрәте пәйгамбәребез вә аның сәхабәләренең планнары вә биналары яңадан төзекләндереләчәк вә тәмамланачак иде. Вә Чыңгызлар, Һөлүгүләр, салибиюннар, җинаятьчеләр, мөстәбидләр вәйран вә хәраб кылган китапханәләр, гыйлем вә белемнәр яңадан билгеле булачак иде.

Тимур дәверенең тергезгәнголүм вә әдәбиятның орлыклары Сәмәрканд шәһәреннән башлап Бохара вә шималь төрекләре булган татарларга (Казан тарафларына) кадәр таралып соңра шулай ук Һиндстанда Дәһли шәһәрендәге Ал Тимурдан булган бабериләр аркылы Һинд тарафларына кадәр таралды. Хәтта госманиләргә кадәр барды.

Бохараның соңгы дәвердә булган бөек галимнәре вә мөдәррисләре, дамелляләре[86] – һәммәсенең гыйлемнәре, тәрбияләре исә ул дәвернең тәэсирләреннән иде.

Казан тарафларының да галимнәре, мөдәррисләре һәрбере дә Тәфтазаниләр, Мирсәедләр[87], Диваниләр[88], Кушҗиләр, Казыйзадәләр, Каһстаниләрне[89], хәтта Бохариләр, Мөслимнәр, Газалиләр, Әбү Хәнифәләр[90], Ибне Хәнбәлләрдән[91] күрә

[77] Әбү Габбас Тәкыйддин Әхмәд бине Тәймия әл-Хәррани (1263-1328) – хәнбәли мәзһәбе буенча фикъһ белгече, дингә яңа гадәтләр кертүнең тәнкыйтьчесе.
[78] Ибне әл-Кайим әл-Җәүзия (1292-1350) – Ибне Тәймиянең шәкерте, хәнбәли мәзһәбе буенча фикъһ белгече.
[79] Әбү Гали Хөсәен ибне Габдулла ибне Сина (980-1037) – урта гасыр мөселман дөньясының энциклопедист галиме, фәлсәфәче, табиб буларак танылган.
[80] Әбү Насыйр Мөхәммәт ибне Мөхәммәт ибне Тархан ибне Үзләг әл-Фәраби (872-950) – фәлсәфәче, математик, астроном, тел белгече. Урта гасыр фәлсәфәсенең күренекле вәкиле. Аристотель һәм Платон хезмәтләренә шәрехләр язучы.
[81] Әбү Рәйхан Мөхәммәт әл-Бируни (973-1048) – бөек төрки-фарсы галиме, тарих, география, тел белеме, астрономия, математика, геодезия, минералогия, геология буенча күп хезмәтләр авторы. Үз вакытының бөтен фәннәрен диярлек белгән. Шулай ук шагыйрь буларак танылган.
[82] Гали бине Хәсән бине Хибатулла Әбүль-Касыйм Ибне Гасакир (1105-1175) – гарәп тарихчысы. Димәшектә туган. 80 томнан торган «Тарихе мәдинәте Димәшек» исемле хезмәт авторы.
[83] Гыйззеддин Әбүл Хәсән Гали бине Мөхәммәд бине Габделкәрим әл-Җәзәри ибне Әсир (1160-1234) – мәшһүр гарәп тарихчысы. «Тарихел-камил» әсәрендә Болгарны зикер итә.
[84] Мөхетдин Мөхәммәд ибне Гали ибне Мөхәммәд ибне Гарәби әл-Хатыйми ат-Таэиәл-Әндәлүси (1165-1240) – ислам галиме, суфичылык тәгълиматчысы һәм күренекле вәкиле. «Әш-шәйхел-әкбар» – «Бөек укытучы» кушаматына лаек булган.
[85] Сәләфе салихийиннең тарикате – изге сәхабәләр һәм табигыйннәр юлы.
[86] Дамелляләре – укымышлылары.
[87] Мирсәед Шәриф әл-Җөрҗәни (?-1413) – ислам галиме, гарәп грамматикасы буенча китаплар авторы.
[88] Дивани, Гали ибне Мөхәммәд ибне Әбү Сәгъд (1265-1342) – Коръән укылышының төрләрен камил белгән мәшһүр галим.
[89] Әл-Каһстани, Шәмседдин Мөхәммәд (?-1546) – хәнәфи мәзһәбе фәкыйһе, Бохара мөфтие. «Җәмигыр-рөмуз» китабы авторы.
[90] Имам Әгъзам Әбү Хәнифә Ногман ибне Сабит ибне Зута әл-Фариси (699-767) – бөек ислам галиме, фәкыйһ, 4 сөнни мәзһәбнең берсенә нигез салучы.
[91] Әхмәд бине Мөхәммәд ибне Хәнбәл Әбү Габдулла әш-Шәйбани (780-856) – ислам диненең фикъһ, хәдисләр, гакыйдәһәм башка өлкәләрендә дан казанган галим, хәнбәли мәзһәбенә нигез салучы.

артык телгә алырлар. Ибне Җәрирләр[92], Ибне Гатыяләр[93], Ибне Хәземнәр[94] кебек ислам бөекләрен һич тә белмәсләр.

Вә хәлбуки, бу тәрбия шулкадәр файдасыз булыр ки, моннан өммәткә ике төрле афәт иреште.

Бере – бу тәрбия өммәтне вәхшәт вә наданлыкның гадәтләреннән чыгармады. Ягъни өммәтне әсатыйрдәвереннән[95] калган төрле гадәтләрдән тазартмаенча, аларны шулай ук әшәкелектән вә бозыклыктан да һич тә тазарта алмады.

Икенчесе – бу әдәбият өммәткә һичбер яктан иҗтимагый тормыш бирмәде. Ягъни өммәтне берләштереп ислам вә кешелеккә кертеп җибәрә алмады. Вә шуңа күрә бөтен өммәт тә таркалыш, каршылык, икейөзлелек, бүленү эчендә калды. Вә бер тарафтан шулай ук алар явыз гадәтләрдән фанатизм, җенеслек сыйфаты кебек хәмияте җаһилияләрендә[96] калдылар.

Мәсәлән, гарәплек, фарсылык, төреклек, көрдлек, татарлык, таҗиклык кебек җаһилият максатларында калдылар. Вә бер тарафтан, хәнәфилек, шафигыйлек, маликилык, суфилык кебек максатларга аерылып, асыл вә мөкатдәс максатны оныттылар. Бәлки дә, бу кагыйдәләреннән һич тә чыга алмадылар. Һәрбере дә үзенең нәсел-милләтен дин вә инсаниятеннән артык күреп яклап тырышырлар. Хәтта моның белән дин вә инсаниятне кайвакыт онытырлар.

Вә шуңа күрә соңгы дәвернең дәүләт вә хөкүмәтләре, бер тарафтан җитешеп оешсалар да, икенче тарафтан бик тиз юкка чыгарлар.

Тимуриләр, Бабериләр вә Дәште Кыпчактагы Алтын Урда хөкүмәтләре вә Ирандагы Илихания[97] хөкүмәтләре дә шуның өчен бик тиз юкка чыктылар. Чөнки һәрбере дә черек нигезгә төзелеп вә черек әдәбият белән тәрбия кылынырлар иде. Вә һичберендә дә хакыйкый төзәтү вә яңарту юк иде.

Мәсәлән, Ирандагы Илихания (1652 елда Лондон шәһәрендә нәшер ителгән тул вә гарыз җәдвәлләре[98] илихания рәсадханәсеннән Насыйретдин Тусинең[99] (зиҗ)ләреннән[100] алынгандыр) дәүләте бөек рәсадханәләр, академияләр вә бөек китапханәләр төзесәләр дә, асыл ислам бинасын төзәтмәделәр, бәлки дә, аның черек булган хәрабәсенә боларны төзеделәр. Вә шуңа күрә аларның да моның кебек мәдәни әсәрләре бик тиз юкка чыкты.

Сәмәрканд шәһәрендәге рәсадханә (Сәмәркандның рәсадханәсенең зиҗләре исә Англиянең Оксфорд шәһәрендә 1665 елда нәшер ителгәндер) белән шулай ук һиҗри XII гасырларда булган Һиндтәге Дәһли шәһәрендәге рәсадханә дә тиз юкка чыкты.

Соңгы дәвернең гареб тарафында булган гарәп хөкүмәтләре дә черек нигезләргә төзелгән иде.

---

[92] Әбү Җәгъфәр Мөхәммәд ибне Җәрир ибне әт-Табәри (839-923) – ислам галиме, тарихчы, «Тәфсирет-Табәри» авторы.
[93] Габделхак ибне Галиб ибне Габдерахман ибне Гатыя (1088-1148) – ислам галиме, фәкыйһ, тәфсир авторы.
[94] Ибне Хәзем, Әбү Мөхәммәд Гали бине Әхмәд бине Сәид әл-Әндәлүси (994-1064) – гарәп илаһиятчесе, фәкыйһ, фәлсәфәче, тарихчы, шагыйрь.
[95] Әсатыйр дәвереннән – борынгы риваятьләр, әкиятләр дәвереннән.
[96] Хәмияте җаһилия – наданлык гайрәте.
[97] Илхания – илханилар дәүләте.
[98] Тул вә гарыз җәдвәлләре – географик озынлык вә киңлек таблицалары.
[99] Туси, Насыйретдин (1201-1274) – фарсы фәлсәфәчесе, математигы һәм астрономы, фәлсәфә, география, музыка, медицина, минералогия буенча хезмәтләр авторы.
[100] Зиҗ – астрономик календарь. Ислам илләрендә йолдызлар җәдвәлләре өчен гомуми атама. Җәдвәлләрдән тыш, зиҗләргә алар белән файдалану кагыйдәләрен дә керткәннәр.

Мәсәлән, Мисырдан башлап Тарабелүс гареб[101] вә Тунис, Җәзаир, Фас хөкүмәтләре – һәрбере дә салибиюнның җимерүләреннән калган хәрабәләрнең черек диварлары өстенә хөкүмәтләрен салдылар. Чөнки исламның иске бинасыннан калган иң файдалы әсәрләрне Әндәлүстә испаниюннар вә салибиюн фиркаләре яндырганнар иде ки, бу хөкүмәтләр исә ялгыз шуларның көлләренә мәгыйшәт[102] вә җәмгыятьләрен төзеделәр. Вә шуның белән генә тәрбия кылындылар.

Вә бер тарафтан шулай ук: Шазалиләр[103], Шәгъраниләрнең[104] юллары, тәрбияләре сәбәбеннән дөньяви тормышларын тәмам оныттылар.

Шуңа күрә бөтен соңгы өммәт тә, хәятләрен вә бердәмлекләрен саклый алмыйча, ахырда аурупалыларның корган тозакларына төшеп беттеләр. Моның сәбәбеннән шулай ук бердәмлекләреннән бөтенләй аерылдылар.

*Текстны басмага **Айрат Заһидуллин** әзерләде.* ■

[101] Тарабелүс гареб – Триполи, хәзер Ливия башкаласы.
[102] Мәгыйшәт – тормыш.
[103] Әбел-Хәсән Шазали (1197-1258) – Шазилия суфи тарикатенә нигез салучы.
[104] Габделвәһаб ибне Әхмәд ибне Гали әш-Шәгърани (1493-1565) – ислам галиме, суфичылык турындагы хезмәтләр авторы.

**Сәрвәретдин Сабитов иҗатын өйрәнүгә багышланган «түгәрәк өстәл». Галимнең рухына дога кылган вакыт**

# Гариза

Рабит Батулла

**Язучыларның Беренче Бөтенсоюз съезды вакытында. Беренче рәттә сулдан: К.Нәҗми, А.Толстой, М.Горький, К.Тинчурин; икенче рәттә сулдан: К.Төхфәтуллин, Л.Гыйльми, Х.Туфан, Г.Толымбайский, Г.Нигъмәти, Г.Ризванов. 1934 ел**

Кәрим Тинчуринның сурәт ядкярләрен аралаганда бер рәсем килеп чыкты. Тинчурин үзе төшергән фотосурәт. Күрәсең, бу егетләр Кәрим Тинчурин өендә кунакта утырганда төшкәннәр. Рәсемдә өч ир-егет. Сулдан беренче утырганы язучы Фатих Сәйфи Казанлы икән. Ләкин аның йөзе каләм белән аркылы-торкылы сызгаланган. Гадәттә, андый эшне берни аңламаган сабый бала эшли. Заһидә ханым белән Кәримнең баласы булмаган. Кем сызгалаган Сәйфи Казанлының чыраен? Заһидә ханыммы, әллә Тинчурин үземе? Заһидә ханым да, Тинчурин да алай эшли алмый, чөнки алар бу рәсемне сакламаган, ерткалап чыгарып ташлаган булырлар иде. Сызгалаган кешенең Казанлыга ни сәбәпледер нәфрәте көчле булганы күренеп тора. Без ошбу серне, бәлки, беләдә алмабыз. Әмма Тинчуринның Татарстан язучылар берлегенә язган гаризасыннан без нидер аңлыйбыз кебек.

Гариза 1934 елның бишенче декабрендә язылган. Анда һәм башка текстларда да автор орфографиясе сакланды:

*«Татарстан Совет Язучылар Союзының Правлениесенә*
*Союз әгъзасы Кәрим Тинчуриннан*

*Г А Р И З А.*

*28 нче ноябрдә Татарстан Совет Язучылар Союзы Правлениесендә, Союз председателе иптәш Кави Нәҗми һәм шагыйрь Туфан алдында, минем иске иптәшем, карт язучы Фатих Сәйфи иптәш рәсми рәвештә мине плагиатлыкта гаепләп, минем язучылык һәм совет гражданлык намусымны таплый торган ялган-төһмәт белән каралады.*

*Фатих Сәйфи иптәшнең мине плагиатлыкта гаепләве моннан гыйбарәт!*

*«Җилкәнсез» пьесамның баш каһарманнарының берсе булган Мисбах хаҗи тибын Фатих Сәйфинең «Дошманнар» пьесасыннан урланганмын, имеш. Фатих Сәйфи утыз елдан бирле минем танышым һәм иптәшем булып килде. «Җилкәнсез» пьесамны, беренче мәртәбә сәхнәгә куелган көннән бирле, бик яхшы белә. Казанда, Татар дәүләт театрында 1926 нчы елда беренче кат уйналганнан соң, бик зур, тирән тикшерү нигезендә язылган рецензиясен «Кызыл Татарстан»да милләтчеләр һөҗүменнән чын күңелдән сакларга да тырышкан иде.*

*Тугыз елдан соң, Мисбах хаҗи «Дошманнар» пьесасыннан урланган, дип, Фатих Сәйфи иптәшнең мине совет җәмәгатьчелеге алдында хаксызга каралаларга тырышуына бернинди дә мәгънә бирә алмыйча хәйранга калам. Чөнки «Дошманнар» пьесында «Җилкәнсез»дәге Мисбах хаҗиның бер бармагына охшаган, тырнагына торырлык бер генә образ да юк. Шуңа карамастан, Фатих Сәйфи чеп-чи ялган ялалар белән мине совет җәмәгатьчелеге алдында каралаларга тырыша. Мондый тупас, дорфа рәвештә Фатих Сәйфинең миңа булган һөҗүменең сәбәпләрен беләсем килә. Һәм ул сәбәпләрне тикшерүне совет язучылары җәмәгатьчелеге алдына ачыктан-ачык куелышын һәм мине мондый кешелексез һөҗүмнәрдән аралавын, бөтен Совет язучылары җәмәгатьчелегеннән үтенәм.*

*Бөтен Советлар Союзы язучыларының Беренче съездына кадәр Фатих Сәйфи белән минем арам һичбер вакыт бозылганы юк иде. Мин аңа һаман, мәдрәсәдән бирле, якын иптәшем, дустым дип ышанып йөридер идем. Карт язучы, җәмәгать эшчесе, дип хөрмәтемне аңар саклап килә идем. Тарихи Беренче Совет язучылары съездыннан соң, Фатих Сәйфинең миңа булган мөнәсәбәтенең алмаша баруын сизә башладым. Баштарак аны да, аның шаярып сөйләвенә, яйсә холыксызлыгына гына юрыйдыр идем. Фатих Сәйфинең миңа бәйләнүләре, мине дискредитировать итәргә омтылулары турында тулысынча хөкемдар судында сөйләячәкмен. Фатих Сәйфи иптәш тарафыннан мине совет җәмәгатьчелеге алдында хур итәргә, йөземне каралтырга тырышуының бәлки тирән сәбәпләре дә бардыр. Хөкемдар суды алдында Фатих Сәйфи тарафыннан шул сәбәпләрнең барысын да ачыктан-ачык куюымның һәм аның Татарстан Совет язучылары җәмәгатьчелеге тарафыннан җентекләп тикшерелүен сорыйм. Юкса, сәбәпсез генә Фатих Сәйфи иптәш намуссыз, буржуа методлары белән мондый оятсыз, тупас рәвештә, мине совет җәмәгатьчелеге алында каралаларга батырчылык итмәс иде. Гомумән, совет язучылары арасын буржуа чүпләреннән, буржуа гадәтләреннән арындырырга кирәк.*

*Үз иҗадына, совет җәмәгатьчелегенә, гомумән, совет төзелешенә ихтирамы булган язучыга нахак рәвештә караклык бөһтаны язуны – язучыны рухан үтерергә тырышу, капиталистик методларның бер методы, дип аңлыйм. Минем бертөрле дә еласым килми әле. Киресенчә, Коммунистлар партиясе Совет хакимияте һәм совет җәмәгатьчелеге җитәкчелегендә күбрәк, яхшырак эшлисем, язучылык өлкәсендә ныгыйсым килә. 5. XII – 1934. К.Тинчурин»*

Кәрим Тинчуринның гомере өзелергә тагын дүрт ел гына калып бара. Сәйфи Казанлы да, Кәрим Тинчурин да репрессия шаукымы вакытында 1937-1938 нче елларда юкка чыга.

Бөек драматургның сөекле хатыны Заһидә ханым Тинчурина сөйли иде:

– Без Кәрим белән үзара төчеләнми идек. Без бер-беребезгә «яратам, сөям» дип әйтми идек, без бер-беребезне мотлак хөрмәт итә идек. Ләкин соңга таба, байтак кына яшәгәч, озаккарак, еракка киткән очракларда ул миңа хат яза яки ачык хатлар җибәрә торган иде. Баштарак «Заһидә» дип башлый иде хатларын, Әстерханда ул 8 ай торды, Әстерхан театрын җитәкләде. Соңыннан «Заһидә» урынына ул «Заһидәм!» дип яза башлады. Шуннан мин аңладым, «Заһидәм» булгач, ул мине ярата икән, дип уйладым. Аннан соң хатларын ул «Сөеклем Заһидә» дип башлый иде. Миңа ошый иде аның болай язганы. Менә аның 1937 елда язган хаты:

*«Сөеклем Заһидә!*

*Синнән бик озак вакытлар хат, хәбәр алмагач, телеграмма да җибәргән идем. Син хатлар язгансың икән. Тик ул хатлар ни өчендер бик кичегеп килделәр. Мин*

**Кәрим Тинчурин төшергән фотосурәттә (сурәт чистартылды) – Фатих Сәйфи Казанлы (сулда). Төшерү вакыты билгесез**

*синең 16, 17 нче июльдә язган хатларыңны фәкать 23ендә генә алдым. «Ил»нең җырларын урысчага тәрҗемә итүче шагыйрьнең фамилиясен белмәвем сәбәпле, фикеремне шагыйрьнең үзенә яза алмадым. Минем фикеремчә, тәрҗемәләре артык яхшы булмаса да, алай бик үк начар да түгел. Башка яхшырак шагыйрь табылмаганда, кабул итәргә кирәк булыр.*

*Бүген Ләбиб Гыйльмидән хат алдым. Алар Язучылар Союзы күләмендә шул бер ай эчендә бик күп һәм кирәкле эшләр эшләгәннәр: Ф.Бурнашны, Р.Ишморатны һәм Дублинский дигән кешеләрне Союздан чыгарганнар. Дублинский дигән кешене мин бөтенләй белмим. Әмма Ф.Бурнаш белән Р.Ишморатны союздан чыгарып, бик яхшы иткәннәр. Бу кешеләрнең үткәндәге һәм хәзерге эшләре Язучылар Союзында торырга аларга бертөрле дә хак бирми.*

*Үземнең көннәрем күбрәк вак колхозларда үтә. Урып-җыю эшләре башлану белән колхозлар бик җанланып китте. Кырлар тулы машиналар шау килеп эшлиләр. Мондагы игеннәрнең яхшылыгын картлар хәтерләмидер. Колхозчыларның күңелләре бик күтәренке. Пьесамны яза башлаганым юк әле. Һаман материаллар җыйныйм. Һаман план корам әле. Колхозларда бик күп йөрим. Җыелышларда катнашам. Үзем дә сөйлим. Колхозларда эшләр бик күңелле. Шуның белән безгә бик яхшы, колхозчылар һәм колхозлар булган кебек, колак-койрыкларны очраштыргалыйбыз. (Димәк, Тинчурин үзе артыннан куелган шымчыларны чамалаган. –* ***Р.Б.****)*

*Һаман-һаман тәрҗемә өстендә утырырга туры килгәнлектән, сиңа ял итәргә дә туры килмәгәндер. Менә шул хәл мине борчып тора.*

*«Һе, хан кызы булган. Әллә кем булган!» – дигән минем дорфа сүземне исеңә төшерүең яхшы түгел. Син дә миңа әйткәли идең бит. Ләкин мин аларны хәтерләмим. Син дә андый «художество сүзләрен» оныт.*

*«Ил»не бастырып, Ләбиб Гыйльмигә яйсә Пинхасик иптәшкә тапшырсаң, бик яхшы булыр иде.*

*Барысына да, барысына да күп сәлам. 25.VII. – 37.*

*Синең Кәримең».*

**Батулла аңлатмасы:** 1937 елның 2 июлендә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Кави Нәҗми **«**халык дошманы**»** мөһере белән кулга алынгач, бушаган урынга җитәкче итеп партия аппаратында **«**хезмәт чыныгуы узган**»** Ләбиб Гыйльмине куялар, ләкин аны да шул ук елның 21 сентябрендә кулга алалар һәм 1938 елның 9 маенда Казанның Черек күл подвалында атып үтерәләр. Л.Пинхасик, ягъни Лазарь Соломонович Пинхасик исә 1937 елның 1 июленә, ягъни кулга алынганга кадәр өлкә комитетында мәктәпләр һәм фәнни оешмалар бүлеге мөдире булып эшләгән, 1938 елның 9 маенда (Л.Гыйльми белән бер көнне) атып үтерелгән. Заһидә ханым Тинчуринның үтенече буенча **«**Ил**»** драмасын Пинхасикка тапшырмакчы була. Ләкин ул, инде аңлашылганча, драманы Пинхасикка тапшыра алмый. Озакламый Кәрим Тинчуринның үзен дә төрмәгә ябалар.

Заһидә Тинчурина архивын барлаганда тагын бер хатка юлыктык. Бу хат Хәсән Шабанов дигән кешегә аталган булырга тиеш. Ул чагында Хәсән Шабанов – нәшриятның баш мөхәррире, К.Тинчурин турында истәлекләр тупламасы чыгарырга әзерләнә. Күрәсең, ул Заһидә ханымнан ире К.Тинчурин турында истәлекләр язуын үтенгән булгандыр. Хаттан шулайрак аңлашыла:

**Атказанган артист Кәрим Тинчурин Әстерхан театры хезмәткәрләре Ф.Баканов, Ә.Әхмәтшин, Х.Аитов, А.Ибраһимов белән. 15 апрель, 1929 ел**



**Фотосурәт артына Әстерхан артистлары тарафыннан язылган текст. 15 апрель, 1929 ел**

*«Хөрмәтле Хәсән әфәнде!*

*Сезнең хатыгызны ияртмәсе белән алдым. Рәхмәт! Тәшәккүрдән гаҗизмен! Сез бик яхшы эш башлап җибәргәнсез, күптин-күп рәхмәтләрем Сезгә! Кызганыч ки, җыентыкны чыгаруда катнашучылардан мин ике кешенең хатирәләрен мәҗмугага кертелүе белән һич тә килешә алмыйм. Аларның берсе – Х.Уразиков, гәрчә, ул үзе үк (Тинчурин турында хатирәләр язмаячак, дип беләм), чөнки ул минем иремә бик теләктәш түгел иде, 1927 елда театрның режиссерын, актерын һәм драматургын – Кәрим Тинчуринны театр штатыннан китүен теләгәннәр арасында ул да бар иде. Яза икән, язсын. Ә менә катнашучыларның икенчесенә мин катгыян каршы һәм мәсьәләне тагын да катырак куям: әгәр дә җыентыкта аның хатирәләре урын алса, һичшиксез, мин ул эштә катнашу гына түгел, ул китапны кулыма алып укымаячакмын да. Сүзем Х.Төхфәтуллин турында. Хәзер сәбәпләрен аңлатам. Кайчан икәнен төгәл генә хәтерли алмыйм, бәлки, З.Ш.Байгильдина хәтерлидер (ул Дәүләт музее хезмәткәре иде ул чагында). Төхфәтуллин ул чагында Мәскәүдә Татар опера студиясенең җитәкчесе иде. К.Тинчурин белән Ш.Камал үз эшләре белән Мәскәүгә килгәч, Төхфәтуллин аларны кунакка чыкыра. Үзе исерек икән. Кунакларның икесен дә котчыккыч тупас каршы алган. Бу ике хөрмәтле язучы китәргә җыенгач, хуҗа кеше туры мәгънәсендә аларның икесен дә баскычтан тәгәрәтеп төшергән. Тинчурин – галстуксыз, Шариф абзый күзлексез чыгып йөгергән. Шулар өстенә аларның ар-*

*тыннан Төхфәтуллин аты-юлы белән көфер сүз яудырып калган. Тинчуринның хатыны адресына пычрак сүзләр кычкырган. Бу турыда мин Әдһәмова авызыннан ишеттем. Татар Студиясе үзләренең профессорлары белән Мәскәүдән уңышларын күрсәтергә Казанга кайткач, Төхфәтуллин үзенең кешесен безгә юллаган, Төхфәтуллин безгә килеп, Тинчурин белән күрешеп сөйләшергә тели икән. Әйттем: син, Кәрим, теләсәң ни кыл, син аны кичерә аласың, ләкин мин ул кешене бусагадан аягын да атлатмаячакмын, дидем. Бу турыда без ирем белән кабат сүз кузгатмадык. Әгәр җыентыкка минем хатирәләремне дә кертсәгез, рәхим итегез, ләкин алдан ук миңа күрсәтегез яки Х.Сәлимҗановка биреп укытыгыз. Г.Кайбицкая мәкаләсен дә күрсәтерсез, күрәсең, аның хәтере какшаудыр, шуңа күрә ул еш кына чынбарлыктан читкә китә. Алай ярамый. Халидә ханымга сәламнәр! Әгәр дә бергәләшеп килсәгез, мин бик шат булыр идем. Хөрмәтләрем илә (имза). 24 / 9 – 67 г.»*

**Батулла аңлатмасы:** Заһидә ханым затлы нәселдән чыккан Хәмит Төхфәтуллин турында яза. Кабып алгач, ул гаугачан, конфликтлар холыклы кешегә әйләнә. Язучы Әдһәмова Сәрвәр – язучы Кави Нәҗминең хатыны. Чыннан да, Кәрим Тинчуринны театрдан кууны оештыручылар арасында артист Хөсәен Уразиков та актив катнаша. Тинчуринны Камал театрыннан куып, Әстерханга сөрәләр. Ул анда сигез ай дәвамында (бер театр сезоны) Әстерхан Татар драма театрында режиссер булып эшли. Заһидә Тинчурина Тинчуринның театрдан куылуы турында болайрак сөйли иде: *«Кәрим үзе пьеса яза, үзе баш рольләрне башкара, үзе режиссер. Куплэрнең эче поша, көнләшәләр, кызыгалар, донос язалар. Кәрим Тинчурин Әстерхан театрында тиз арада коллективның хөрмәтен яулый...»*

Менә аның Әстерхан театры артистлары белән төшкән рәсеме (1929 ел, 15 апрель). Рәсемнең артына артистларның Тинчуринга рәхмәт сүзе язылган:

*«Татар театрының җитәкчесе, атказанган артист Кәрим абый Тинчуринга! 28-29 нчы ел. Әстерхан Дәүләт татар драма театрында Сезнең кул астыгызда яшәү истәлеге итеп бирәбез. Без Сезнең өчен, шушы карточкадагы башка берәр исбат кылырлык нәрсә эшли алмавыбыздыр, әмма Сез үзегезнең сәхнә эшендә зур художник, оста режиссер һәм яхшы артист булганыгыз белән безгә, Сез безнең карашта онытылмаслык бер шәхес булып истә калачаксыз. Без 4-5 ай эчендә Сезнең кул астында ярдәмче көчләрегез булып эшләсәк тә, Сез үзегезнең белемегез, эш методыгыз белән тәҗрибәле булуыгыз һәм матур сәнгать эшендә безгә күп нәрсәләр өйрәтү, күрсәтүегез һәм Сезнең безгә мәгънәви зур ярдәмче булуыгызны әйтергә мәҗбүрбез. Аз вакыт булса да, Сезнең кул астында эшләү безгә мәктәп үтү белән бер булды. Сәхнәгә аяк басып эш башлаган Әстерханда Өлкә Татар драма театры ярдәмче көчләреннән: Ф.Баканов, Ә.Әхмәтшин, Х.Аитов, А.Ибраһимов. 15.04.1929».*

Фотосурәт «Универсальная фотография, Астрахань»да төшерелгән. Күрәсең, бу рәсем коллектив белән аерылышу вакытында төшерелгәндер. Тинчурин киткәч, академия театрының сукасы ташка терәлә. Куярга пьеса юк, режиссер юк, театрга халык йөрми, коллективта торгынлык башлана. Тинчуринны Әстерханнан кайтарырга карар кылалар. Театрга кайткач, Кәрим үзенә бөһтан яккан, шикаять язганнарга бер сүз әйтми. Әмма шул ук кешеләр аны тагын төрмәгә аткара. ■

# Нурихан Фәттах көндәлекләре

Нурихан Фәттах

*«Безнең мирас» журналын көтеп алып, бер җөмләсен дә калдырмый укып барам. Гыйбрәтле язмышлар, тарих... Журналның 8 нче (2021) санында галим Миркасыйм Госмановның көндәлегеннән язмалар басылган иде. Бу минем өчен кызыклы яңалык булды. 27 яшьлек М.Госманов Алтын Урда чорын өйрәнгән, 1962 елда Сарай-Бәркә хәрабәләрен казуда катнашкан икән. 1957 елда 29 яшьлек Нурихан Фәттах та Болгарда археологик тикшеренү эшләре алып бара. Мәскәү профессоры, тюрколог А.П.Смирнов җитәкчелегендә җәй буе җир казый. Тарихны күзе белән «күрә», кулы белән «тотып» карый, җитәкче сөйләгәннәрне күңеленә сеңдерә. Туктаусыз фәнни китаплар уку, архивларда казыну, тырышлык бушка китми – бу иптәшләрнең берсе атаклы тарихчы-галим, икенчесе танылган язучы, тарихи романнар авторы булып китә.*

*Исәбем «көндәлек» темасын дәвам итү. Нуриханның кульязмалары үзе исән чакта ук ИЯЛИгә тапшырылган иде, калганнарын күптән түгел генә дәүләт архивына тапшырдым, көндәлекләре әлегә үземдә саклана. Аннан соң мин үзем дә мәктәп елларыннан башлап көндәлек язам. Шуңа күрә, Нуриханга кагылышлы үзем язган фактларны да өстәсәм, укучы гаеп итмәс дип уйлыйм.*

***Руфинә Фәттахова***

***3 октябрь, 1988 ел***

Күптән инде көндәлек язган юк. Кайчакта язасы килә. Зур үзгәрешләр, яңалыклар бар дөньяда. Бүген иртән радиодан 5 минутлык сүз сөйләдем. «Болгармы, татармы?» – дип, «татар» атамасын «болгар»га алыштырырга кирәк дип шау-шу куптарганнар кайберәүләр. Мин каршы. Нәшриятта булдым. Якладылар – Рәис Даутов, Гәрәй Рәхим, Р.Мөхәммәдиев һ.б.

***6 октябрь, 1988 ел***

Кичә Союзда Г.Рәхим янында булдым. Ул секретарь исәпләнелә. Юбилей кичәсе 11 ноябрьдә Академия театрында (искесендә) булачак. Концерт турында сөйләштек. Магазиннарда аракы юк. Мәҗлес җыйсак, барыбер аракысыз булмый, каян табарга?.. Алфавитның яңа вариантына каршы Иҗтимагый үзәккә хат язам әле. Мәкалә бастырырга җай юк, юл бикле. Бернәрсәне дә бастырмыйлар.

***9 октябрь, 1988 ел***

*(Бу өзек тулаем минем көндәлектән. – Р.Ф.)*

*Ял көн. Нуриханның иҗаты турында радиодан бер сәгатьлек тапшыру булды. Ибраһим Нуруллин, Фәрит Хатыйпов сөйләде, ялыктыргыч, коры мактау шунда. Ирек Баһманов романнан өзек укыды, 10 минутлап, ярый инде. Ринат Таҗетдиновның «Кол Гали»дән монолог укуы гына җанландырып җибәрде. Гомумән алганда, сценарий уйланылмаган, ашык-пошык әзерләнгәнме, тапшыру сүлпән, күңелсез тәэсир калдырды.*

***14 октябрь, 1988 ел***

Кичә Руфинә белән яхшырак азык артыннан йөрдек (банкет өчен). «Советская Татария» (хәзер «Республика Татарстан». – *Ред.*) газетасыннан студент Рифат Фәттахов килде. Аның интервьюсын укып чыктым, хаталарын төзәттек.

***16 октябрь, 1988 ел***

Гомәр абый радиодан бик төпле, һәркем аңларлык итеп татарны «болгар» дип атауга каршы сөйләде.

***20 октябрь, 1988 ел***

Китап чыккан. «Сызгыра...». 2 нче китап.

***21 октябрь, 1988 ел***

Р.Харистан котлау телеграммасы килеп төшкән. Конвертка салып кире җибәримме дип уйлаган идем: «Вакланма», – диде Руфинә. *(Бу урында кечкенә аңлатма кирәк булыр. 1984 елда Мәскәүдә «Наука» нәшриятында Равил Фәхретдиновның «Очерки по истории Волжской Булгарии» дип аталган фәнни монографиясе басылып чыга. Равил 1986 елның 21 декабрендә аны Нуриханга бүләк иткән. «Хөрмәтле Нурихан абыйга зур ихтирам белән, үз итеп!» – дип язган. Тиражы – 3500 данә. Шушы китапка Нурихан бик тәфсилләп уңай рецензия яза, аны «Казан утлары»на илтеп бирә. Ул вакытта Нурихан редколлегиядә дә була. Ренат Харис – редактор. Ни сәбәптәндер, редактор рецензияне бастырудан баш тарта. Моңа каршы Нурихан «Сызгыра торган уклар»ның инде басарга әзер икенче китабын «Казан утлары»ннан кире ала. Шулай итеп, рецензия дә, китап та басылмый, гонорар да юк, ике арада озакка сузылган дошманлык кына*

*кала. – Р.Ф.)* Апрельдә съезд булачак, диләр. Шунда югары үрләмәкче була. Минем каршы чыгачакны сизенә.

Радио өчен алфавит турындагы мәкаләне тәмамладым, машинкада басасы гына калды.

***25 октябрь, 1988 ел***

Бүген миңа 60 яшь тулды дип исәпләнелә. Өченче көн «Советская Татария»дә Рифат белән булган интервью чыкты, фотосы да бар. Руфинә күлмәк бүләк итте. Көн коры, салкынча. Дөнья үз көенчә бара, без генә картаябыз.

***27 октябрь, 1988 ел***

Кичә Союзда булдым. Юбилейлар ыгы-зыгысы белән йөрим. Фаил Шәфигуллинның 50 яшьлек юбилеен уздыру комиссиясенә сайлаганнар. Мәгъсум Хуҗин, Эльмира, Гәрәй Рәхим һәм мин. Гәрәй Мәскәү кешеләре белән чыгып китте. Майда Фаилгә 50 тулган булыр иде. Ничегрәк уздыру турында сөйләшәбез, киңәшләшәбез һ.б.

***30 октябрь, 1988 ел***

Кичә радиодан русча тапшыруда болгар-татар темасын сөйләдем. Айрат Арсланов «Әтил...»дән өзек укыды. Сәгать 4тә Иҗтимагый үзәктә җыелыш булды. Бауманда. Политмәгариф йортында. Халык шыгрым. Союздаш республика сорыйлар. Шуннан Руфинә белән Гөлсем Исәнгулова банкетына киттек. «Болгар» ресторанында булды. Мин тиле кебек сикердем, ягъни биедем дип атала. Күңелле булды.

***31 октябрь, 1988 ел***

Кичә радиодан сөйләгәнне «Социалистик Татарстан»га яздым. Аларга бик бирәсе дә килми иде, бирми дә ярамый – мәсьәлә бик җитди. Бу арада кунаклар чакырып мәш килдек.

*(Бу өзек минем көндәлектән – Р.Ф.) Бүген радиода сәламәтлек темасына тапшыру яздырып кайттым. Искәрмә: ул елларда табиблар арасында татарча әңгәмә үткәрерлек кеше калмаган да иде бугай. Профессураны әйткән дә юк. Телевидениегә чакырсалар да, медицина турында татарча сөйләү хакында башларына да китермиләр иде. Ярты сәгатьлек тапшыруга айлар буе әзерләнә идек. Мидхәт (М.Миншин, Иҗтимагый-сәяси тапшырулар редакциясенең баш редакторы. – Ред.) әйтә: «Бүген көне буе Нурихан абыйның кичәге чыгышы турында сүз бара. Нурихан абыйның юбилее, макталулары актив рәвештә, конфликтлы ситуациядә бара. Болгар-татар турында һәм алфавит турында сүз бара. Икесе дә бигрәк принципиаль шул, әйтәсе дә юк», – ди.*

***1 ноябрь, 1988 ел***

*(Бу өзек минем көндәлектән. – Р.Ф.)*

*Нуриханның алфавит турындагы мәкаләсен «Социалистик Татарстан»га илтеп бирдем. Шәех Зәбировка. (Алга китеп, шунысын өстәп куярга кирәк: декабрь урталарында Роберт Батулланың миниатюралар спектаклен карарга баргач, Шәехне очраттык без. Җыларга җитешеп гафу үтенде. «Мәкаләңне бастыра алмадык, зинһар, гафу ит», – ди, Нуриханның кулларын үбә...)*

***7 ноябрь, 1988 ел***

Кичә төш вакытында Нил (Н.Юзиев – күренекле галим. – *Ред.*) килеп керде. Әлерәк кенә Бакудан кайткан. Кичәдә доклад ясау аңа тапшырылган иде. Шул хакта сөйләшергә килгән. Төрле даталарны, фактларны ачыклау өчен. Ул чыгып кына киткән иде, Рәис Сафиуллин килеп керде. Дербышкида ансамбль җитәкчесе. Кичәдә чыгыш ясарга әзерләнәләр икән. Кызым Чулпан 3-4 ел инде шунда хорга йөри. Кичәгә чакыру билетлары алып китте. Кичкә таба авылдан Әминә килеп төште. Мәскәүдән тимерьюлчылардан чакыру килгән.

**Нурихан Фәттах капка янында**

***11 ноябрь, 1988 ел***

Тантаналы кичә узды. Халык тулы. Президиумда Мансур Хәсәнов, Марсель Таишев, өлкән язучылар утырды, гадәттәгечә. Кызыл җәеп. Котлаулар күп булды. Республика библиотекасыннан тузып-таушалып беткән «Сезнеңчә ничек?»не бүләк итте Разил һәм миңа багышланган шигырен укыды. Разилгә шаулатып кул чаптылар. Роберт Миңнуллин да чын күңелдән язылган шигырен салмак тавыш белән халыкка җиткерде. Яшьләрнең ихтирамы күңелгә сары май булып ятты. Җыелышны Гәрәй алып барды, концертны – Батулла. Әлмәтлеләр «Сармат кызы Сәринә»дән өзек күрсәттеләр, «Сорнай», университеттан «Каз канаты» – бию, Рәшит Сабиров «Пулат»тан өзек укыды, тамашачылардан сорау-җавап оештырган Батулла. Күңел күтәренке! Группадашлар Гарәф, Фатыйх, Сәгадәтләр, танышлар күп килгән. Сәхнәдән барысы да күренә. Соңыннан чын бәйрәм булды, рәхмәт, дип, танышлар да, таныш түгелләр дә кулны кыстылар, хәтта халык та тиз генә таралышмый торды.

***12 ноябрь, 1988 ел***

Көндез туган-тумача, танышларны балалары белән кунакка җыйдык. Ыгы-зыгы килделәр. Төштән соң бер майор килеп керде. Бөтенләй көтмәгәндә улыбызга армиягә китәргә повестка алып килгән. Срочно, бүген үк военкоматка килсен, диде. Әнисе: «Егет кеше бит, соң кайтырга мөмкин», – ди. «Көтәрмен», – диде.

*(Бу өзек минем көндәлектән. – Р.Ф.) Алмас, эштән кайту белән, ашамый-нитми, военкоматка чыгып йөгерде. 16сында китәм армиягә, Братск шәһәренә, диде.*

***13 ноябрь, 1988 ел***

Кичә кич Татар ашлары йортында зурлап банкет уздырдык, 60 кеше булды. Оештыру, тәртип белән алып бару мәшәкатьләрен тулаем Батулла башкарды. Туктаусыз мактау, ихтирам, чәчәкләр, китап таратулар, уен-көлке һ.б. «Җылы, ихлас булды, чын күңелдән бәйрәм иттек», – диделәр кунаклар, таралышканда.

***16 ноябрь, 1988 ел***

Алмас, иртүк торып, портфелен күтәреп военкоматка китте. Озаттырмады. Мин 18енә Мәскәүгә китәргә ике билет алып кайттым (юбилей уңаеннан очрашуга. – *Ред.*). Равил Фәхретдинов та чакырулы икән, димәк, өчәү бергә китәбез.

***22 ноябрь, 1988 ел***

Бүген иртән «Татарстан» поезды белән Мәскәүдән кайтып төштек. Мәскәүдә татар активистлары каршы алдылар. Руфинә белән мине – Фирдәвес Вафин дигән кеше, Равилне Шамил исемле бер иптәш үзләренә алып китте. Фирдәвес институтта теоретическая механика укыта икән. Доцент. Хатыны Рөхсәнә исемле. Шул кичне үк Нур Гарипов исемле өлкән яшьтәге бер кешенең шәһәр читендә урнашкан квартирына кунакка алып киттеләр. Мәскәүнең татар активистлары, галимнәре җыелган иде. Төрле сораулар, бәхәс, җиңелчә шаяртулар, бай табын…

*(Бу өзек минем көндәлектән. – Р.Ф.) Миңа иң нык тәэсир иткәне җыелган хатыннарның алтын-көмеш белән чуарланган киемнәре дә, затлы табын да булмады. Аларның «туган көн мәҗлесе» дигәннәре дә бер сәбәп кенә булды шикелле, чөнки хуҗа бабайны котлаучы да булмады. Нуриханга мәҗлес башлану белән сорау артыннан сорау яудыра башладылар. Әллә нинди фәнни конференция дип әйтимме, докторлык диссертациясе яклауга да охшаш иде ул мәҗлес. Баштарак Нурихан каушамасмы, сорауларына җавап бирә алырмы дип, котым очып утырдым. Юк, каушамады, елмая төшеп, бөтен сорауларына кыскача, ниндидер төгәллек белән, колак ишетмәгән кытай фамилияле авторларга таянып, җавабын тезде генә. Әйтерсең, профессор студентларга лекция укый… Күккә чөеп мактаулар, тапкыр сүзләр, көлешүләр, музыка табын җанлана төшкәч башланды.)*

***

Икенче көнне Тимерьюлчылар профсоюзының III Интернациональ исемендәге клубында очрашу булды. Мин кыскача гына берничә генә сүз сөйләдем дә «котылдым». Равил русча сөйләде. Тарих, Болгар турында. Аңа сорауларны бик күп яудырдылар. Мәскәүлеләр бик актив, усал, бугазыңнан алырга торалар. Үзләренең культура сарайлары, җыелыр урыннары юк икән, бирмиләр, ди. Икенче көнне кич тагын кунакка алдылар. Зөфәр Сәхәбиев дигән кеше кайсыдыр техникумда татарча фольклор ансамблен җитәкли икән. Шуларда кунак булдык. Өченче көнне кибетләрдә йөрдек, күп кенә китаплар алдык. Пушкин музеенда Мисыр сәнгате күргәзмәсенә керәсе килгән иде, булмады, дүшәмбе туры килде – музейлар ул көнне ял итә. Шаһинур Мостафин да Мәскәүдә булган. Ул архивларда казынып йөри икән. Бик күп татар батырларын тапкан инде. Татар дуслар бик зурлап озаттылар, әйберләр кулга да тимәде. ■

Безнең мирас №2 февраль 2022



# Әхмәт Гадел шигырьләре

**Шагыйрь Әхмәт Гадел (1942-2012).**
**1 февраль, 1982 ел.**
***Мидхәт Шакирҗанов фотосы***

## *Атлар килә*

Томырылып атлар килә чабышта...
Һай көчлеләр, мәһабәтләр, горурлар!
Уч төпләре яна, яна алкыштан,
Зур бүләкне кемнәр генә алырлар?!

Атлар килә... Дөп-дөп итә йөрәкләр,
Канатлана колгадагы сөлгеләр;
Кайсы егет чаптарының муенына
Кайсы гүзәл чиккән сөлгесен эләр?!

Атлар килә... Тояклары көмештән!
Атлар килә ерак дала ягыннан.
– Атлар килә! – Батыр белән көрешкән
Яшь кызларның бит алмасы кабынган...

– Атлар килә! – Күтәрелде гөр, мәйдан;
– Кемнәр җитез, кемнәр өлгер, күрегез!
Сабыр, заман! Ярыш-көрәш башлана,
Әкренләп ныгый төшә билебез.
Кайбер юрга кебек, азак китеп, без
Иң элгәре, бәлки, әле килербез!

## *Җавап*

Кададыгыз йөрәккә,
Чәнчедегез бәгырьгә.
Түзә алмас дидегезме,
Ошбу татар җәбергә?!

Кылычын да күргәнбез,
Сөнгесен дә күргәнбез,
Гасырларда исән калып,
Явызларны күмгән без!

Нахакка да түзәрбез,
Яманга да түзәрбез,
Дуслар хыянәт итсә,
Без араны өзәрбез.

**Әхмәт Гадел газиз оныклары белән.** *1990 нчы еллар уртасы*

# Су буенда каурый җыйган малайга

Көньякка чакыра тавышы казларның,
Талпына күңелем, уктала томанга...
Моң тулы уйларым эзлидер язларын,
Канатлы төркемнән кайгырам калганга.

Аһ, казлар төркемен чакрымнар төтене
Йотадыр, йотадыр... Мин калдым...
Ук сыман уйларым ясыйдыр туйларын,
Уй күктә ук сыман, җирдә тик суларым...

Яр буен иңлимен, очарга телимен,
Йә, ә син бирегә ник килдең?!
Рәхәттән туепмы, сагыштан оепмы,
Һәй, олан, яр буйлап син йөрдең.

Җыйма, һәй, каурыйны, каурыйда – күз моңы,
Кошларның аһ-зары каурыйда бер оя...
Каурыйда – салкын җил, кошларның шаукымы,
Үлемнең сулышын каурыйда җан тоя.

Хис, акыл, ике кул бирелгән кешегә.
Илләрне гизәрсең, кочарсың дөньяны.
Казларның каурые коелган – өшегән...
Куй, энем, каурыйны, җыйма һич, куй, җаным! ■

Безнең мирас №2 февраль 2022

# КАРА ТӘКЪДИР

*(Ачы язмышлы шәхесләр)*

**МОХТАРОВ КАШШАФ (1896-1937)**

Сәламәтлек саклау министры, Совнарком рәисе. 1896 елның 14 июлендә Казан губернасының Мамадыш кантоны (хәзерге Мамадыш районы) Тау Иле авылында игенче гаиләсендә туган.

Кашшаф Мохтаров, «буржуаз милләтчелек»тә гаепләнеп, 1929 елда кулга алына. 1931 елның 13 гыйнварында үлем җәзасына хөкем ителә, әмма соңрак әлеге җәза унъеллык каторга белән алыштырыла. 1937 елның 27 октябрендә аңа карата яңадан атарга дигән хөкем карары чыгарыла һәм ул Карелиядә – Сандармохта гамәлгә ашырыла.

**МӨЛЕКОВ СӨЛӘЙМАН (1920-1941)**

Татар шагыйре. 1920 елның 5 гыйнварында Татарстанның Балтач төбәгендәге Пыжмара авылында туган. Украинада чик сакчысы булып хезмәт итә.

1941 елның сентябрендә ул Киев өчен барган каты сугышта батырларча һәлак була.

**НИГЪМӘТИ ГАЛИМҖАН (1897-1941)**

Татар әдәбияты тәнкыйтьчесе. 1897 елның 26 июлендә Башкортстандагы Чишмә төбәгенең Үдрәкбаш (Өйдерәкбаш) авылында ярлы игенче гаиләсендә туган.

Галимҗан Нигъмәти 1937 елда ялган шаһитләрнең күрсәтмәсе нигезендә кулга алына һәм 1938 елның 4 ноябрендә атып үтерелә.

---

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

## НӘҖМИ КАВИ (1901-1957)

Татар язучысы. 1901 елның 15 декабрендә Сембер губернасындагы Кызыл Утрау (Кызыл Атау) авылында ярлы игенче гаиләсендә туган.

Кави Нәҗми 1937 елда кулга алына. Бер ел төрмәдә утырганнан соң ирекккә чыгарыла. 1957 елның 24 мартында вафат була.

## РАХМАН ХӘБРА (1914-1942)

Татар язучысы. 1914 елның 26 ноябрендә Татарстанның Балтач төбәгендәге Яңгул авылында ярлы игенче гаиләсендә туган.

Ул Икенче бөтендөнья сугышында – Калинин фронтындагы бәрелешләрнең берсендә батырларча һәлак була.

## РӘСҮЛИ ЗӘЙНУЛЛА (1833-1917)

Ислам дине белгече. Ишан. Мәгърифәтче. 1833 елда Оренбург губернасына караган Шәриф авылында мулла гаиләсендә туган.

Зәйнулла Рәсүлев, шовинистлар тарафыннан эзәрлекләнеп, ун ел сөргендә иза чигә.

Зәйнулла хәзрәт 1917 елның 2 февралендә вафат була.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

# «Болай ук булыр дип уйламаган идем...»

**Фәрдия Сәфәргалиева,** Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

**Илдар Юзеев каләмдәше Шамил Рәкыйпов белән**

Илдар Юзеев... Әлеге исем гомерем буена озата килә икән бит! Әле аның исемен дә белмәгән вакытта ук җырларын җырлый идек бит без. Туган авылым Урта Бирәзә клубында авыл үзешчәннәре оештырган концерт-кичәләр, спектакльләрнең зал тутырып тамашачы җыйган чаклары... Залга сыймаганнар тәрәзә-ишектә булырлар иде. Бөтен дөньясын онытып, авызын ачып карап утыручы абый-апаларны күреп үстек без. Кичке тамашаларга кертмәскә бик тырышсалар да, җаен таба, барлык чараларда да була идек. Казаннан килгән артистларны да күрдек, тыңладык. Ата-аналарыбызның «Кыз урлау», Арча педучилище студентлары куйган «Зөбәйдә адәм баласы» һәм «Таныш моңнар» спектакльләрен дә онытылып, барысына сокланып карый идек... Наласа авылы үзешчәннәре спектакльләре барышында җырланган җырларга кадәр хәтердә: «Хәмдиянең ак калфагы яңа каралган чагы... Хәмдиягә сүз әйтмәгез, зиһене таралган чагы...» Истә калганнардан «Таныш моңнар» Илдар Юзеевныкы булган бит!

Сәхнәдә барган вакыйгалар шулкадәр тәэсир итәләр иде ки, «артистлар» борчылганда борчылып, мәхәббәт хисеннән өзгәләнгәндә ярдәм итәргә тыры-

шып утыра идек. Сәхнәдәге геройларның тормышта да шундый моңлы, хисле, матур булуларында һич шигебез булмады... Кыскача әйткәндә, «Дөнья матур, дөнья киң» чаклар...

Башлангыч мәктәптә укыган 60 нчы еллар. Арча педучилищесы студентлары куйган «Таныш моңнар» спектакле бигрәк тә истә калган. Без инде аны караганда спектакль вакытында яңгыраган барлык җырларны да белә идек. Шигъри телдә сөйләшсәләр дә, барысы да аңлаешлы булды. Резидә ролендә минем туганнан-туган апам – Сания Фәйзрахманова (аның авылыбыз мәктәбендә практикада булган вакыты). Өстендә ак борчаклы зәңгәр күлмәк. Зөфәрнең: «Резидәкәй, зәңгәр күлмәгеңне нинди елгаларда чайкадың?» – дип җырлаган чагында: «Күлмәге ник зәңгәр түгел, ник ак борчаклы зәңгәр күлмәк киде икән Сания апа?» – дип уйлаганым хәтердә. Ничек туры китергәннәрдер, зифа буйлы, дулкынланып торган озын чәчле апамны моңлы тавышлы, чибәр тракторчы егет Зөфәр ярата иде. Аларның кавышуга кадәр кичергән уй-кичерешләре дә шулкадәр табигый булды.

Билгеле инде, ул вакытта «Таныш моңнар» спектакленең Илдар Юзеев поэмасы буенча сәхнәләштерелүен дә белми, авторлар турында уйламый да идек. Үзеннән-үзе барлыкка килгән кебек иде спектакльләре дә, җырлары да. Резидә һәм Зөфәрнең җырлары егет-кызларның үз йөрәкләреннән чыккан җырлар кебек кабул ителде... Җыр авторларына, композиторларга соңрак игътибар бирелде. Әлеге җырларның сүзләрен дә шагыйрь Илдар Юзеев иҗат иткәнен белдек.

Аның бик күп җырлары яшь чактан ук тормышта юлдаш булды: «Төнбоек», «Яшь наратлар», «Кайтам инде», «Янар чәчәк», «Фәүзия җыры», «Лира җыры», «Сине уйлап янам», «Бөркет турында баллада», «Мәтрүшкәләр», «Кыр казлары артыннан»...

Гыйнвар – әдәбият, сәнгать дөньясына Илдар Юзеевны биргән ай. Тирән фикерле шигырьләр, күпсанлы поэмалар, хәтердә уелып калырлык җыр сүзләре авторы Илдар ага Юзеев күңелемдә тыйнаклыкның иң камил үрнәге буларак саклана. Әйе, мин Илдар абый белән шәхсән таныш идем. Танышлыгым шуннан гыйбарәт: Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясендә эшләгән елларымда Илдар абыйны «Таныш моңнар, таныш исемнәр» циклыннан булган әдәби-музыкаль кичәләргә, бигрәк тә Г.Тукайның, И.Шакировның туган көннәренә багышланганнарына чакыра идем. Соңрак шул кичәләрнең берсен, Илдар Юзеевның юбилее якынлашып килүе сәбәпле, аның иҗатына багышларга булдык.

2002-2003 нче еллар... Концерт сезоны башланган чак. Бөтенләй уйламаганда: «Иҗат кичәгезне уздырыйк», – дисәм, шатланыр инде дип, Илдар абыйга шалтыраттым. Әмма башкарачак килеп чыкты: «Юк-юк, миңа болай да уңайсыз, районнарда да уздыралар, бик артыкка китә. Туган ягымда да узды, кирәкми, җитәрлек булды инде», – диде ул... Ничек кенә күндерергә тырышсам да, ризалыгын ала алмадым. «Алай килешми. Юбилей дип шапырыну була», – диде Илдар абый, сүзне тәмамларга теләп. Аннары, аптырагач: «Шигырьләрегездән, Сезнең сүзләргә язылган җырлардан торган әдәби-музыкаль кичә уздырырга хакыбыз бардыр бит инде безнең, Илдар абый?!. Сез моңа каршы килә алмыйсыз бит инде...» – дидем, тәмам өметем өзелә дигәндә... «Анысы шулай инде, уздыра аласыз инде...» – дип куйды Илдар абый. Миңа шул җитә калды: «Илдар абый, менә шул кичәгә тамашачы буларак килүегезне үтенеп сорыйм», – дидем, шатлыгым күңелемне биләп алган халәттә.

Соңрак, кичәнең яңа җыр белән тәмамлануы ачыклангач, Илдар абыйны җырның беренче башкаручысы янына сәхнәгә чыгарга күндердем…

Зал тулы тамашачы ул кичне Илдар Юзеев шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар моңында гизде. 2002 елның 17 октябре иде ул. Кичә матур узды. Флера Сөләйманова *(«Төнбоек» – Л.Айтуганов көе; «Серле чәчәк», «Таң кызы» – М.Яруллин көйләре)*, Рабига Сибгатуллина *(«Сине уйлап янам» – С.Ибраһимов көе; «Кайтам инде» – С.Садыйкова көе)*, Айдар Фәйзрахманов *(«Гармун» поэмасыннан өзек; «Чит илләргә чыксам» – С.Садыйкова көе)*, Фатыйма һәм Мәсгут Имашевлар *(«Туган ягым каеннары», «Шәмсенаһар мәчете», «Кыр казлары артыннан», «Гашыйклар тавы», «Хуш, исән бул, Яңавыл» – М.Имашев көйләре)* Люция Хәсәнова *(«Яшьлек дустыма» – М.Яруллин көе)*, Фердинанд Фәтхи *(«Хуш инде» – Ф.Мортазин көе; «Ике егет китә армиягә» – Радик Яруллин көе)* һәм Илнар Нуриев *(«Зөфәр җыры» – Ш.Мәҗитов көе; «Яралы кош» – М.Имашев көе)* башкаруында җырлар яңгырады. Мин, алып баручы буларак, җырлар арасында Илдар Юзеев шигырьләрен укыдым.

Кичәгә әзерләнгәндә Илдар абыйның «Казан утлары» (№1, 2002) журналында чыккан яңа шигырьләренә дә игътибар иттем. Берсе бигрәк тетрәндерде:

*«Чәчләр агарды дип мактаналмыйм,*
*Ап-ак калалмады күңел дә.*
*Күп хыяллар, чынга ашалмыйча,*
*Югалдылар өмет күгемдә.*

*Сафлык калса әгәр бу җанымда –*
*Саклап калды аны җыр гына.*
*Гомеремнең соңгы тамчыларын*
*Көйгә салган чагым тын гына...»*

Моңа каршы күңелемдә шигырь юллары туган иде, оялып кына, аларны сәхнәдә укыдым:

*«Гомеремнең соңгы тамчылары...»*
*Шушы сүзләр шигыреңә кергән...*
*Илдар абый, синең йөрәгеңә*
*Сокланырлык якты моң иңгән.*
*Телдән-телгә күчә шигырьләрең,*
*Җырларың да тынмый җырлана.*
*Синең моңлы шигырьләрең аша*
*Күңелләр күңелгә ялгана.*
*Илдар абый, сөенергә язсын*
*Туар көннәрең шатлыгына,*
*Гомереңнең гүзәл мизгелләрен*
*Көйгә салып йөрче тын гына!*

Кичә тәмамланып саубуллашканда шигырь язылган дәфтәр битен Илдар абыйның пиджак кесәсенә салдым…

Кичәне Фәрит Хатыйповның Илдар Юзеев сүзләренә язылган «Син кайчан кайтырсың?» җыры белән тәмамладык. Әлеге җырның тәүге тапкыр яңгыравы

«Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән...». 12 апрель, 2002 ел









«Таныш моңнар, таныш исемнәр». Рәсемдә (уңнан): Фәрдия Сәфәргалиева, Нәҗип Бәдретдинов, Илдар Юзеев, Фердинанд Фәтхи, Флера Сөләйманова, Фәрит Хатыйпов, Мәсгут Имашев. 17 октябрь, 2002 ел

иде бу. Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты студенты Гүзәл Галләмова аны күңелләргә үтәрлек итеп башкарды. Җыр ахырында, алдан сөйләшеп куелганча, залдан сәхнәгә Илдар абый күтәрелде... Тамашачы аны озак алкышлады. Ә мин: «Илдар абый, менә бу чәчәкләрне алдан ук сәхнәдәге журнал өстәленә куйган идем. Илдар Юзеев иҗатына гашыйк тамашачыларыбызның җылы күз карашлары иңсен дип уйладым. Инде менә шушы ак чәчәкләрне мин Сезгә тапшырам», – дип, Илдар абыйның кулына ап-ак чәчәкләр суздым.

Илдар Юзеев

Тамашачы, аягүрә басып, халык шагыйре Илдар Юзеевны көчле алкышларга күмде. Кичә бик матур, җылы булды. Бергәләп сәхнә артына чыгып барганда: «Болай ук булыр дип уйламаган идем...» – диде миңа Илдар абый. Моннан да зур бәя була аламыни?!. Илдар Юзеев сүзләре бит ул! Миңа тагын да тырышып иҗат итәргә, тагын да матуррак кичәләр уздырырга көч өсти торган сүзләр!

Бу көннәрдә ярый әле үзе исән чагында олуг шагыйребезгә хөрмәтебезне җиткерә, иҗат җимешләренең безгә никадәр кирәкле икәнен аңлата алдык дип уйлап йөрим.

2004 елның 17 апрелендә Илдар Юзеевны Ләбиб Айтугановны искә алу кичәсенә чакырдык. Сәхнәдә чыгыш ясаганда ул Ләбиб Айтуганов белән «Карлыганым-бөрлегәнем» дигән беренче җырын иҗат итүләре турында да сөйләде.

Илдар абыйның мондый кичәләребезгә соңгы килүе булган... 2004 елның 21 декабрендә ул арабыздан китеп барды...

Мин Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында әдәби бүлек мөдире булып эшләгәндә (2005-2011 нче еллар), 2010 елның 3 декабрендә Илдар Юзеевның «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз» дигән әсәре буенча спектакль куелды.

Репетицияләр вакытындагы төп вазыйфам – сәхнәдә яңгыраган һәр җөмләне тикшереп, авторның сөйләм теле саклануына игътибар итү булса, эчтән генә: «Илдар Юзеев сөйләме бозылмаса ярар иде, юморы да аныңча үткен, әмма ягымлы булсын иде», – дип утырдым...

Илдар абый исән булса, һичшиксез, театрга килеп, тыйнак кына елмаеп утырган, шатланган булыр иде, ошатыр иде, дип, юксыну катыш куандым...

Сәхнәдә – музыкаль комедия... Барысы да – үз урынында, барысы да – заманча, барысы да – режиссер, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ренат Әюповка хас җиңеллектә, тизлектә. Тамашачы хозурында Г.Кариев театрының талантлы артистларының ихлас, халык игътибарын тулаем җәлеп итә торган уены. Күңел, спектакльдә тасвирланган вакыйгаларга ияреп, рәхәтлек кичерә, чөнки анда уены-чыны белән бергә үрелеп барган саф мәхәббәт хисе, ата-ананың баласына булган эчкерсезлеге, борчу-хәсрәтләре, өмет-ышанычлары гәүдәләндерелә. Матур комедия. Җанның шушындый сәхнә әсәренә сусаганлыгын спектакль тәмамланганнан соң да һаман колакта яңгыравын дәвам иткән шаян сүзләр, көйләр раслый, колакта артист Марсель Мәхмүтов башкаруындагы «Бөркет турында баллада» яңгырый... Күз алдына кабат-кабат сәхнәдә барган выкыйгалар килеп баса. «Шулкадәрле ышандырырлык итеп уйнарлар икән!» – дип уйлап куясың артистлар турында. Аларның һәрберсе – Баязит ролендәге Марсель Мәхмүтов, аның хатыны Зөлфияне уйнаган Гөлнур Шиһапова, Гөлүс белән Нәзнинә образларындагы – Г.Кариев театрында әле икенче генә сезон эшләүләренә карамастан, үзләрен тырыш, эзләнүчән артист итеп таныткан Рушан Фәхертдинов белән Гөлназ Якупова, Миңнурый ролендәге Рәмзия Закирҗанова, Әбүзәр образындагы Илнар Низамиев, артист Варисны уйнаган Алмаз Гыйльметдиновлар – бу көнне барысы да «ялтырадылар». Әйтерсең лә, һәммәсе дә рольләрен зарыгып көтеп алганнар да тамашачы алдында уздырылачак һәр мизгелнең тәмен тоеп калырга омтылалар иде. Премьера көнне һәрберсе, үз образын матур-матур бизәкләр белән шәрехләп, сәхнәдән нур чәчте. Спектакль барышында башкарылган аерым-аерым җырлар да, дуэтлар да күңелне җәлеп итте. Илдар Юзеев «теле» сокландырды...

Сәхнә бизәлешенә килгәндә, беренче карашка гади генә декорация кебек тоелган, әллә ни искитәрлек булмаган фатир күренеше, спектакльнең төп идеясенә туры килеп, комедиянең башыннан ахырына кадәр гел үзгәрештә булды. Ир белән хатын аерылырга мәҗбүр булгач, тәрәзәләрен узып барган поезд утлары яктырткалаган ятим ояны да, кавышырга планнар корып йөргән яшьләрне киләчәккә, хыялга таба алып барган поездны да, әсәрнең барлык геройларын кабат бер урынга җыйган ишегалдын да хәтерләтте ул. Ә фатирның поезд гөрелтесеннән бер ачылып, бер ябылып торган ишекләре биредә – шушы ыгы-зыгыда гомер кичергән фатир хуҗаларының тормыш авырлыкларына бирешмичә бер-берсен яратып яшәүләрен искәртеп торды.

***

Илдар Юзеев иҗатына кат-кат әйләнеп кайтылыр әле, дигән идем, шулай булып чыкты да. Инде байтактан лаеклы ялда булсам да, Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе җитәкчеләре ара-тирә чакыргалап, иҗат эшчәнлегемне искә алып тора. Быелгы концерт сезонында башланып киткән «Галиҗәнап шагыйрь» дигән кичәләрнең берсе Илдар Юзеев иҗатына багышланды. Филармония директоры Кадим Назыйр улы Нуруллин әлеге кичәгә сценарий язуымны сорады. Кабат Илдар абый Юзеевның тылсымлы иҗатына чумдым...

Тормыш дәвам итә! Илдар абыйның үз сүзләре белән әйтсәк:

*«Авырлыклар, сабырлыклар белән*
*Яшәү барыбер кызык!»* ■

Безнең мирас №2 февраль 2022

# Истә, һаман да истә!

## *Шагыйрь Әхмәт Гаделнең туууына 80 ел*

Шагыйрь, прозаик һәм публицист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1992), Башкортстанның Ф.Кәрим исемендәге әдәби бүләге иясе Әхмәт Гадел (Әхмәт Мөхәммәтһади улы Гаязов) 1942 елның 2 февралендә Татарстанның Мамадыш төбәгендәге Ак Чишмә авылында туган.

Төп басма китаплары: «Яшьлегем былбыллары» (1985), «Серле күпер» (1990), «Дәрт» (1993), «Йолдызлы чат» (2000), «Рух бәйрәме» (2002), «Еракта, томаннар артында...» (2007).

Ә.Гадел 1912 елның 13 ноябрендә Казанда вафат булды. Җәсәде Балык Бистәсе районының Зур Мәшләк авылы зиратында җирләнде.

## *Актриса Рәйсә Гобәйдуллинаның туууына 110 ел*

Актриса, ТАССРның халык артисты (1968) Рәйсә Гобәйдулла кызы Гобәйдуллина 1912 елның 12 февралендә Казан губернасының Чистай өязендәге Яңа Кади авылында туган. 1934 елда ул Театр сәнгате техникумының театр бүлеген тәмамлый.

1934-1937 нче елларда – Татар эшче театрында, 1937-1949 нчы елларда – Мамадыш колхоз-совхоз театрында, 1949 елдан исә Әлмәт татар драма театрында эшли. Әлеге театр сәхнәсендә Р.Гобәйдуллина башкарган кайбер рольләр: Гөлгөл («Гөлмәрфуга», И.Абдуллин), Саҗидә («Ана бәхете», Ш.Шаһгали), Фатыйма («Бөдрә тал», Г.Минский) һ.б.

Р.Гобәйдуллина 1997 елның 22 гыйнварында Әлмәттә вафат булды.

## *Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның туууына 80 ел*



Шагыйрь, публицист, 1978 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Кадыйр Сибгатуллин (Минкадыйр Идиятулла улы Сибгатуллин) 1942 елның 15 февралендә Татарстанның Балык Бистәсе районындагы Балыклы Чүкәй авылында дөньяга килә. Кече Укмас, Яншык һәм Олы Солтан авылларының мәктәпләрендә белем ала.

1974 елда Кадыйр Сибгатуллинның «Әманәт» дигән тәүге шигъри җыентыгы дөнья күрә. Шулай ук аның «Гамь» (1976), «Авазлар» (1981), «Хыял» (1986), «Инану» (1988), «Таңнар, кичәләр» (1989), «Гомерем дулкыннары» (1993), «Намазлык» (1994), «Әйтте шагыйрь» (2002) һәм «Бер ноктада» (2007) исемле шигырь җыентыклары да басылды.

К.Сибгатуллин 1994 елның 4 июнендә Чаллыда вафат булды.

## *Социолог Флюра Зыятдинованың тууына 75 ел*

Социолог, социология фәннәре докторы, педагог, җәмәгать эшлеклесе, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Дәүләт Думасының өченче чакырылыш депутаты, «Россия төбәкләре» депутатлар төркеме әгъзасы, Халыкара эшләр буенча комитет рәисенең урынбасары Флюра Газиз кызы Зыятдинова 1947 елның 18 февралендә Казанда туган.

1988-1992 нче елларда ул Укытучыларның белемен күтәрү институтында кафедра мөдире вазыйфасын башкара.

Ф.Зыятдинова 2011 елның 1 мартында вафат булды.

## *Рәссам Бакый Урманченың тууына 125 ел*

Рәссам, сынчы, график һәм педагог, ТАССРның һәм РСФСРның халык рәссамы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1967) Бакый (Габделбакый) Идрис улы Урманче 1897 елның 23 февралендә Казан губернасының Тәтеш өязендәге Күл-Черкен авылында (хәзерге Буа районы) туган.

1907-1914 нче елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала.

1929 елда репрессияләнә һәм Соловкига сөрелә. 1933 елда азат ителә.

Төп әсәрләре: «Сепаратор янында» (1928), «Татарстан» триптихы (1976, 1985), «Салтык болыны» (1979), «Сагыш» (1966), «Сания Кәримова портреты» (1968), «Тулпар» (1968), Г.Тукай мемориаль архитектура (хәзер – әдәби-мемориаль музей) комплексы (Арча, Кырлай, 1976).

Б.Урманче 1990 елның 6 августында Казанда вафат булды. Җәсәде Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнде.

## *Актер Роберт Әбүлмәмбәтовның тууына 80 ел*

Актер, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Роберт Шәрифҗан улы Әбүлмәмбәтов 1942 елның 25 февралендә Оренбург өлкәсенең Зиянчура районындагы Юлкотлы авылында туган.

Казан театр училищесен тәмамлаганнан соң (1966), ул Татар академия театры труппасына алына, күбесенчә музыкаль-драматик спектакльләрдә катнаша.

Роберт Әбүлмәмбәтов башкарган Хәлил һәм Бакый («Галиябану», «Ак калфак», М.Фәйзи), Газиз («Күк капусы ачылса», Х.Вахит), Амур («Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин), Витторио («Бәйрәм кичендә», Э. де Филиппо), Альфред («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Исәнбай («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт) рольләре тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителә.

Р.Әбүлмәмбәтов 1977 елдан – Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында директор урынбасары, 1984 елдан вафатына тиклем Татар драма һәм комедия театры директоры вазыйфаларын башкара.

Р.Әбүлмәмбәтов 2002 елның 27 апрелендә Казанда вафат булды.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

*Җуелмас хәзинә*

# «Вәгъдә» җыры

***«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».***

***Габдулла Тукай***

Тәртип радиосы

## Вәгъдә

*(Татар халык җыры)*

Таң атканда салкын чишмә буенда
Очраштык без иркәм белән тагын да.
Күктә болыт тулган иде,
Сандугач та тынган иде,
Без аерылып киткән чагында.

Вәгъдә биргәч, кирәк иде көтәргә,
Нигә инде мине моңсу итәргә?
Зәйтүн гөл чәчкәсе кебек
Яшьтән сөйгән үз ярыңны
Нигә инде ялгыз итәргә?

Вәгъдә биргәч, яшь егеткә дөньяда
Саф мәхәббәт, керсез күңел, хис кирәк.
Яшьтән өзелеп сөйгән ярың
Үз вәгъдәсен үзе бозгач,
Газапланып тибә яшь йөрәк.

**Җырчы, ТАССРның атказанган артисты (1960), Теләче районының Алан авылы тумасы Сөләйман Даут улы Йосыпов (25.07.1925-20.02.2003)**

Узган гасырның 1950-1960 нчы елларында үзешчән сәнгать чын мәгънәсендә гөрләп чәчәк атты. Авыл һәвәскәрләре бер генә бәйрәмне дә концерт-спектакльсез үткәрми, радиодан яңгыраган яңа җырларны алар, шундук отып алып, җырлый да башлый иде. Алтмышынчы елларда концерт саен башкарыла торган бер җыр күңелдә нык сакланган. Ул – «Вәгъдә».

«Вәгъдә»не иң беренче булып радиодан халыкка җырчы Сөләйман Йосыпов җиткерде. Бу узган гасырның илленче еллары иде.

«Вәгъдә» җырының тарихы турында композитор Җәүдәт Фәйзи «Халык җәүһәрләре» китабында язып үтә. Җырның баштагы исеме «Егет моңы» була. Аның күпьеллык тарихы да бар икән. Көенең авторы – Татарстанның элеккеге Бондюг районындагы Песәй авылында клуб мөдире булып эшләгән Зиннур Мөхәммәтдинов. 1959 елда ул Җ.Фәйзигә җырның тарихын аңлатып хат яза. Хаттан аңлашылганча, бу җырның тарихы М.Әмирнең «Тормыш җыры» драмасын авыл сәхнәсендә кую белән башланып киткән икән. Авыл үзешчәннәре әсәрне сәхнәгә куярга әзерләнә, әмма алар драмадагы җырның көен белмиләр. Зиннур исемле гармунчы һәм җырчы егет аңа көй чыгара. Авыл клубы коллективы җырны яратып кабул итә. Спектакль зур уңыш белән уза. Бер елдан соң радиодан әлеге җырны ишеткән яшьләр, көенә кызыгып, әсәрне кабат сәхнәгә куялар. Шуннан соң көйнең икенче тормышы башлана. Песәй авылының укытучысы Нурулла Шәрифуллин (Нур Шәриф), шушы көйне истә тотып, «Чишмә буенда» дигән пьеса яза. Пьесада төп геройның йөргән кызы, егет сугыштан кайтуга, башка кешегә тормышка чыккан була. Төп геройны уйнаучы артист «Вәгъдә» дигән җырны Зиннур Мөхәммәтдинов язган көйгә җырлый. Халык җырны күтәреп ала. «Егет моңы», «Чишмә буенда» һәм, ниһаять, «Вәгъдә» исеме астында җыр тирә-юньгә таралып та өлгерә. Көйнең авторы ул вакытта Колымада була. Берничә елдан соң ул авылына әйләнеп кайта. Кайтса, «Вәгъдә»не халык та, артистлар да башкара, тик көен халык көе дип җырлыйлар, авторын әйтмиләр. З.Мөхәммәтдинов шуңа хәтере калып язган икән әлеге хатны. *«Әмма эш, минемчә, җырның авторын әйтүдә түгел,* – ди композитор Җ.Фәйзи. – *Аны халык яратып, үз көе итеп җырлауда хикмәт. «Вәгъдә» әнә шул бәхеткә ирешкән».*

«Вәгъдә» җыры Вафирә Гыйззәтуллина, Бәширә Насыйрова, Нәфкать Нигъмәтуллин, Габделфәт Сафин һәм Рәфинә Ганиуллина репертуарында да бар.

Тәртип радиосы

***Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан күзге» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева) материалларына нигезләнеп, Ләбиб Лерон әзерләде.*** ■

# көлке куа килә...

## Гамил Афзал (1921-2003)

### Урынбасар булу яхшырак

Киңәш бирәм: җәфа чигеп йөрмә,
Һөнәр эзләп йөрмә аптырап.
Яхшы гына оклад килгән җирдә
Урынбасар булу яхшырак.

Шәп кабинет. Өстәл. Йомшак диван.
Телефонның бор да шалтырат.
Җаның тыныч булган җирдә, туган,
Урынбасар булу яхшырак.

Бер эшне дә үзең хәл итмисең,
Берни өчен җавап бирмисең.
Эшләр хөрти китсә, мин күрмәдем,
Мин начальник түгел бит, дисең.

Рәхәт. Җылы. Тыныч. Оклад килә.
Аена бер чыгып доклад сөйлә,
Начальникка күрен ялтырап:
Урынбасар булу яхшырак.

*1956*



Гамил Афзал.
*Нияз Хаҗиәхмәт шаржы*

## Тәлгат Нәҗмиев (1950-2014)

### Төшләнү

*(Саба мәзәге)*

Беркөнне Саба урамында таныш ханымны очраттым. Хәлләрен сорашам.

– Әйбәт түгел, – диде бу, – ирем Шәфәгать әллә нишләде. Беркөнне йокымсырап ятам. Төн уртасы. Шәфәгать, гырлый-гырлый йоклаган җиреннән уянып, бит уртасыннан «чут» итеп үпте һәм колакка: «Аэропортта очрашырбыз», – диде. Сабада аэропорт бөтенләй юк бит!

– Шуннан? – дим.

– Шуннанмы? Шуннан тагын да катырак гырылдап йоклап китте...

Безнең мирас №2 февраль 2022

**Туфан Миңнуллин.**
***Нияз Хажиәхмәт шаржы***

## Туфан Миңнуллин (1935-2012)

# Лирик хикәя

Ах, аларның килеш-килбәтләре!

Өстәл янына пар күгәрченнәрдәй кара-каршы кунаклаганнар да урталарындагы бердәнбер тәлинкәдән икәүләшеп аш ашыйлар. Икесе дә яшь, икесе дә чибәр. Берсе – Таһир кебек, икенчесе Зөһрә шикелле.

Түзалмадым, килдем яннарына.

– Нинди бәхетле сез, җанкисәккәйләрем! Икәү бер тәлинкәдән, бер-берегезгә елмаешып, ризык җыяр чагыгыз! – дидем.

– Ике тәлинкә ашка акча җитмәде, абый, – диделәр бәхетле студентлар.

## Гәрәй Рәхим (1941-2021)

# Элек һәм хәзер

*(Рифма өчен язылган шигырь)*

Халкым, элек сине сатар өчен
Кирәк булса миллион,
Миллиардлар –
Хәзер сине рәхәтләнеп сата
Үз туганнарыбыз,
Милли артлар.

Элек безне интектерә иде
Атом куркынычы,
Милитаризм.
Ирек алгач, хәзер җанга тия
Үзебезнең ваклык,
Милли таризм.

Безне күпме тыеп, буып тора
Империя,
Тоталитаризм.
Күр, аларның иң шәп ярдәмчесе
Үзебезнең
Татаритаризм.

## Фаил Шәфигуллин (1939-1982)

# Бөек мизгел

*(Пародия)*

*Җир шарына утырып тәмәке төрдем...*
*Мин бер мизгел шагыйрь булып алдым.*

***Разил Вәлиев***

Җир шарына утырып махра төрдем,
Тирә ягым куе кычыткан.
Беркем күрми.
Тик пыскытып ятам.
И рәхәт лә яшәү, кызык ла.

Чү!.. Кычыткан ерып кемдер килә...
Әти ич бу!.. Әти!..
Чәнчелде...
Тәмәкемнән түгел, яңагымнан
Көлтә-көлтә утлар чәчелде.
Ярса – ярды әти,
Янсам – яндым...

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2022



# БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – БАЛАЧАКТАН

*«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны, озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!*

**Мәхмүт Хәсәнов (1927-1990)**

## Көн җылынды

*(Хикәя)*

Әтисе белән әнисе, һәйбәтләп киендереп, Хәйдәрне дә үзләре белән ишегалдына алып чыктылар. Тышта салкын. Кар ява. Әтисе белән әнисе утын кисәргә кереште, ә Хәйдәр бер читкә басып карап торды. Бераздан аның бүрек түбәсен, җилкәләрен кар каплап китте.

Әтисе, Хәйдәргә таба борылды да, елмаеп:

– Улым, кар күмеп китә күрмәсен үзеңне, – диде.

Хәйдәр ни дияргә дә белмәде. Туңам, дисә, өйгә кертеп җибәрүләре бар, ә аның өйдә утырасы килми. Туңмыйм, дияр иде – суык. Әнә бит суык, шаярган кебек кенә итеп, борынны, бит очларын чеметеп алды. Аннары бияләй эчендәге бармакларга, итекләр эчендәге тәпиләргә үк барып җитте...

Әтисе белән әнисе эшли дә эшли. Кая ул туңу! Тирләп чыкканнар. Бераздан әтисе Хәйдәр янына килде.

– Улым, туңасың бит, – диде ул. – Йәле, шушыларны утынлыкка илтеп куй, суык синең янда тора алмасын.

Хәйдәр ярып ташлаган утыннарны берәм-берәм утынлыкка ташый башлады.

– Менә, улыбыз да эшкә ярый хәзер, – дип куаныштылар әтисе белән әнисе.

Бераздан Хәйдәр, әнисе янына килеп, бүрек колакчыннарын чишәргә кушты.

– Әни, көн җылынды! – диде ул.

Әтисе белән әнисе рәхәтләнеп көлеште. Аннары әтисе, Хәйдәрнең аркасыннан сөеп:

– Көн җылынмады, улым, эш җылытты сине, – диде.

## Рөстәм Мингалим (1937-2014)

### Иң зур кеше

Күпне белгән кеше
Ул зур кеше була...
Күптән күпне белгән
Бик зур кеше була.
Бик зур кешегә дә
Тиң зур кеше була.
Әти-әнидән дә
Зуррак кеше булмый:
Шуны белгән кеше
Иң зур кеше була!

## Шаһинур Мостафин (1948-2020)

### Хат языша җәнлекләр

Кыш бабайның тылсымыннан
Ап-ак булган җир өсте –
Беркем кулы кагылмаган,
Чип-чиста дәфтәр төсле!

Куян кызы чабып үтә
«Дәфтәр»гә сүзләр язып...
Озакламый Эт малае
Укыр шул эздән барып!..

## Тәлгат Нәҗмиев (1950-2014)

### «Кыйбат әби»

Улым Нияз кечкенә вакытта авылга кайткач, энем аңа хәйран зур бәягә ике тәгәрмәчле бик матур велосипед алып биргән. Бала аңламас, диптер инде, әни Зөфәрне «кыздырган», кат-кат:

– Кыйбат бит, кыйбат, ник алдың?! – дигән.

Әлеге әңгәмәне тыңлап торган сабый әбисенең бу гамәлен яратмаган. Абыйсын кызганган. Шуннан соң «Кыйбат әби» дигән кушамат такты әбисенә. «Кая барасың?» – дип сорасалар: «Кыйбат әби»гә кайтам», – дия торган булды.

Бервакыт әбисе әкрен генә:

– Улым, бүтән алай димә, яме! – дип үтенә моңардан.

Бала кеше бирешергә теләми.

– Менә бу төш «әйт-әйт» дип тора бит, – дия-дия, йөрәгенә төртеп күрсәтә.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

# ГЫЙНВАР

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 12 гыйнварда Казан Кремлендә, Болгарда Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан, республика оештыру комитетының киңәйтелгән утырышы булып узды. Утырышны ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов алып барды.

● 12-15 нче гыйнвар көннәрендә Мәскәүдә, күренекле галимнәр, дин һәм мәдәният-сәнгать әһелләре катнашында, «Россия исламы: Россия мөселманнарының күпгасырлык тәҗрибәсен аңлау» темасына «Шиһабетдин Мәрҗани укулары» VII Бөтенроссия конференциясе үтте. Аның кысаларында Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти шәех Равил Гайнетдин татар мәдәнияте һәм сәнгате эшлекләләре – Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрының баш режиссеры Ренат Әюповны (татар халкына лаеклы иҗади хезмәт итүе, милли сәнгатьне үстерүгә, үсеп килүче буынны патриотизм рухында тәрбияләү эшенә зур өлеш керткәне өчен) һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Леронны (татар әдәбиятын, тарихын һәм мәдәни мирасны өйрәнү һәм популярлаштыруга зур өлеш кертүе, рухи традицияләргә тугрылыгы өчен) Россия мөселманнарының иң югары бүләге – «Әл-Фәхр» ордены белән бүләкләде.

● 14 гыйнварда Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә Ульяновск өлкәсендәге Иске Кулаткы районының элекке башлыгы, милли җанлы меценант, эшмәкәр, милләтпәрвәр шәхес Эдуард Әнвәр улы Ганиевка (1952-2019) нисбәтле «түгәрәк өстәл» утырышы узды. Утырышта Ильяс хәзрәт Җиһаншин, академик Индус Таһиров, Җәлил хәзрәт Фазлыев, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрит Мифтахов, прозаик һәм драматург Данил Салихов, галим-агроном Харис Камалиев, Татарстанның атказанган урманчысы Ирфан Халитов, «Безнең мирас» журналының җаваплы мөхәррире Ленар Гобәйдуллин һ.б. катнашты.

● 18 гыйнварда күренекле язучы-фантаст, журналист, нашир, 1996 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы, Кукмара районы тумасы Заһид Мәһмүди (Заһид Габделбарый улы Мәхмүтов) кинәт вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде Кукмара районының Манзарас авылы зиратында җирләнде.

● 19 гыйнварда Язучыларның Г.Тукай исемендәге клубында, «Гомер чалымнары» проекты кысаларында, Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Ркаил Зәйдулла белән очрашу булды. Сорау-җавап рәвешендә барган әлеге очрашу-

да (алып баручы – Илсөяр Иксанова) әдипнең каләмдәшләре З.Мансуров, Л.Хәмидуллин, Т.Галиуллин, Р.Фәйзуллин, Р.Батулла, Р.Мөхәммәдиев, В.Имамов, Х.Миңнегулов, Г.Морат, К.Кәрим, Р.Сверигин, В.Нуриев, Р.Җамал, А.Хәмзин, Л.Лерон, Р.Сәгъди, Х.Ибраһим, Н.Гыйматдинова, М.Закир, Й.Шәрәпова, җырчы Г.Сафиуллина һ.б. катнашты.

● 19 гыйнварда Г.Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең элеккеге директоры, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әсхәт Зөфәр улы Сафин вафат булды.

● 20 гыйнварда киң җәмәгатьчелек ТРның Беренче Президенты, ТР Дәүләт Киңәшчесе, ЮНЕСКОның мәдәниятара диалог буенча Махсус илчесе, РФнең Хезмәт Герое Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә 85 яшь тулуны билгеләп үтте. «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр залында үткән тантаналы чарада Федерация Советы рәисе Валентина Матвиенко ТР Дәүләт Киңәшчесе М.Ш.Шәймиевне күркәм юбилее белән котлап, аңа «Федерация Советы. 25 ел» медален һәм Федерация Советы рәисенең Рәхмәт хатын тапшырды.

● 21-22 нче гыйнвар көннәрендә Г.Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында күренекле артист Нуриәхмәт Сафинга 75 яшь тулуга нисбәтле «Арыну» спектакленең (авторы – Айдар Әхмәдиев, режиссеры – Тимур Кулов) премьерасы булып узды. Юбилярны ТР Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникова, ТР Мәдәният министрының урынбасары Дамир Натфуллин, Казан шәһәре башкарма комитеты рәисенең урынбасары Гүзәл Сагыйтова һәм Татарстан театрлары вәкилләре котлады.

● 22 гыйнварда, дин, мәдәният-сәнгать әһелләре һәм галимнәр – Мансур хәзрәт Җәләлетдин, Ансар хәзрәт Мифтахов, Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин, Абдулла хәзрәт Әдһәмов, Әзһәр Шакиров, Ренат Таҗетдинов, Миңгол Галиев, Раил Фәхретдинов, Искәндәр Гыйләҗев, Рамил Төхвәтуллин, Нәҗип Нәккаш, Ләбиб Лерон һ.б. катнашында, башкалабыз Казанның «Әл-Мәрҗани» җамигь мәчетендә мәшһүр шәхесебез Шиһабетдин Мәрҗанины искә алу чарасы булды. ■

# МИРАСВОРД

Математик гамәл

Чәчүлек өчен урманны төпләп, яндырып чистартылган җир

Борынгы Римда ир-атларның өс киеме

Ат караучы

Пионер булырга әзерләнә

Агач чиләк (диал.)

Тагын бер мәртәбә, яңадан (иск.)

Самавыр төбендә көл җыела торган урын

Марат Кәбиров романы

Әлфис ...

Икенче шәкел, рәвеш, төс алу, икенче төрлегә әйләнү күренеше

Алмашынучан ... һава

...-зыгы

Ишек сакчысы (иск.)

Көчле әчкелтем исле дару үләне

... Минкина

Иң борынгы язма

Кытай шашкасы

Шагыйрь ... Мансур

Мөритләр башлыгы

Аллаһыдан башкага гыйбадәт кылу

Озын, куе йон, ябага (диал.)

Нәкый Исәнбәт комедиясе

Борынгы сугыш киеме

Римга нигез салган Ромулның туганы

Танылган татар балалар язучысы

Иганәче

Борынгы Идел

Вьетнамда вак акча

Җәләлетдин ... (урта гасыр фарсы шагыйре)

Пиреней тауларының көнбатышында яшәүче халык

Купшы, көяз

Кыргый суган

Мәш килү, шау-шу, тынычсызлык, буталыш

Борынгы Русь дәүләтендә эре җирбиләүче

Жанна д'...

Рафис Корбан романы

...-ера

Нәрсәнең дә булса яртысы (бор.)

Борынгы салым

Элекке авырлык үлчәве



**1 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:**
**Сулдан уңга:** Натан, «Кичү», дәвер, «Күги», Илсөяр, Өмми, ахак, Ши, бикәбаш, Нух, маг, Агра, әрә, Лена, Зиннәт, илд, исә, киек, Яго, имра, Твен, Шәрәф, илек.
**Өстән аска:** нида, мәзин, Илбарис, Тавил, Игәнәй, Сак, теше, Нурмөхәммәтов, бая, Генри, Ркаил, Ян, әл, Өфе, кактөш, «Аникин», Мингалим, чагым, ур, дер, Исхак, Ка.

*Рәис Габдулла төзеде.*

# «Безнең мирас»
## елъязмасы / февраль

**Бакый Урманче һәйкәле. Казан.** ***Фото «Татар-информ»нан алынды.***

**650 ел элек (1372)**
Мамай морза Рязань кенәзлегенә олуг кенәз итеп Олег Ивановичны билгеле.

**410 ел элек (1612)**
Лейпцигта беренче татар басма китабы дөнья күрә.

**125 ел элек (1897)**
23 февральдә күренекле рәссам, сынчы, график вә мөгаллим Бакый (Габделбакый) Идрис улы Урманче (1897-1990) дөньяга килә.

**100 ел элек (1922)**
Новониколаевскида (хәзер – Новосибирск) себер татарлары вә казакъ яшьләре өчен гыйльми, иҗтимагый вә сәяси «Алмашка» журналы чыга башлый.

**95 ел элек (1927)**
Һади Такташ «Мәхәббәт тәүбәсе» исемле поэмасын тәмамлый. Әсәр «Безнең юл» журналының февраль санында басылып чыга.

**75 ел элек (1947)**
19 февральдә, күренекле шагыйрь Фатих Кәримнең яу кырында һәлак булуына 2 ел тулу уңаеннан,Тукай клубында искә алу кичәсе оештырыла.

**30 ел элек (1992)**
7 февраль көнне Татарстан Республикасының Югары Советы тарафыннан Татарстан Республикасының Дәүләт гербы кабул ителә.

*Журналга* ***Айдар Закиров*** *әзерләде.* ■

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

## Содержание. Февраль 2022

**Историческое наследие:** «Татары – народ, у которого есть своя государственность». И.Тагиров; «Татарское наследие, проданное в Финляндию». Н.Гариф; «Страшный голод». Ш.Юзеева; «Украденное татарское золото». Л.Габдрафикова.

**Татарский мир:** «Сирина Салимшина: «К победе нас привела искренняя дуа верующих!»; «Мы – потомки Чингиз хана!» Ф.Нафиев.

**Религиозное наследие:** «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Хадисы пророка Мухаммеда (с.г.в.)». А.Рахими; «Уроки религии». С.Бикбулат; «Давайте восстановим наследие Сарваретдин хазрата!»

**Литературное наследие:** «Заявление». Р.Батулла; «Дневники Нурихана Фаттаха»; «Стихи Ахмата Гаделя».

**В глубинах памяти:** «О таком исходе событий и не думал». Ф.Сафаргалиева; «В памяти, до сих пор в памяти!»

## Алхәбәр:

**Хәлим Ибраһимовның авылдашлары**
***(«Хәлим һәм ефрейтор Адольф Гитлер». Р.Шәфигуллин)***

# *Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин — фотоларда*

Каләмдәшләр. Беренче рәттә (сулдан уңга): Тәлгат Галиуллин, Ренат Закиров, Ринат Мөхәммәдиев, Разил Вәлиев, Лидия Шилова, Фәрваз Миңнуллин, Рәис Даутов; икенче рәттә: Равил Вәли, Эдуард Касыймов, Наип Лаисов, Николай Алешков, Рахмай Хисмәтуллин, Кадыйр Сибгатуллин, Нәҗип Мадьяров, Мәхмүт Газизов, Ямаш Игәнәй. *Чаллы, 1981 ел*

Кадыйр Сибгатуллин (уртада), Ризван Хәмид (сулдан беренче), Хәниф Хөснуллин (уңнан өченче), Рәшит Гәрәй (уңнан икенче)

Чаллы язучылары Мәскәү шагыйре Лев Ошанин белән. Беренче рәттә уңнан беренче – Разил Вәлиев, икенче рәттә сулдан беренче – Хәниф Хөснуллин, өченче – Нәҗип Мадьяров, дүртенче – Кадыйр Сибгатуллин, алтынчы – Ямаш Игәнәй, җиденче – Рәшит Бәшәр, уңнан беренче – Газиз Кашапов. *1983 ел*

Уңнан беренче – Рахмай Хисмәтуллин, икенче – Кадыйр Сибгатуллин, сулдан беренче – Факил Сафин

Уңнан сулга: Вахит Имамов, Кадыйр Сибгатуллин, Хәниф Хөснуллин, Равил Лотфуллин



Фотогр. печатаніе Г. Ф. ЛОККЕ въ Казан

СЕЛО БОЛГАРЫ, БАШНЯ, МАЛЫЙ МИНАРЕТЪ.

СӘЛАМ УЛСЫН СИҢА, БОЛГАР,
ОЛУГ ДАННАР КҮТӘРДЕҢ,
МӘДӘНИ ШӘҺӘР УЛДЫГЫҢ
ЯУРУПАГА КҮСТӘРДЕҢ...

Фотогр. печатаніе Г. Ф. ЛОККЕ въ Казан

СЕЛО БОЛГАРЫ, БѢЛАЯ ПАЛАТА ИЛИ БАНЯ.

**ИНДЕКС:**
**ТАТАРСТАНДА – П2343**
**РОССИЯДӘ – П7074**
**beznenmiras.ru**

***«БЕЗНЕҢ МИРАС»***
***журналына башкача язылу:***
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

***«БЕЗНЕҢ МИРАС»*** журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.